МӨХӘММӘТ МИРЗА

# ТЕРЕ СУ

*Газәлләр, робагыйлар, гыйбарәләр*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007

УДК 821.512.145-1:3
ББК 84(2Рос=Тат)-5:4
М51

**Мирза М.**

Тере су: газәлләр, робагыйлар, гыйбарәләр, шигырьләр / Мөхәммәт Мирза. — Казан: Татар. кит. нәшр., ISBN 978–5–298–01488–5. 3000 д. — 351 б.

ISBN 978–5–298–01488–5

Мөхәммәт Мирзаның бу китабында соңгы елларда иҗат иткән әсәрләре — газәлләре, робагыйлары, гыйбарәләре урын алды.

ISBN 978–5–298–01488–5
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Мирза М., 2007

## КӨЗЛӘР ТӨСЕ

Уңмас, җуелмас Илаһым нурына,
И Мирза, манып язамсың каләмең?

*М.Мирза*

Шигърият чытырманлыгына аяк баскан һәр кеше үз юлын, үз сукмагын табарга тырыша.

Адым саен монда шик һәм өметсезлек сагалый.

Адашып калуың да бар!

Ләкин иң куркынычы — кеше сукмагыннан атлау. Ә янәшәдән сукмаклар гына түгел, олы юллар да үтә. Кемдер таптаган җирдән сәфәрне дәвам итү нинди җиңел югыйсә...

Юк, Шагыйрь офыкларга таба үз юлын эзли.

Төнге зилзиләләр чолгап алган аны.

Ул, күктәге йолдызларга багып, юнәлешен билгели. Йолдызлар — аңа кадәр үтеп киткән юлчыларның җан тамчылары...

Шагыйрь үзе дә шушы дөньяда эреп бетә. Шигырь табигатенең бер күренешенә әверелү — менә бөтен нәтиҗә. Иң югары кимәл...

Кара төннәрдә йолдызларны таба алмаганда:

Катлам-катлам кара болыт
Каплаганда күгемне,
Яшен булып яшьнәдем мин,
Яңгыр булып түгелдем.

Татар шигъриятендә Мөхәммәт Мирзаның исеме яңгырый башлаганга озак вакыт та үтмәде кебек. Хәтеремдә, егерме еллар элек Рөстәм Мингалим — Язучылар берлегенең тар бер бүлмәсендә утыра иде ул, нәни өстәленең ике ягына тау булып папкалар өелгән, якын килеп карамасаң, ябык гәүдәле шагыйрьне күрә дә алмыйсың... — безгә, шунда әвәрә килгән берничә кешегә, шигырьләр укый башлады. Сирәк күренеш! Шагыйрьләр бер-берсенә чит кеше шигырен укырга бик атлыгып тормый. Ләкин болар укырлык шигырьләр иде.

Мингалимгә ышанмыйча, мин үзем дә кычкырып укыдым аларны.

Шигырьләр кытыршы иде. Бәлки, шуңа җәлеп иткәннәрдер?! Шома шигырьләрне без күп күргән...

Шигырьнең әйбәтме, түгелме икәнен ничек беләсең?

Әлбәттә, аның үз кануннары бар... Теориясен дә күпмедер чамалыйбыз.

Тик... укыганда аркадан кайнар гөрләвекләр йөгереп узса, монда инде бернинди өстәмә дәлилләр кирәкми.

Мөхәммәт Мирзаның (дөньялыктагы исем-аты Илфак Ибраһимов икән) шул вакытта укылган шигырьләре үк кайнар гөрләвекләр кузгатты дип расларга җыенмыйм... Хәзер... Ләкин тәэсир итте.

— Актаныштан! — диде Рөстәм Мингалим, нигәдер горурланып.

Шагыйрь эчкән суларның тәме — шигырьләрдә...

Хикмәт анда гына да түгел.

Мәгълүм ки, шагыйрьне сәмави биеклеккә күтәргән канатларның берсе үзеннән алда килгәннәрнең мирасы булса, икенчесе, һичшиксез, халык авыз иҗаты. М.Мирза бу яктан аерата бәхетле: татарның бердәнбер саф төбәге булган Актанышта телебез үзенчә аһәңле, сыгылмалы, җор... Әлеге затлылык шагыйрьгә ана сөте белән күчкән.

М.Мирзаның шигырьләрен укыганда, борынгы шагыйрьләребезнең дә йогынтысын тоймый мөмкин түгел.

Әмма бу тәэсирне йогынты дип атарга кирәк микән?

Уйлап баксаң, һәр шагыйрь гасырлар аша сузылган шигърият чылбырында бер бөҗра булырга тиеш бит. Күрдек: күпләр шуңа берегә алмыйча юл буенда сибелеп калды.

Мирасыбыз — мең еллык шигърият, дип һәрдаим сөйләнсәк тә, хакыйкатьтә үткән гасыр давыллары безне әлгәреләребездән бөтенләй аерган иде бит. Ислам фәлсәфәсен белмәвебез сәбәпле, без борынгы шигъриятебезне бөтен байлыгы, бөеклеге белән аңлый да алмадык.

XX гасырның егерменче елларыннан соң татар шигъриятенең иң асыл җәүһәрләре йә имансыз коммунистик идеология тәэсирендә, йә яһүд-христиан мәдәнияте җирлегендә барлыкка килде.

Гасыр ахырында күздәлекләр коелып калгач, әһле каләм беравык аптырап, югалып та калды. Капкалар ачык, офыклар киң!

Мөхәммәт Мирза менә шул чакта шигъриятькә килеп керде.

Узгандагы ялгышлары чабуыннан тотып тормый иде.

Ул әле юлны башлады гына!

Шигъриятьтә биологик яшьнең әһәмияте юк.

Туксанда да тупсада ятарга, алтыда да алтын тәхеткә менәргә мөмкин.

Шагыйрьләр гадәттә яшьли таныла. «Егерме яшьлек шагыйрьләре булмаган әдәбиятның киләчәге юк», — дигән бер акыл иясе.

М.Мирза шигъриятькә соң килде. Әмма юлы уң булды. Ул, бәлки, яшьлегендә үк шигырь белән авыргандыр. Ләкин тормыш мәшәкатьләре аны бөтенләй бүтән өлкәләргә алып китә, башка һөнәрләрне иярләргә мәҗбүр итә.

Язмыштан узмыш юк — иярләнгән ат барыбер йөрәктән сикереп чыга...

Иңемдәге ике фәрештәнең
берсе — нәфис, берсе — нәфес.

Нәфис барыбер кодрәтлерәк!

Тынгысызлык — менә шагыйрьнең иң төп юлдашы. Талант тынгысыз булырга тиеш. М.Мирзаның шигъри эзләнүләрендә аерата ачык күренә ул. Үлчәмнәр үзгәрә, аһәң, шәкел... Робагыйлар, газәлләр, эпиграммалар, мәдхияләр, нәзыйрәләр... Әле шагыйрьнең авазында йөрәкләрне кысып алырлык сагыш, моң ишетелә... Син аның белән канатланасың, сызасың... Әле ул сине җиргә китереп бәрә — бөтенләй көтелмәгән социаль каһкаһә яңгырый... Тавыш тупаслана... прозаизмнар колакны тырный. Нишлисең — монысы да безнеке, шигъриятебезнең Тукайлардан, Бабичлардан килгән үзенчәлеге.

Шагыйрьне мактарга да, сүгәргә дә кирәкми. Ул бит шигъриятнең бер чагылышы гына:

Аерма татлы газабың,
Шигърият, колыңнан.
Сине эзләп килде җаным
Мең яктылык елыннан.

Шигърият биләп алган җаннан да серлерәк һәм сәеррәк ни бар тагын бу гөнаһлы җир йөзендә?

Кайчагында Мөхәммәт Мирза миңа сикәлтәле юлдан алга ыргылучы җайдакны хәтерләтә.

Кая ашыга ул?

Ул аны үзе дә белмидер.

Борын канатларын киергән атны ул түгел, ә шигырь җене камчылый.

Шуңа да юлдагы сикәлтәләр кайчак шигырьләргә дә күчә.

Табигый.

Мирза шигырьдә кыланмый, уйнамый, кемнедер осталыгы белән шаккатырырга җыенмый, ул шигырь булып яши.

Кемгә бу ошый, кемгә ошамый.

Һәркемгә дә ошарга шигырь, кем әйтмешли, акча түгел.

Аның ашыгуын аңлыйм мин... офыклар күзенә кызыл төшкән... үләннәр күзендә — ак...

Мәңгелек җиленә шагыйрь йөрәге сизгеррәк.

Мин — көзге шигырь...
араламагызчы
көзге төскә кереп януымнан;
янып-ялкынланып — азаккача! —
алтын төскә кереп калуымнан...

Алтын төсләргә төренеп ап-ак кышларга керү хыялыннан безне кем аралый ала?

Беркем дә...

Безнең бәхетебез дә, бәхетсезлегебез дә шунда.

*Ркаил Зәйдулла*
*14.02.07*

Газәлләр

* * *

Фатихасыз бер көнем дә торалмам,
Ил-көнемә иминлек бир, Бер Аллам.

Уң кыл юлын бөтен нәсел-ыруның,
Кодрәтең киң, рәхмәтең зур, Бер Аллам;

Сыенамын хаклыгыңа инанып,
Рухымны яктыртасың иң алдан,

Ризыгымны мул итәсең — мең шөкер,
Разыймын саулыгыма, Бер Аллам;

Таныйм, тоям, сөеп яшим дөньяны:
Җаным иҗат рәхәтенә уралган.

Хәер — савап гамәлендә ачык юл
Камиллеккә ирешүдә, Бер Аллам!

* * *

Коръән — бел, хаклык үрнәге бердәнбер,
Раббым мәңгелек нурына төргәндер.

Дәгъва кылып дөньясына, малына,
Тәкәбберләр инкарь итеп көлгәндер;

Санламый бер хәдис, аять сүрәсен,
Мин-минлеген фәкать алга сөргәндер;

Кодрәте зур: гыйбрәтлән, и Кеше,
Кайсы кайда ни газаплар күргәндер;

Рәхмәте киң: ярлыкалып меңнәре,
Тәүбә кылып, хак юлына кергәндер;

Яралган җан хозурында Бер Хакның,
Фани дөнья — савапланыр өченгәдер...

* * *

...Әйләнә сәхнә, әйләнә,
Сибелеп кала еллар...

*Р.Фәйзуллин*

Җир — тоташ бер сәхнә, тора әйләнеп,
Күренешләре бер-беренә бәйләнеп.

Суырылып килеп керә сәхнәгә
Котып, чүлләр... көз, кыш, язы, җәйләре.

Алышына ничек моңзар — тамаша,
Төсләр, хисләрдән китә баш әйләнеп.

Уенчылар — патша, ханнар, вәзирләр,
Җарияләр, коллар кала шәйләнеп...

Бәрелешә холык, акыл, ихтыяр,

Сөю — мәкер, сагыш — нәфрәт, хәйләлек...

Күкләр хөкемендә бөтен тамаша...
Тукталмасын, мәңге торсын әйләнеп...

...На страшной высоте
земные сны горят...

*О.Мандельштам*

Күкләр хәбәр итә шул көн хакында:
Тиңсез күчү көтә җирне якында...

Туфан кубар, актарылыр тау-ташлар,
Болытка җитеп баскан дулкынында.

Кояш, Ай, йолдызлар алышыр ягын,
Күзең ачып-йомып алган бер тында.

Көнбаешта алланыр да таң атар,
Көнчыгышта сүрелер, батырында...

Тереклектән калыр бары яралгы,
Тернәкләнер өчен яшәү тагын да.

Орлык хәлендә калалсаң, и Мирза,
Язарсың барын шул хәлләр хакында...

*** * ***

Актарасың: һәр битеннән батыр чыга...
Алтын дисең, көмеш дисең — бакыр чыга...

Катламнарда казын дисәң: янган шәһәр,
Сынган кылыч, киселгән баш — сабыр чыда!..

Таш кыяда, мәгарәдә тамга-сыннар, —
Асылына төшенгәнче акыл чыга...

Тузга язган, уйган ташка елъязмачы,
Бәхәс, ызгыш куптарасын уйламыйча...

Дәгъва кыла, гауга кора галим-шаман,
Күрәзәче, сихерче һәм багучыга.

Хаҗәте ни, дан-шөһрәте кисекбашның...
Тарих — кизәк, кагылдисәң — исе чыга...

*** * ***

Үтеп бара заман, тузган чал чәче,
Таныйм аны, ул бит бабам яшьтәше.

Салкын көздә бергә килделәр җиргә...
Җирдә купты канлы җәнҗал җир өчен?..

Аямады кардәш, кавем бер-берсен,
Кот, иманы чыгып качты — җен эше?..

Ана — улны, ата кызны белмәде,
Көпә-көндез кылынды бар төн эше;

Үтеп бара заман, йөзе — йөз яра —
Батып кергән кардәшенең теш эзе...

Яфрак ябар, чирәм басар эзләрен...
Хәтердән чыкмас кара кан исе...

* * *

Ничек, дисәң, шулай мөмкин атарга: —
Мәскәүләргә татар товар — сатарга...

Коллык беткән, имеш, калган ихтыяҗ,
Димәк, хаҗәт юк бетереп атарга...

Тәһарәтле һәм сөннәтле бу кавем, —
Җүнгә алып, мөмкин кыйммәт сатарга...

Йогышлы да, йомышлы да... — бар барын,
Мөмкин уптым, мөмкин ваклап сатарга.

Әҗәткә дә биреп була: «Бурычлы
Үлмәс!» дигән әйтем шул ук татарда...

Качып китмәс, баш күтәрмәс эш аты.
Мәскәү кулында алтатар — татарга!..

* * *

Кемлегенә карап, сыең куясың,
Көткән килми калса, җыеп куясың;

Йөз нурыңны да ачасың сайланып,
Ярлыга гел аркаң борып куясың;

Туганыңны тарсынганда ни хәтәр —
Үзләрен гаепле итеп куясың...

Барсы бар, тик туя белмисең һаман:
— Ал, — дисәләр, тар ярыкка сыясың...

Капкан саен майлы калҗа үзеңә...
Йотканыңа шәп кикереп куясың...

Бик тә алып китәр идең җыйганың,
Белмисең кабергә ничек сыясын...

* * *

Газәл — гүзәллек бакчасы, уз, сылу,
Гөлләр сәламли, кулларың суз, сылу;

Сафлыкка чумган мең төсле манзара
Чакырып тора, икеләнмә, уз, сылу;

Тиңнәрең бар да: сызылган җәя каш,
Иреннәр — ачылган бөре, бүз, сылу;

Тик тәкъдирдән кем дә китәлми качып,
Көнчеләр күзе көйдерер — түз, сылу;

Мәрхәбәдән бер адымда мәсхәрә.
Зинһар, үзеңә колак-күз бул, сылу...

Тиңе юк бәхет сафлык һәм матурлык...
Газәл — гүзәлләр бакчасы, уз, сылу!..

* * *

Холыксызлар кемнедер гел битәрләр...
Нидер кылып, хәтта хөкем итәрләр.

Нәфрәт тулы сүзләр кисәр һаваны,
Сүгеп җиде буынына җитәрләр...

Тәмам тетеп бәгыреңне, җаныңны
Аяк асты таптап, изеп китәрләр...

Бер тыннан соң кабат килеп яныңа,
Берни булмагандай хисләр итәрләр...

Сәбәп итеп, хәтта тапмый сәбәбен,
Инде мактап, сине сөеп китәрләр...

Якын йөрмә, шайтан орган — шулардыр,
Үтмәс чирләрен йоктырып китәрләр...

* * *

Сөй гомерне, сөй халыкны...

*Г.Тукай*

Килгәнсең дә төпләнгәнсең бу якта,
Ризалык та сорамый торып хәтта...

Чир үтсә дә, гадәт кала, диләрме,
Әр-җәнҗалсыз тормыйсың бер сәгать тә.

Көнче, дисең, мескен, дисең халыкны,
Телисеңме булуын шул халәттә?

Юләр, дигән саен акыл артмый ул,
Сүзләмәктә булыйк әле, әдәптә...

Туганына тапмаган бер җылы сүз,
Үзе үк кала мескен кыяфәттә...

Яктыртмакчы булсаң халык күңелен,
Якынай һәм бул олы мәхәббәттә.

* * *

Чигенде кыш — чигенгән гаскәр кебек,
Урман, кырдан ышна төште үкереп...

Инеш, дәрья кубарылып бозыннан,
Ташып акты йотып яры, күперен...

Муеныннан суга чумган талларның
Бөреләре саркып чыкты бүртелеп.

Йолдызлы күк чуарлаган күллеккә
Каңгылдашып төште казлар төркеме...

Утырган кош оясында төнозын,
Бәбкәләрен барлап торды бөтереп...

Алып килде Җиргә күпме манзара
Соңлап килгән язның шушы бер төне.

* * *

Күкләр битараф түгел һәр тарафка,
Күреп торалар барсын бер карап та...

Бөгелсә бер гөле күбәләк кунып,
Тәгәрәп китсә чык үлән, яфракта...

Кузгалса чүл исеп үткән тын җилдән,
Комы күчәр диеп, кайсы тарафка...

Актарылса диңгез, купса дулкыны,
Ни халәттә калырлар, дип, корабта.

Энә күзеннән үткәрә һәр мәлең,
Һәр гамәлең языла күк тарафта.

Гыйбрәтләнер өчен болар, и Бәндәм,
Күкләргә фарыз җирне сакламакта...

* * *

Тантана итсә дә һаман төннең туе,
Күр, озайды көн яктысы керфек буе.

Тынмый калмас февральнең соры бураны,
Боҗырлар баскан тезелеп чана юлын...

Боз эчендә изрәп яткан кебек кенә
Бөреләр төсен үзгәртә — җете куе...

Яры, талы язны көткән Агыйделнең,
Актарылып бер ташуда бөтен уе.

Аратада кешнәгән шул турайгырның
Көтеп көтек булган көне Сабан туен...

* * *

Ни тәңгәллек — бердәй тамыр тибеше,
Төс, кыяфәт, холык-фигыль килеше.

Ачу, нәфрәт, үпкә, курку хисләре,
Юк анда һичбер кемнең кичереше...

Ялган-яла, тәкәбберлек, көнчеллек
Гомер булмаган, гайбәт сүз имеше.

Эшле-ашлы — муллыкта бар яшәеш,
Саф көмештер чишмәләре, инеше.

Юк артыгы, юк киме, хаҗәтенчә:
Хәләл хуры, хөрмәсе — мең җимеше...

Савапларың өстен чыгып, иншалла,
Оҗмахларның түрендә бул, и кеше.

* * *

Кышның китәсе килмиме һич кенә,
Өеп-өеп яуды кары кич белән.

Салкын тынын өрде бөтен җиһанга,
Салып тунын, кулмәген кигәч кенә.

Ак мамыкка төрде каен, талларны,
Бөреләре ачылам дигәч кенә.

Тәрәзәмә элде томан пәрдәсен,
Тулган айга карыйм бер дигәч кенә.

Керфегеннән тамды тозлы бер тамчы,
Иреннәре иренемә тигәч кенә...

Тыныч бул, өзгәләнмә, и Мирза,
Бу кар — сыерчык бураны ич кенә!..

* * *

Уйчан йөзем борчулы күренмәсен,
Әйтеп булмый һәрчакта күңелдәсен.

Асылташтан кыйммәтрәк, кадерлерәк
Бергә булган шушы төн өермәсе.

Мәртәбәле шөһрәт, дәрәҗәдән
Сиңа— тәхетемә — тик ятлар үрелмәсен.

Язны көтеп тилмергән бәхет бөрем
Эремәслек бозларга төренмәсен.

Синең хакта актан-ак уйларымның
Йөзенә былчырак сүз түгелмәсен...

Талчыктырмасын уйларың, и Мирза,
Син бәхетеңнең җиде күгендәсең!..

* * *

Һәр ташуда ун адым чигенде яр,
Ни хәл итим, түгел минем ихтыяр.

Узган елда агып китте ун тирәк,
Бу ташуда ничәсе җанын кыяр?..

Катлам-катлам бозлар килеп орынды:
Ярылды боз — тотты тамыр — торды яр.

Йөзенче кат оруында, йа Ходам,
Ун тирәкне кочаклап убылды яр.

Агыйделдән агып китте ун тирәк:
Сулкылдап калды өзек тамырлы яр...

Ташкын судай гомерләр дә, и Мирза,
Узып бара, еглап калыр кайсы яр?

* * *

Тулган айда күрдем йөзең төсләрен,
Уяндылар мәрткә киткән хисләрем.

Ничек ялгыз дип әйталам үземне,
Кабат кайтты, гел минеке кичләрең.

Бергә чакның күпме сере аларда —
Серләремне һичкемгә дә чишмәдем.

Хәтер — диңгез, бәхтем булган шуңа тиң,
Син — корабы, ап-ак иде җилкәнең!..

Татлыдан да татлырак ни җиһанда —
Учларыңнан чишмә суы эчкәнем!..

Ак корабың йөзеп бара, и Мирза,
Тулган айга бакчы — ап-ак җилкәне!..

* * *

Дөнья гел алыш-бирештә, аңла син,
Бирсәләр — ал, алсаң — бирми калма син.

Алганчы тик, лязим бирү үзеңә,
Бирәм дигәч, кире тартып алма син.

Гел алырга күнеккән куллар булыр,
Эзләренә эзләрең һич ятмасын.

Хәрам җыйган, таптым дигәч талигын,
Калыр тотып җимерелгән арбасын.

Үлчәвеңдә калдырма һич шик-шөбһә:
Кирәксә — бүл дүрткә тары ярмасын!..

Дөнья кала, малы кала, и Мирза,
Җаныңа нур җыярга соңарма син!..

* * *

Кызлы йортның капкасында ат торыр,
Тояк чыңы пәрдә читен тарттырыр.

Әдәп-сафлык бөркеп торган күңеле,
«Бисмилла»лы тәне һәрчак пакь торыр.

Сафлыгына тиң тәңгәл сылулыгы
Сан җитмәслек кыйммәтләргә хак торыр.

Хак Тәгалә нурландырган җанына
Фәрештәләр һәрчак уяу сак торыр.

Гаден* йортның бакчасында хур кызы
Җирдә тиңен күреп чиксез шат торыр!

Рухы, җисме самим-садә Кыз бала
Ике дөньяны бергә тоташтырыр!

* * *

Күзгә-күз багып бирәмсең сәламең,
— Туганым, — дип өзеләме камәлең?

Нәсел-ыру, ил-йорт йөге иңеңдә,
Нык будыңмы билеңдәге камәрең?

Дога, бәддогамы вәгазь-таләбең,
Вәгъдәңә тәңгәл ятышмы гамәлең?

Яктыртмакчы күңлең күгең күпләрнең,
Кояш, Ай, йолдызлымы үз галәмең?

Искәндә дулап җаһиллек җилләре,
Имангамы чакыра бу әләмең?

Уңмас, җуелмас Илаһың нурына,
И Мирза, манып язамсың каләмең?

* * *

Көн уртасы, туктап калды сәгатем,
Юк иде лә кинәт туктау гадәте.

Соңга калдым килер-барыр юлымда,
Шул сәгатем туктап калу сәбәпле.

Сәгатькә ни, аның һичкем каршында
Юк бирәсе йә аласы әҗәте.

Без генә ул, баш күтәрми көн-төнен,
Гомер буе үтибез кем хаҗәтен?

Вакытны кертермен димә тәртәгә,
Җитсә дә күпкә акылың, сәләтең.

Кабат йөреп китте дивар сәгатем.
...Туктап калыр беркөн гомер сәгатем.

* * *

Әйтче, кардәш, һаман түзеп торыйкмы,
Суын сыккан каен кебек корыйкмы?

Җаһил җилләр җелекләрне өткәндә,
Бөкерәеп арка куеп торыйкмы?

Күзгә карап килерең не кискәндә,
Карачкы күк, күрми-дәшми торыйкмы?

Әллә акылга килеп бер төштән соң:
— Тор, күтәрел, милләт! — дип лаф орыйкмы?

Аяк-куллар, аң-зиһенгә салынган
Мең дә бер богауны өзеп орыйкмы?

Бусагада яңа гасыр, и кардәш,
Асылына тәңгәл тормыш корыйкмы?

* * *

Тыңла, ничек сыктый көз кышны тоеп,
Дерелди, күз яшьләрен көчкә тыеп.

Сарыга сарылып утларда яна,
Яшел яшьлеген ул тәгаен кыеп.

Талгый җилләр даланың бар курасын,
Мең авазлы көй чыгарганчы җыеп.

Сүрән кояшның йончыган нурлары
Таралып бетеп, йоклыйлар оеп.

Күк кинәт ябынды кара пәрдәсен:
Явармы җепшек кар йә яңгыр коеп?!

Гомерләрнең бер мәле бу, и Мирза,
Тамгалап куй хәтереңә нык уеп.

* * *

Малай булсаң, малай бул, тик куркак булма,
Ике төрле фәлсәфәгә уртак булма.
*Р.Мингалим*

Бәләкәй булсаң бул, тик син вак булма,
Мантымас малга куелыр хак булма.

Биеклектә, бөеклектә бел чамаң:
Үзең дә буй җитмәслеккә мотлак булма.

Һәр терек парлы яралмыш җиһанга,
Бердәнбер үзең аерым так булма.

Сыналмыш кеше, дан-дәрәҗә алып,
Җете кызыл тиз уңа — онытмак булма.

Ялтыраган бар да түгел лә алтын,
Ятлар бәхетенә кызыкмак булма.

Анык бул, Мирза, иңеңдә кем йөге?
Ахмак балтасы чабар ботак булма!

* * *

Карыйм да бу дөньяның дүрт ягына:
— Шөкер, — димен Хак биргәннең барына.

Хөрлегемә, саулыгыма мең разый,
Тулып агам гомер-дәрьям ярына.

Ил-йортым киң, ризыгым мул, рухым шат,
Юлым ачык — хилафсыз иманыма.

Ким итмәгән — ургып тора хисләрем,
Былбыл оя кора күңлем талына.

Күгем зәңгәр, таңым алсу, гөлләрем
Һәрчак шифа, илһам коя җаныма.

Җиде бабам күтеп алган бәхет бу:
Насыйп әйлә, Раббым, оныкларыма!

# РОБАГЫЙЛАР

* * *

Эшлексезнең төп шөгыле — сафсата,
Эш башлардан әүвәл ул акыл сата...
Ук алмаслык аралыкта ерак тор,
Хакыйкатькә ул агулы ук ата...

* * *

Сөйләгәнне тыңлау фарыз сайланып:
Пешкән, өшегән авыз гел зарланыр...
Мактанчык вә гайбәтченең телендә
Барысы да имгәнер, зарарланыр.

* * *

Әйтерең хаклыгын әүвәл ачыкла:
Кылчыклы булмасын бәяң, ашыкма...
Даһи иҗат — түгел тары боткасы,
Кабып йотып булмый салып кашыкка...

* * *

Ишек, тәрәз уелмаган тикмәгә,
Үзең дүрт дивар эченә бикләмә:
Ишет, күр — киң вә якты бу дөнья,
Күрә торып, килереңне чикләмә.

* * *

Хак бүләге — һәрнәрсәнең үз төсе,
Яз, көз, җәй, кыш үзгәрмәктә — күп төсе.
Камиллекнең булсын дипме өлгесе...
Күз агын зәңгәрсу иткән — күк төсе?!

* * *

Белмәс иде һичкем дә юк-барыңны,
Чәчеп йөрмәсәң дөньяга зарыңны,
Инде белдек — танылмакта ниятең:

Күпертеп, борчак ясамак тарыңны...

* * *

Җан биргәнгә җүнен биреп тора гел,
Гамәлләрне саваплыдан кора гел:
Ирешергә телим дисәң ни-нәрсә,
Фатихасын Раббыңның сора гел.

* * *

Шөкерана кылу фарыз барына,
Теләгәндә сыеп була тарына...
Бер алдын, бер артын күрсәтер дөнья:
Көтелмәгән газапларга тарыма...

* * *

Бу дөньяның бердәнбер «Мин»нәре күп...
Һәрберсенең бәхетле «Миң»нәре күп...
«Миң»ле «Мин»нәр арасында тагы да
Мин-минлеге азынган тиңнәре күп...

* * *

Тыңласаң, бетәсе түгел — күп хәбәр...
Хаклыгына төшенәм дисәң әгәр:
Кемнән чыккан сүз? — ачыкла иң әүвәл:
Бәһәсе — сөйләүчесенә бәрабәр...

* * *

Вәгазьчеләр күп үрчеде — исәпсез...
Авызлары гөрләп тора, и шәп сүз...
Ул вәкарьлек Имамында! — Һич тә сез
Кичәге ата коммунист димәссез...

* * *

Ул, имеш, камилдән камил тумыштан,
Өстәлер ни юк хәтта укымыштан...
Йолдыз булып җирдә гел балкымакчы,
Киеп алып ялтырыйк күлмәк-ыштан...

* * *

Аһ сөймиләр берсен берсе, аһ сөймиләр,
Ул тегеләй, ул болай, диеп сөйлиләр.
Ә чынында әләкче ул гайбәтчеләр,
Имәннәрне бит юкә белән чөйлиләр...

* * *

Ал, җаный, ал йөрәгемне учыңа,
Синең учыңа төшәм дип очына...
Үпкән-кочкан җилгә очкан, дисеннәр...
Җилнең аның җаны да юк, учы да...

* * *

Әле куеныма алып җылыталам.
Әле үзем дә куеннан җылы табам...
Шул рәхәтнең газабыннан аермасын...
Әле көнләп, көнләштереп яраталам...

* * *

Өйләренә уйган тәрәз сигез икән...
Тәрәзеннән күрдем: кызы симез икән;
Түшәгеннән түгелеп төшкән түшләре
Казбек белән Эльбрус кебек игез икән...

* * *

Галиләр күп, мин — Галиләр Галие,
Сүз сөрешенең Хәйяме, Кол Галие
Дип инанган үзе турында үзе.
Баксаң — гап-гади тәмуг Галилие...

* * *

Киңәшенә һичбер кемнең карамый,
Икеләнми: ярый, дип, йә ярамый...
Мәртәбәле исемнәрнең барын да
Алып бетергән үзенә — харами...

* * *

Синдәй шәпләр булып киткән элек тә,
Үзгә фикерне тормаган элеп тә.
Шуңар истә калган тик гадәтләре,
Исемнәрен һичкем әйтми белеп тә...

* * *

Көрәшәмен, дисең, үзең аямый,
Милләт, дисең, халкым, дисең һәрдаим...
Шәһәр саен ташлап качкан гаиләң.
Ишетмисең дә күрмисең ай-ваен...

* * *

Милләт, динең мәнфәгатеннән бизден,
Шул хакка дөнья рәхәтендә гизден...
Фиргавенгә тиң зурлап озаттылар...
Хак каршына килеп басарсың тиздән...

* * *

Көтмәгәндә буең җитмәс биеккә
Күтәрерләр сынап карыйк диеп тә...
Гамәлләрең чагышмаса чамаңа,
Мәтәлерсең бер чыра-ук тиеп тә...

* * *

Уйнашчылар һәрчакта да чиркандыра...
Узышлый булса да узмас чир калдыра.
Сәясәттә сазаганнары шуларның...
Халкына тик өеп нәҗесен калдыра.

* * *

Түгелгән тир микъдарына бәрабәр
Бөртек белән билгеләнгән бәһәләр...
— Бер телем, — дип теләнмәсме бер көнне,
Бүген хакын тиен иткән бәндәләр?

* * *

Алынганчы бер-бер эшкә уйла Син,
Ният кылсаң, инде читкә куйма Син.
Бер тарыдан ботка пешерә заман:
Шул тәгамнән өлешеңне җуйма Син...

* * *

Маллы һәрчак билдән биек сикерә,
Кирәк — таба җитеп җирнең читенә...
«Барлык», «юклык» — фани дөнья ваклыгы,
Җанның хаҗәте юк елан итенә...

* * *

Ягылмаган мичкә арка куймыйлар,
Корылмаган йортка ишек уймыйлар.
Буш хыялдан арына алмаганнар
Аркылыны буйга алып куймыйлар...

* * *

Фатиха — гади сүз, җөмлә түгелдер...
Әйткәне — тел, әйттергәне күңелдер...
Ирешсенгә җиде буын катына,
Мәгънәсе биеклегенә үрелдер...

* * *

Чүп чиләге — иң кирәк бер әсбаптыр,

Булмаса шул — дөньяңның өстен-астын
Нәҗес басар... Тик шулай да тормышта
Чүп чиләге булудан Син бик сак тор!..

* * *

Гадел хисап лязим мирас бүлештә.
Нәфес — шайтан — котыртыр, бул белештә...
Һәм белеп тор: ызгыштырыр барысын,
Әгәр бер хатын кысылса бу эшкә...

* * *

Туган туганнан бизенә мал тапса,
Ишеген ача тик үз ише какса...
Дуслар бизә беркөн барын югалтса,
Үзе туган тупсасына килеп баса...

* * *

Чиксез иде көч-куәте, гайрәте,
Төзек иде, тигез иде дүрт саны.
Инде дөнья чәчеп йөри гайбәтен:
— Бер-берсен ашый татар?! — дип, аны...

* * *

Гомер итү бер катлаулы җөмләдер:
Ымлык, кисәкчәләр сүзгә теркәлер...
Сан, сыйфат әверелеп мәгънәгә,
Исемне биеклегенә күтәрер...

* * *

Ул мәкам, ул ыспайлык сүзләмәктә:
Гашыйк итәр ишеткән тәү сәгатьтә...
Рәвешенә әйтмәс һичкем кайтыш сүз —
Мәгънәсе бер тиен тормаса хәтта...

* * *

Йомышлы булсаң да, йогышлы булма...
Яллыга ялланып, юк эшле булма.
Үлгәч булса да җавап тотарсың;
Азгын уйнашчыга йомышчы булма...

* * *

Бәләкәйдән даулап алдың барысын,
Йомырканың хәтта куш сарылысын.
Алтмышыңда да алтыда калырсың,
Тар түшеңә тимер-томыр тагарсың...

* * *

Әдәплекнең шома битлеген каплап,
Төп-төз басып, йөрисең кыек атлап...
Дөнья чүбен чөям дисең күтәреп,
Чәнечкеңә сәнәк саплыгын саплап...

* * *

Язганнары гел урта кул югыйсә,
Даһилыкка дәгъвасы зур бихисап...
Шәп күтәрә үзен табып җай-исәп,
Нишләр дөнья үзгәреп китсә кисәк?!

* * *

Күп белдеклеләр күп булган элек тә...
Үзгә фикерне тормаган элеп тә...
Барсын бергә җыйсаң да тиң булалмас:
Син — бөекләр бөеге мин-минлектә...

* * *

Тормыш — диңгез, йөздем дисең аркылыга,
Тиңләп үзеңне иң киме акулага...
Авыз ачып тыңлап торыр идек тә бит:
Фәлсәфәң сай — тәңгәл кильки акылына...

* * *

Фәрештә түгелсең, читкә йөргәләдең.
Кояш батуга, уҗымга кергәләдең.
Кардәш-дусның маңгаена мөгез куеп,
Күрәләтә: — Син — мүкләк, — дип, сөзгәләдең...

* * *

— Ал, — дисәң дә, алырга һич ашыкмый!
Кап, — дисәң дә, читкә этә кашыкны.
Тыштан боз да, эчләрендә вулкан шул:
Хәлен һичкем аңлый алмый гашыйкның...

* * *

Ун бармагы ун кәкре кармак кебек,
Бар дөнья малын каптырып алмак кебек,
Гомер буе чиртеп торса да балык,
Нәфсе туймас, куллары армак кебек...

* * *

Уяу тор бу дөньяның һәр очрагына,
Җил-давылы йомычкадай очыра гына.

Күкләр өчен Адәм гомре Аһ! дигәнче
Дөрләп янып, сызып сүнәр чыра гына...

* * *

Туган җирең — кендегең төйнәлгән төш,
Яшимен дип, дөньяга инәлгән төш.
Бары-югына багып кинәнгән төш,
Гомереңне үткәреп җибәргән төш.

* * *

Рас килде — фаразлар хаклыгын кара син,
Ачып хәтернең тоз сибәр ярасын.
Кан һәм сөякләр түшәлгән бу кала.
Котырган этләр кулына каласы...

* * *

Шундый-шундый хәлләр бездә: тыңлале,
Тыңлаган булып тыңламый тормале.
Күкләргә кемдер күтәрмәк безләрне,
Койрыгыннан эләктереп торнаны!

* * *

Явыз белән усалны һич бутама,
Усал хакны әйтеп ярыр уртадан...
Явыз, үтеп бәгырь-бакчаң түренә,
Гөлләреңне йолкып чыгар уталап...

* * *

Ир теләге — бер сылу вә бер аттыр...
Ил терәге — бер пәһлеван ир-аттыр.
И Тәңрем, кодрәтең киң, бу илнең
Син теләкле пәһлеваннарын арттыр...

* * *

Ни кадәрле җаваплылык — ачыклыйк...
Күзге каршыннан куарга ашыкмыйк.
«Матурлык коткарыр, — диләр, — дөньяны»,
Хөрмәт итик үз-үзенә гашыйкны!

* * *

Үзенеке генә һәрчак үзәктә,
Ничек оста үзен өстен күрсәтә...
Әрсезлектә аңа тиңнәр табылмас,
Бар дөньяны бетереп эзләсәк тә!..

* * *

Аның өчен вакыт — хисап арасы:
Кайчан-кайда яңа бүләк аласы?..
Тар түшендә энә төртер урын юк —
«Нәфес» орденын кай төшкә тагасы?..

* * *

Баш түрәгә сөалем бар хикмәтле,
Беләсеңме хак бәяңне — ни хәтле?
Үзем күреп, үзем ишетим дисәң,
Бүлнистә чират тор әбәткә хәтле...

* * *

Кануннарны кабул итә депутат,
Күрәләтә хакны-нахакны бутап.
Камил канун — кабер казу үзенә:
Калыр кагылгысыз булудан туктап...

* * *

Үкчәсе дә текә биек булган, диләр,
Үзеннән биекне көнләп куган, диләр,
Үчләшерлек һичбер көндәше калмагач...
Бу кәрлә үз күләгәсен буган, диләр...

* * *

Күрә торып күрмәгәннән ерак тор,
Ерак торсаң да, кылырын юрап тор...
Үзенә бик кирәксә, күз дә йоммый:
Күрмәгәнен күрдем, диеп елатыр...

* * *

— Бер кашык дегет бер мичкә бал бозганын
Инде мең беренче мәртәбә ишеттем...
— Ишетү ни нәрсә, төшендеңме, егет:
Бер кашык балмы син, бер мичкә дегетме?..

* * *

Күрергә бик кирәк булган күрелмәгән,
Сизәргә бик кирәк булган сизелмәгән...
Тәрәзәмә яглып үскән чия пешкән.
Буй җитсә дә, нәфес җитеп өзелмәгән.

* * *

Ирек — хөрлек, диеп, хәтәр йөрсәләр дә,
Калын кашлы карттан бик нык көлсәләр дә,
Тәхеттән китәсе килми берсенең дә:
Халыкка ни — кала бары көрсенергә!..

* * *

Янып бетеп бара гомер — тоямын,
Сүрелгән көлләрен җаннан коямын...
...Фатихасын алырмын, шәт, дөньяның,
Дүрт ягын да тигез күрдем мин аның.

* * *

Без кабызган утлар янып тора,
Без төзегән йортлар балкып тора.
Без омтылган оҗмах тормыш кына
Офык артларына качып тора.

* * *

Язылası җырлар язылмаган,
Табынасы ярлар табылмаган.
Үткәннәрдән гыйбрәт алынмаган,
Киләчәккә күпер салынмаган.

**Синнән башка**

Бу кичтә синнән башка сагыныр кешем юк,
Сагынудан ары һичбер сарылыр кешем юк.
Бу кичтә синнән башка табыныр кешем юк,
Табынырга сиңа тиңдәш табылыр кешем юк.

* * *

Читләр кулы белән күз тоткан,
Читләр теле белән тоз йоткан.
Баса-баса арык аркаларга,
Вәзир булганлыгын оныткан.

* * *

Һич туймады нәфесе кан эчеп.
Әләк, чагу — бүген, кичәгесе.
Белә торып ничек кеше дисең?
Син — дөньяның сукыр эчәгесе.

* * *

Философлар читтә торыр хәйран калып,
Аракының зарарын ул аңлатканда.
Хәмер капкач, охшап кала бу «гали» зат
Ләгәнгә төшкән бер сары тараканга.

* * *

Күрмәгәнне күрәсең килә бик,

Оҗмахларга керәсең килә бик.
Гөлләр булып үрәсең килә бик,
Дуңгыз булып сөрәсең нигә, ник?

* * *

Кояшта да таплар бар, диләр,
Бәндә ничек булсын тамгасыз.
Уң битемдәге бу нокта — миң —
Күңелем күзенең алмасы.

* * *

Тәүбә ит, бәндә, бер Ходаң каршында.
Туар көн — җавап тотарсың каршында...
Кылган бар гамәлең, хәтта уйларың
Сурәттә күренер үз күз каршында...

* * *

Җилләр исә, тарый еллар толымын,
Буразналый йөздә язмыш корымы...
Алын — ал, гөлен гөл иткән чак булды:
Һәр мизгеле бер гомергә торырлык!..

# КОШ ТЕЛЕ

*(Кыска шигырьләр)*

**Икеюллыклар**

Иман ерагайган саен,
Якынайган җаһиллек...

* * *

Кояшта да таплар бар, ди,
Кемнәр калдырган икән?..

* * *

Кем белми шул хакыйкатьне:
Туар көн төн артында...

* * *

«Кисекбаш»лар болай гына,
Эч пошканнан язылмаган...

* * *

Ташлап чыккан иске йорт шикелле,
Тәмам бушап калган күңелем...

* * *

...Айны, Марсны бүләләр,
Җиргә туймаслар...

* * *

...Комганыннан көлә сәхнәдә
Тәһарәтсез татар баласы...

* * *

Күз карасы кебек дусларым бар
Күз карашымнан ук аңлаучы!..

* * *

Баш — каш түгел, сызып кына
Булмый аны төзәтеп...

**Мәсәл**

Яшәгән гомере, шөкер, йөз ел!
Йөз елга калыр язганы — йөз юл!

* * *

Көлеп катырган эчен
Елап йомшартмак була...

* * *

Санның сынга күчешендә
Галәми мәгънә ята...

* * *

Маймылдан яралмаганына төшенүгә,
Кеше галәмне яулады.

* * *

Галәм, Җирне санламаса,
Таңын да аттырмас иде...

**Өчьюллыклар**

* * *

Тормыш—гел алыштыр:
Син яки язмышың
Аркага салыштыр...

* * *

Гөл-чәчәкләр арасыннан
Эзлим сиңа охшаганын...
Охшаган, дип ышанамын...

* * *

...Мин бар кыйммәтләрне
Шигырь бизмәненә
Салып үлчим хәзер...

* * *

...Иртәсе, иртәсе!..
Энҗегә төрелгән
Җир — күкләр иркәсе!..

* * *

Ычкынды гомер йомгагым,
Белмим кая тәгәрәсен.
Бармы юрар мәгънәсе?!

* * *

— Күк капусы ачылса,
Теләр идең ни теләк?
— Милләткә бер ир кирәк!..

* * *

Случай — сам великий вор...
*И.В.Гете*

...Төн — тотылмас карак:
Йомылдырып күзләрне,
Урлый безнең гомерләрне...

* * *

Чалманарат — гомерем бишеге!
Егылып төшмәсен дип, чабуымнан
Бәйләп үк куйган кендек әбисе...

* * *

Ятлар аш куйды — ачыктым,
Су бирде — сусадым,
Җылы сүз атты — туңамын...

**Илһам җыры**

Илһам җыры —
Йомшак, җылы,
Сабый куллары кебек!..

* * *

Карый кешелек
Туар гасыр катына...
...Буразнада ат тора...

* * *

Бүләк итимме
Гомеремнең яртысын?
Икеләнмим — алырсың...

* * *

Яшьләреңне шулай
Агызмачы, и бала...
...Ярылып, эзе кала.

* * *

Ятагың салкын,
Кайда идең бу төнне?
Әйт, җылыттың син кемне?

* * *

Атлантлар киткән
Төпкә, әллә күккәме?..
— Күккә, — диде Үрмәгөл.

* * *

Базар — мең ел зар,
Бәяләр үскәненә...
...Кирәк гел өскә менә...

* * *

Агач корыса,
Оя кормый кошлар да...
Шуңамын пошаманда.

* * *

Үпкәләү дип уйламачы
Вакыт-вакыт дәшмәвемне.
Дәшми генә яшьнәвем, бел!

* * *

Кеше хәлен кеше белмәс.
Син белеп тор хәлләремне,
Тик күрсәтмә җәлләвеңне...

**Чокыр**

Чокыр — җеннәр оясы:
Дөньяның бар чүп-чары
Шундадыр җыелмасы...

* * *

Теләнченең —
Туеп алгач —
Теле әче...

**2004 елның көзе**

Еллар охшамый елга,
Ноябрьнең уртасында
Кар-боз күрмәде елга...

* * *

Тормыш шәп иде...
Кызыл авызларга...
Халык ишәк иде...

* * *

Ярыш та ярыш,
Күчмә байрак алганчы
Калышма карыш...

* * *

Иблис астыртын:

Уе — зыян салмакта...
Уяу тор һәр тын...

* * *

Син кайда, Сылу?
Юк ник бер тының —
Газап юксыну?..

* * *

Кайда җир чите?
Урап кайтканчы җирне...
Чыкты чи ите...

* * *

Кемгәдер — ишетелгән бәхет,
Кемгәдер — төшкән бәдбәхет,
Һәммәсен шәт — көтә ләхет.

**Дүртьюллыклар**

* * *

Күңелемнең ябагасын
Кырып аласым килә.
Биләүдәге нарасыйдай
Саф-пакь каласым килә.

* * *

*(Мәсәл)*

Кибән астында бер тычкан әйткән үртәлеп:
— Түрәләр күрми, бәяләми хезмәтемне.
Озын кыш буе иңсәмдә йөртәм күтәреп
Адәм баласы күтәралмас шушы йөкне!..

* * *

Заман җилләре исә лә,
Маңгайга эзләр кисә...
Җанкаеңны кем җылытыр,
Челләдә кырау тисә?..

* * *

Йөксез поезд кебек шакылдап тик
Үтеп китеп барды шигырьсез көн.
Кызарып каралды офык чите,
Әллә болыт купты, әллә төтен?..

* * *

*(Мәсәл)*

Койрыгын кысып, посып яткан көчекнең
Беркөн салпысына салам кыстырдылар.
Тартып-сузып ике башка үстерделәр,
Аннары соң хуҗасына өстерделәр...

* * *

Йөрәгемә дәштем: «Түз! — дидем, —
Газапларың беркөн чигенер.
Ак сөлгедәй ап-ак көн килер:
Илһам нуры белән чигелер».

* * *

— Еракларга китеп кара, — диләр, —
Үз хәлеңне анык белергә.
Китмичә дә беләм, хәйран калам:
— Ничек мөмкин шулай бөлергә?!

* * *

Атылды йолдыз —
Янды кем җаны?
Сөреме якты
Ярты дөньяны...

* * *

— Ниләр күрербез тагын? — дип
Аптырамагыз.
Күрәчәкне күрсәткән бит
Нострадамус.

* * *

...Ташулар, ташулар...
Ярларга язылып
Кала да сүзләре,
Югала үзләре...

* * *

Йолдызлар
сабантуй
үткәрә
августта...

* * *

Тарих тамырыннан
Төртеп чыкты курпы.
Куркып калды дөнья:
— Тартар, татар, ургы...

* * *

Үз хәлемне үзем генә беләм,
Сорамагыз: «Нигә, нилектән?..»
Шигырьсез үткәргән көннәремне
Җәһәннәмдәгедәй хис итәм...

* * *

Талгын җил йөземә ягылды,
Пышылдап: «Боекмачы»,— диде.
Җил түгел, син икән, син икән
Юатмакчы буласың мине...

* * *

Үтеп китте егерменче гасыр,
Кешелекне канга батырып.
Үтмәс шомга салып, янап китте:
— Бер кайтырмын! — диеп, акырып.

* * *

— Дусларың шәпләрме? — дисең.
Дуслар шундый төстәрәк:
Берсе суга тез астына,
Берсе үрелә өскәрәк...

* * *

Сорыйм шигем калмасынга:
— Кайсы ялганың, чының?
Утырдың кем арбасына,
Җырлыйсың кемнең җырын?..

* * *

Шүрәле бармагы сыман
Кысылды көн Күк белән Җир арасына:
Җирдә мәңге чарасызлык
Адәм - Һава баласына.

* * *

Бизмә, шигырь, ятим итмә колыңны,
Алма җаннан йомшак җылы кулыңны,
Балкыт Илаһыдан килгән нурыңны,

Яктырт мәңгелеккә күчәр юлымны!

* * *

Мәңгелек акыл җитмәслек еракта,
Сере җитмеш җиде мең бер йозакта...
Киек Каз Юлында казлар тавышы...
Кемнәр китә?.. Кемнәр кемне озата?..

**Тәкъдир**

Тәпи атлап киткән көннән
Һәркем — мосафир...
Юллары төрле булса да,
Барыр җире — бер...

* * *

Үзенә дәште кыйблам — Казаным,
Чакырды гел шигъри азаны…
Тик Нөркәмдә калып язармын
Гомер китабымның азагын...

* * *

Кайда да бер Кояш,
Кайда да бер үк Ай,
Кайларда торсак та,
Иманлы ит, Ходай!..

* * *

Сиңа килдем, утлар-сулар кичеп,
Өметемне кысып учларыма...
Ялкыныңа сулар сибим ничек,
Ут тергезим ничек учагыма?!

* * *

Көннең кашын сызган кара күмер,
Сөрмәсен дә тарткан карадан.
Көн белән төн арасында—гомер.
Йә, кем чыгалган шул арадан?..

* * *

Дөньяда Адәм баласын
Күрәчәге җилкетә...
Күреп бетергәч күрәсен,
Ике аршын җир көтә...

* * *

...Әүвәл телен кистеләр,
Аннан тотып печтеләр...
Ни әйтсен, кая барып,
Кече тел белән калып...

* * *

Тәкъдиренә тәңгәлдер
Җирдә кемнең кемлеге.
Кем сөйри, кем сөйрәлә,
Кемдер дөнья кендеге...

* * *

Илләр гизеп кайткан, имеш,—
Дөнья күргән...
Чабатасын элеп куйган
Чөйгә түрдән...

* * *

*Г.Афзалга ияреп*

Рәсәй һәрчак супер булды,
Тик халкына сукыр булды.
Талап алды бар җирен,
Тиенләп бирде әҗерен...

* * *

Мәңгелек боз таулар эреп кибә
Күзең ачып йомган бер мәлдә...
Мәңгелеккә килгән кебек, нигә
Нәфсең котыртасың, и бәндә?!

* * *

Тыелган татлы җимешем,
Татымаган тәгамем...
Ничекләр итим көмешем?
Үзең тап бер әмәлен...

* * *

— Кагылма, — дидең, — күңелгә,
Уалыр пыяласы...
Түгелеп китсә, тамчылап
Кем диңгез җыяла соң?!

* * *

Бөекләрнең биеклеге
Кызыктырмады һич тә.

Кояш булып кояш сүнә,
Сүрелеп бетеп кичтә...

* * *

Алып барыр юлы бер генә —
Тәгәрәпләр китте йомгагым...
Дөнья — фани... Гомер дигәне —
Бер ачып, бер күзең йомганың.

* * *

Никадәрле кирәк — шулай чыда,
Тик таштай катмасын күңелең...
Таш күзеннән дә яшь бәреп чыга,
Төпсез күле тулса түгелеп...

* * *

Илбасарны илләр басмый торса,
Чир-чор баса: кыза, өшәнә...
Милли арысланнар, милли филләр
Кереп йөдәтә гел төшенә...

* * *

*26 апрель*

Изге бер әманәт итеп,
Догасына тиңләп,
Тукае туган көнендә
Шигырь укый милләт!..

* * *

Керфегем төште кәгазьгә,
Киселде язар сүзем;
Сулкылдап елап җибәрдем,
Яшьләнде төннең күзе.

* * *

Ага да ага вакыт,
Дәрья — су кебек...
Кеше гомере —
Дәрья — суда бер күбек...

* * *

...О войне?
Окопная правда еще
Не написана...

*Г.Бакланов*

Окоп дөреслеген язар өчен,
Окопларда яту кирәк шул.
Окопларда ятып
Исән калганнар бик сирәк шул...

*** * ***

Бар да үтә,
Бар да китә.
Кала хәтер.
Кала кабер.

**Әнкәй**

Карашыңны тоям һәр тарафта:
Агып барган ап-ак болыттан да,
Ак күбеккә баткан шомырттан да,
Бармак имеп яткан оныктан да...

**Томанда**

Талы да юк, яры да юк,
Агыйдел дә юк сыман:
Бар җиһанда салкын тынлык,
Бар җиһанда ак томан.

*** * ***

Тулган Ай серле елмая.
«Таныйсыңмы әллә?» — дим.
Төнозын бер керфек какмый,
Айга баккан бәндә мин.

*** * ***

Кайнар хисләремне
Салкын карашыңа
Манам да алам, манам да алам...
Барыбер янам...

*** * ***

Җир
Галәм каршында
Имтихан тота—
Өлгергәнлеккә.

*** * ***

Ерак калмады шул инде язга,
Изүләре ачык кышкы көннең.

...Һәм, мөлдерәп, очына тамчы төште
Күңелемдә тулган боз сөңгенең.

* * *

Һәркемнең
Тәнен — Җир,
Җанын Ай
Көтәдер...

* * *

Ник баса бу моң мине,
Авыраеп баса моң?
Киләчыгып чабасым,
Ертып төннең карасын.

* * *

Белмим
Алда тагы ниләр күрәсемне.
Беләм
Барысы өчен кыйммәт түләсемне.

* * *

Иңемдәге
Ике фәрештәнең
Берсе — нәфис,
Берсе — нәфес.

* * *

Карама очында ярты Ай,
Үләндә таң чыгы ялтырый...
Изелгән җиләкләр өстендә
Онытылган кулъяулык зар елый...

* * *

Уң кабагым тарта,
Сул кабагым тарта:
Әллә шатлык арта,
Әллә кайгым — артта?

**Шикләнүчегә**

Чүплектән тапкан сөяген
Кемдер талый дип белеп,
Куып җибәрмәкче бер эт
Үз күләгәсен, өреп.

**Шөкер итәм**

Әткәм-әнкәм гомер биргән,
Үзләренекен өзеп.
И Раббым, шөкер итәм:
Дүрт ягым да төп-төзек!

**Язны көткәндә**

Кыш күтәреп киде бүреген,
Салыр бер көн, куяр элеп үк.
Күр, үзгәрә төсе бөренең —
Тулып килә күзгә күренеп.

**Элек һәм хәзер**

Авыл саен бер исерек,
Бер исәр, диләр иде.
Хәзер бары да исерек...
Акыллысы ничәдер?..

**Җир белән Күк арасында**

Тәннең Җиргә кайтасы бар,
Җанның Күккә китәсе.
Җир белән Күк арасында
Гомеркәйләр итәсе...

**...тора дөнья**

Гаҗәпләнеп тора дөнья:
— Нишли татар, нишли? — дип, —
Бербөтен булу кирәктә,
Берсен берсе тешли, — дип...

**Көздә бер мәл**

Коелган сап-сары яфраклар
Пышылдап, серләшеп яталар...
— Бар иде тибрәлгән чаклар! — дип,
Бер-берләрен юаталар...

* * *

Роза гөлем ачты чәчәкләрен,
Бүлмәм тулды алсу, моңсу нурга;
Юылды да бетте юшкыннары, —
Күңлем тулды нурлы, моңлы җырга.

**Шигърият**

Аерма татлы газабын,
Шигърият, колыңнан.
Сине эзләп килде җаным
Мең яктылык елыннан!

*** * ***

*Г.Афзалга ияреп*

Җаны телəгəнгə елан ите,
Күгəрченкəй сөте кемнəргə?
Ил казнасын талый эте-бете,
Хуҗасы үлəр-үлмəс көннəрдə...

**Кышкы төндә**

Шартлап ярылды бүрəнə,
Күңел ник курка шунда?..
Əллə яшен яшьнəдеме
Кырлач төн уртасында?..

**Көз**

Көз, көяз кызлар шикелле,
Көн дə бер күлмəк кия.
Ни кисə, шулай сөйкемле, —
Менə күз нидəн тия...

**Ни калган?**

Булган су тегермəне,
Булган җил тегермəне—
Аларын юган вакыт,
Калган тел тегермəне...

**Кош теле**

Кош теле җибəргəн Əнкəй
Кучтəнəчкə авылдан.
Каптым, тик йота алмадым,
Куркып телсез калудан.

*** * ***

Торган җирең ничек, дисəң əгəр,
Кайтыш ягын əйтү уңайсыз:
Туган җирдəгедəй күклəр зəңгəр,
Тик зəңгəр күк монда тургайсыз.

**Көз соңы**

Калмаган бер яфрак коясы,
Калган бары карга оясы...
Утырып карт тирəк төбендə,

Уйларымны калды җыясы...

**Иртә язда**

Иртәләгән яз барыбер
Бер хикмәтен күрсәтер.
Кырау суккан алмагачның
Керфегендә күз яше...

*** * ***

Таныйм сине, гөлем, болындагы
Бихисап күп гөлләр арасыннан.
Янып торган йөзең мең адымнан:
— Монда кил! — дип чакырып ала сыман.

**Шигърият**

Читләштеләр күпләр, инде сит ят.
Сан бирерлек, имеш, сының юк.
Тик мин һаман колың, Шигърият, —
Синнән башка сыеныр җылым юк!..

*** * ***

Буш бүлмәмдә сәгать һәм мин—
Ялыктыргыч бертөрлелек:
Үткәрәбез көнне, төнне,
Бер урында бөтерелеп...

**Көзге көй**

Көзге көй, юкә балыдай,
Татлы да, мөлаем да.
Ничек җырламый түзим соң
Моң сарган көз аенда?!

**Көзге төс**

Көз төсенә тиң куярлык
Кайсы төсне тапмак кирәк?
Вакыт үзе, хәйран калып,
Алтын көзгә башын игән.

*** * ***

Китәселәр китеп торсалар да,
Карыйсы да килми ул якка;
Газаплардан гына торган дөнья
Һаман саен үзенә тарта.

* * *

Балачактан иртә кояш чыга,
Балачактан һәр кич ул бата.
Шушы бөек ике күренештә
Җирдә яшәү мәгънәсе ята.

**Илһам**

Киреләнсә килми, —
Чакыр-чакырма син.
Килгән чакта сизеп
Калсаң — Акын ла син...

* * *

Күк чакыра кебек җанны,
Күңел шуннан курка да.
Күп татыган бу җиһанда
Калып булмас, кусалар.

**Үземә**

Җилгә сөйләмә сереңне,
Җил — гайбәтче — чәчәр генә.
Гайбәт түгел, кырау тимәс
Шайтан таяк чәчәгенә.

* * *

Гомер җыйган гөнаһлардан
Арынасылар килә.
Юып элгән ак күлмәктәй
Сарыласылар килә.

* * *

Адашып кергән уйларым—
Чит оя бәбкәседәй
Бәргәләнә-бәргәләнә
Чыгып китәр җай эзләй...

**...диде авыл**

Кыш чыкканчы, өч исерек
Бар урманны кырып салды.
— Урман бетә, — диде авыл,
Тик аһ-зардан узалмады...

* * *

Ташны таш бәреп ваталар,
Ташка таш бәреп ут чыга.

Таштан бар авыр хаталар.
Таш атма узгын юлчыга...

* * *

Тормыш дигән шушы алачыкта
Чүки-чүки кеше сын аладыр;
Очкын чәчеп торган корыч булат
Чын кылыч булганчы сыналадыр.

* * *

Күз алдымда сабый «мин»легеңә
Шакшы үкчә белән типтеләр.
Түзә алдың, сынатмадың, улым,
Минем яшьләр әле дә кипмиләр.

* * *

Җигелеп дөнья йөгенә
Үр мендек, эч чыгарып;
Мал да юк, дан да килмәде,
Булдык көнлекче бары.

* * *

Ихтыяры да ул, эч сере дә —
Күпләр көтеп алды шатланып.
Изүләрен ертып бер эчсеннәр —
Көн дә төшермиләр патшаны.

* * *

Бу — минем шигъри бакчамда
Өлгергән тәү җимешләрем.
Өзеп алыгыз, кабыгыз
Үрелеп буегыз җиткәнен.

* * *

Күкләр куйса киртә,
Күкрәп булмый һич тә.
Кояш байый гына,
Кояш чыкмый кичтән.

**Белә торып**

Туган туганын рәнҗетә бик еш, —
Белә шул ул аның кичерәсен.
Кайчак читне якын итәбез, —
Белмибез лә агу эчерәсен.

**Өметсезлек**

Кояшым сүнде, җылынам
Чит-ятлар кояшында.
Көнем үлде, ә төннәрем —
Үрмәкүч оясында...

**Мәңгелек сорау**

Гел яңаны эзләп табабызмы,
Табып югалттыкмы күптәннән?
Киләчәккә таба барабызмы,
Кайтып киләбезме үткәннән?

* * *

Күктән бәхет, дан иңмәде,
Йолдыз булып балкымадым.
Дан яки Вөҗдан дигәндә,
Сатмадым һәм сатылмадым.

* * *

Катлам-катлам кара болыт
Каплаганда күгемне,
Яшен булып яшьнәдем мин,
Яңгыр булып түгелдем.

* * *

— Тәмле! — дидең, иренең тигездең дә
Тамып чыккан каен суына.
Чисталыгын суның шул мизгелдә
Күчерлең син елмаюыңа.

**Көн уртасы**

Җәйге урман. Көн уртасы.
Тынып калган тирә-як.
Кинәт, сискәндереп җанны,
Җиргә төште бер яфрак.

**Җан**

Бүрәнәдә бер күбәләк, —
Урап кайткан кем җаны?
Бүрәнәсе белән бергә
Күтәргән ул Җир шарын.

* * *

Көнне көнгә ялгыйм ничек,
Уртасында озын төн бар?
Кырлач гыйнвар төнендә

Явыз ялгызлык хөкемдар.

* * *

Ташны бәреп чыккан чишмә кебек,
Яшәү даулап тудың дөньяга.
Яхшыгамы гомерең, ямангамы
Багышларсың икән, и бала?!

* * *

Син әле белмисең:
Бик шапшак бу дөнья.
Иртәгә мин аны
Чакырам дуэльгә...

* * *

Хыянәтне кичерә алмый йөрәк,
Ачу-нәфрәт инде сүнсә дә,
Акыл шуңа күптән күнсә дә,
Гафу сорап тезем түнсә дә...

* * *

Кан көндәше — шагыйрьләрне
Һәр тиран үзенчә кырган:
Кайсы — өзгән чабып башын,
Кайсы — данда тончыктырган.

* * *

Зәңгәр күзләреңнең тирәнлеге —
                                        диңгезнеке,
Киңлеге — күкләрмени!
Кабул итми күңел синсезлекне, —
Ничекләр түзәрмендер.

* * *

Сызып үтә көннәр бер-бер артлы,
Үтә өметләнгән сәгатьләр.
Үткән саен үкенүләр артты,
Табып кына җиткер сәбәпләр.

* * *

Киләләр дә китәләр тәлинкәләр,
Йә, әйт, ни кызыгын табалардыр?
Иртәгәсе көндә Рәсәй шаулый:
— Читләр безне шефка алалар, — дип.

* * *

Тигезсез яратылган дөньяда
Тигезлек даулап гомер уза.
Тигезлек бары теге дөньяда:
Хаким дә, сукбай да бер — тузан.

**Ачлык**

Ачлык кычкырып елый урамнарда,
Ачлык — козгын, ачлык — карчыга.
Ачлык түбәнсетә, тезләндерә,
Илтеп дошманыңның каршына.

* * *

Көзнең төсе төссез быел,
Төссез, болганчык судай.
Гомерләрнең көзен шулай
Итә күрмә, и Ходай!

* * *

Көзгә керәм. Агачларым
Яфракларын коймый гына.
Көннән-көн ныграк уралам
Көзнең сары толымына.

* * *

Минем дә чаларды чәчләр,
Бар дөньясы шулай булгач...
Бер чеметем бәхетемә
Чиләкләп кайгы коелгач.

* * *

Алтынсыз яшәп була.
Хатын-кызсыз,
Алтын көзсез
Күңелсез...

* * *

Минем дә булды буранлап,
Давыллап алган чагым;
Күк карасын айкый-айкый,
Яшенләп яуган чагым.

* * *

Адаштырып хисләремне,
Елмаеп карамачы.

Инде белмим нишләремне, —
Ялгыштан аралачы.

* * *

Кырау да төшмәгән көз иде бит,
Каян килеп чыкты кар-буран?
Тупылларым яшел яфракларын
Калтыратып елыйлар сыман.

* * *

Итәк кисеп җиңне ялгап кына
Бөтен итеп булмый җиһанны...
Шыр дивана туган нарасыйда
Бәргәләнеп елый кем җаны?..

* * *

Томаландымыни хисләр —
Көлмим дә, еламыйм да...
Дөнья малы миңа нигә?
Бирмим дә, сорамыйм да!..

* * *

Кемнән кем туеп ялыккан —
Вакыт күрсәтер ачык...
Килер көн, ташлап барысын
Кем китәр кемнән качып?!

* * *

Сәхнәдә коточкыч гаделлек:
Мөмкин — үзеңнән көлдерергә,
Мөмкин — көлдереп һәм елатып,
Төкәнмәс данга төренергә!..

* * *

Һәр исемдә шигырь бар...
Шигырь — җисем бизмәне:
Кемдер — дөнья бизәге...
Кемдер — дөнья бизгәге...

* * *

Үч кодрәте аң-зиһенне томаласа,
Асыл затлар асылыр яки асылыныр...
Мисал дисәң, күз алдына килә баса
Утыз җиденче елы үткән гасырның...

* * *

Җаныңны ваклама:
Таралыр, сибелер...
Шакшы табаннарда
Тапталыр, тибелер...

* * *

...Хыялы — килер көнендә,
Хәтере — үткәнендә...
...Һәркемгә җитә шул хәле
Гомерен үткәрергә...

**Еники торган бүлмәдә**

*(Остазым Р.Мингалим Әмирхан ага*
*Еники фатирына күчеп яши башлагач)*

Еники торган бүлмәдә
Укып ятам Еникине.
Морзалыгы, Мирзалыгы —
Әмир, Ханлы, Еникиле...

* * *

Гыйбрәтләнү өчен гыйбарә —
Борынгыдан күчеп ул барыр:
Ата-анасына орынган
Нәсел-ыруыннан гел калыр...

* * *

Күкләр күзе белән күрү кирәк
Дөньялыкта ниләр барганын...
Аерырга чынын, ялганын...
Ни язмышка җирнең тарганын...

**Үр**

Үр — иң тәүге корылма:
Тоткарлаган үтә җилне,
Борган ташып аккан суны,
Йоткан төзәп аткан укны...

* * *

Әле язлар төшкә генә керә,
Хөкем итә кырлач салкыны...
Боз-пыяла эчендә тал бөре,
Өметемнең кузы-ялкыны...

* * *

Еллар яткан арабызга кереп,

Юллар ябык торды ни гомер...
Хәтеремә салып куйдым төреп:
Бергә булган шул төн — бер гомер!..

*** * ***

Бәхет ишелеп төшми ул,
Төштә күреп кенә...
Өнеңдә ташлар күчерсәң,
Тешең кырып керә...

*** * ***

Дөньясы — базар, ни хакың,
Аныклап тор, сорап тор...
Мыскалга салып вөҗданың
Сатылудан ерак тор!

*** * ***

Тәгәрәп киткән җирнең йомгагы:
Җәелгән дә җәелгән дала...
Чәнечкеле билчән, кылганы...
Яланаяк йөгерә бала!

*** * ***

Дулкын бәрә — таш кырлана...
Җил куба — күчә комы...
Күз ачып йомган арада
Күк күреп кала моны...

**Кеше**

Җилне җиккән, ут тергезгән,
Агымны борган буып...
...Тик әүвәл үзен чыгарган
Мәгарәсеннән куып...

*** * ***

*Г.Афзалга ияреп*

Сүзне үлчәп сөйләр заман килә,
Авыз — йомык, колак сак булыр...
Көнозыны җир актардым, димә,
Җәмәгать эшенә чап, зурым...

*** * ***

Бу кыш тагын ниләр алып килер?
Кемнәр китеп барыр кайтмаска?
Шушы уй гел килеп керә басып,

Төнозыны керфек какмаска!..

* * *

Бирсәгез дә алмамын артыгын,
Кименә дә разый түгелмен...
Һәркем салпысына үз саламы,
Кыстырыгыз шуны — күнермен!..

* * *

Кай тарафтан яңгырар сур?
Туфан кубар кай яктан?
...Әйтерсең бер — ни кылырсың —
Җир җиде кат гөнаһта...

**Гыйнвар**

Ташуларга әле ерак,
Кырлач кыра кырыстан.
Бүрәнәләр шартлап тора,
Көнне үткәрә кылычтан.

**Февраль**

Буран эчендә кояш
Бер күренә, бер кача.
Бозлары кубып төшеп,
Бөре керфеген ача.

**Март**

Көне аяз, төне аяз —
Керәсе килми тыштан...
Ятып җыласа да җиле,
Җир җылыга авышкан...

**Апрель**

Сыерчык бураннары ла,
Гөрләвек урамнары.
Ташый елга, ташый хисләр,
Мәхәббәт буалары...

* * *

Хыял узынган, теләкләр чиксез,
Мөмкинлек кенә кысылган икән...
Күктән йолдызлар җыеп бирергә
Теләк бик зур да, буй кыска, иркәм.

* * *

Аралачы, Бер Ходам,
Языклардан арала...
Намазсыз да, догасыз да
Булдым соңгы арада...

**Гайбәтче**

Ура, суга, җилгәрә
Хәбәрен бар дөньяның.
Өстәп, төяп җибәрә —
Теле комбайн аның...

* * *

Өемне басып керде уй,
Өнемне алды биләп:
Кемгәдер дөнья — бетмәс туй,
Кемне гел тора иләп...

* * *

Арымый арымагач та,
Тынгысыз матдә — кеше...
Тик үзе китеп баргач та
Кала өч көнлек эше.

* * *

Үзәннәр киң, таулар биек,
Диңгез төпсез, күк чиксез...
Урман-дала... Җанвар-киек —
Берни тормый бер «мин»сез...

* * *

Дәва юк, диләр, сагышка...
Авыруым үткесез...
Янып бетеп бара гомер,
Берьялгызым ут-күзсез...

* * *

Яз — яшьлек, гомер иртәсе
Тамчыдан китә ташып...
Диңгезгә барып җитәсе —
Ярлар чакыра — ашык!

* * *

— Кайгырма, — дим, — дөнья фани...
Рух мәңгелек — җан бакый...
Әллә хуплап... әллә болай...
Җил тәрәзәмне шакый...

* * *

Сораган, биргән бер булмас:
Беренчесе икенчесен,
Хәтта тамагы туйса да,
Саран, дип хурлап туймас...

* * *

— Үзем булып калам, — дисең, —
Килми, — дисең, — үзгәрәсем...
— Ач күзеңне — дөньясында
Һәр мизгелдә — үзгә рәсем...

**Сынау көне**

Көтмәгәндә кубар гарасат,
Тончыктырыр күкне корымы...
Күрмәскә дип теләп барысын,
Кайларга төртерсең борының?..

**Ноябрь**

Дымсу томан тора эленеп,
Карга хәтта оча иренеп,
Кояш булып кояш сүрелгән,
Йокы тора күкрәк киереп.

* * *

— Сафлык?.. — Архаизм! — Бозыклыкка
Сылтау табып була теләсәң...
...Оят җиреӊ һичкемгә ят түгел...
...Тапкансың сөйләр сүз, хөрәсән...

* * *

Каршы ярда учак яктылар,
Дулкыннар шул якка чаптылар...
Ярда басып калган ялгызның
Керфек очларын чылаттылар...

* * *

Ала каргадан алганчы
Агарып бетәр чигәң...
Вәгъдәсез — шул ук ялганчы —
Атсыз, йөгәнсез чегән...

* * *

Саташып беткән сәрхушләр

Сапладылармы сине?..
Санга тулмый калмасын дип
Сакладылармы сине?!

* * *

Алиментын эзләт дәүләтеңнең,
Тудырган да ташлап качкан сине...
Берние юк шәрә гаүрәтеннән,
Үтермәкче бары ачтан сине...

* * *

Йөзе шадра шөбһәледер кемгәдер,
Күңеле пакь, син чирканма аңардан...
Күңеле шадра шома битләр элгәре —
Ачулары дөньясына кабарган...

* * *

...кал күңелнең
иң түрендә
шәмәхәле
таңым булып!..

* * *

Язылмаган романын
Сөйләп йөри өзекләп...
Мәңге айнып бетмәс башын
Аннан-моннан төзекләп...

* * *

Чын исеме — Роберт Батуллин,
Тәхәллүсе — Рабит Батулла...
Коръән Кәримне тәфсилләде,
Ул хәзер булды — Аятулла.

**Бишьюллыклар**

Фани дөнья сынар өчен дан, мал бирер,
Әмма чиксез бары вакыт үзе генә.
Югалту һәм табу чиратлашып килер,
Рәхәтенә, хәсрәтенә син түз генә.
Аллана, баллана алма тик көз генә.

* * *

Ялкыныңа ураласым килде,
Ташкыныңда килде агасым.
Уралыплар актым — бәхетемне таптым,
Инде

Күз алмаңда килә каласым!..

* * *

Мине хәзер никтер күкләр тарта,
Күктә әллә күңеллерәкме?

*Ф.Яруллин*

Фәрештәләр хозуры бит ул күк,
Ничек анда булсын күңелсез.
Изгеләрне чакырып тора Гарше,
Шунда
Менәлмәслек шәхес түгел Сез...

* * *

Шөгыльсез үтмәде көнем —
Сугардым гөлләремне.
Шигырьсез үтмәде төнем —
Җаныма елышып гөлләр
Күкләргә үрләделәр!

* * *

Бер дә болай түгел идең,
Нишләтте сине урын?
Гел шунда булырмын диеп,
Эх, ялгышасың, зурым,
Ләгеткә калыр турың.

* * *

...Гомер атым туарылды,
Арбасында җәсәдем...
Кайсы төше бу дөньяның,
Шуны куып
Җитәм диеп яшәдем...

* * *

...Көл, күңел, дөньяның моңы
бер безгә генәмени?

*Р.Фәйзуллин*

Көл инде, күңел, көл инде,
Дөнья ямьсез түгел лә!
...Бер чеметем куаныч та
Шөкер итсәң җитәр иде
Мең тулып түгелергә...

* * *

Көнем өчен Син бар,
Төнем өчен Син бар...
Көннән, төннән торган

Дөньям
Синең өчен ник тар?..

*** * ***

Человек — это звучит гордо!
*М.Горький*

Җир йөзендә сугыш булмый торса,
Чебен-черки күбәя, имеш...
Кешем, ни артыгың шул чебеннән,
Исемең горур яңгыраган килеш?..
Үз хәлеңә төшен дә килеш!..

**Авылда бер кич**

Җырлап үттеләр урамнан
Түбән оч егетләре!..
Өреп чыктылар
Дуамал
Югары очның этләре...

**Тынлык**

Тынлык — могҗиза,
Телим дисәң, син хәтта
Уең агышын,
Карашыңның тавышын
Тыңлар идең тынлыкта...

**Бер карасаң**

Бер карасаң, шәп бу дөнья,
Бер карасаң — күңелсез.
Еларсың да, көләрсең дә, —
Барысын да күрерсең,
Барысына күнәрсең...

**Мин — көзге шигырь...**

Мин — көзге шигырь...
Араламагызчы:
Көзге төскә кереп януымнан;
Янып-ялкынланып азаккача,
Алтын төскә кереп калуымнан!

*** * ***

Кайда туып, кайда торасын
Алдан кемнәр белсен, юрасын?
Фани дөнья, килү-китү дигән,
Әй борылып аккан елга син, —
Яшәү-гомер итү йоласы...

**Болыт**

Болыт, гаеплиләр сине юкка.
Синдәй хезмәтче юк та:
Җәен, каплап кояшны,
Коткарасың пешүдән,
Кышын исә — өшүдән.

**Җәй уртасы**

Сандугачлар тынып калды,
Өндә берни аңламый, —
Урманымда җәй уртасы, —
Кәккүк шуны аңламый,
Бертуктаусыз алдалый...

* * *

...учагымда
дөрләп яна
синең хактагы
уйларым,
күмергә калып.

**Без кем?**

...вакыт һәм киңлектә
хыялымы
йә ихтыярымы
без
кемнеңдер?..

* * *

Урманда көз,
Уйларда көз.
Мөлдерәмә моңсулык.
Бусагада гомер көзем.
Ихтыярым, булчы нык!

* * *

Торган җирнең
Туган җиргә
Тиң газиз түгеллеген
Җиде ятлар арасында
Җиде көндә үк белдем.

* * *

Бер бакча

Дөньялык, —
Керү бар,
Чыгу бар,
Калу юк...

* * *

Өметләр зур, —
Океаннар
Кичәрбез кебек иде.
Юл чыктыкмы «Бисмилла»сыз? —
Көймәбез комга тиде.

* * *

Адәм баласына ни җитми:
Сулар һава, эчәр сумы?
Шәрәме без бүген?
— Ирек җитми, — диде малай...
— Каты кул!.. — диде бабай...

* * *

Таллардан биек таулар бар,
Таулардан биек болытлар,
Болытлардан биек йолдызлар.
Йолдызлардан да биектә
«Әнкәй» дигән Бөек Йолдыз бар.

* * *

Яшәү-үлү арасы —
Күз һәм каш арасыдыр.
Язылганы язмышыма
Авыр таштыр,
Аның да карасыдыр.

* * *

Килмешәкләр килеп, Ак Илемне —
Агыйделне киткәч каралтып,
Туган җирдән аерып еракларга,
Язмыш безне кыйный-кыйный йөртә,
Дөнья буйлап сибеп, таратып...

* * *

Бердәнберем булмасаң да,
Берәгәйлем булдың.
Сикереп чыгып киртәләрне,
Күңелемә тулдың —
Гомерлегем булдың.

* * *

Бу мизгел —
Ташлап дөньяның
ваклыкларын,
юклыкларын,
Сине уйлаган чагым.

* * *

Өзелде тамчы
Сөңге бозның күзеннән...
Раббым, бир түзем, —
Язга бары кул сузым,
Күзе, кышы түзелгән...

* * *

Ятлар күз атты
Төзәп йөрәгеңә үк;
Ятлар сүз атты
Төзәп йөрәгеңә үк...
Үзең — йөрәгемә ук.

* * *

Җир, күк, йолдызлар —
Ноктасы чиксезлекнең...
Газизем, Әнкәем,
Тиңләп шуларга,
Кичерәйтимме Сезне?!

* * *

Ерак тор, Мирза,
Нәфес колы ул заттан;
Дан, шөһрәт өчен
Милләтен, динен саткан...
Пычагын тыгар арттан...

* * *

Бер Хакның ихтыярында:
Мәңгелек тәгәрмәчендә,
Читлектәге тиен кебек,
Әйләнеп тора Кояш, Җир...
...Туктап калмасын берүк!..

* * *

Күңеле каты кителгәнме...
Кызып ташлап кителгәнме?..
Шуңа җиде ят җирләрдә,
Зәһәрдән зәһәр җилләрдә
Гомеркәйләр ителгәнме?..

* * *

Беркем берни белмәс димә,
Беркем берни күрмәс димә...
Кемдер белеп, күреп торыр:
Каптырырга кармагына
Форсат кына көтеп торыр...

* * *

Гөнаһлардан арала, Бер Ходам,
Нәсел-ыру, бала-чаганы...
Саклanганны саклаганың беләм,
Белә торып,
Онытып җибәрәм шул чаманы.

* * *

Көмешкә бактым — күрдем үземне,
Алтынга бактым — күрдем үземне...
Күз алмаңа бактым —
Күзләрем камашты...
Шул көннән белештермим үземне...

* * *

Коммунизмның таңын
Аттырабыз дигәндә,
Таланды да бетте ил,
Таралды да бетте ил.
Ул таң мираж икән лә...

* * *

Мәхәббәттә арадашчы нигә,
Хөкемдар ник кирәк хисләргә?
...Олылыгын ваклау өчен генә,
Хыянәтне аклау өчен генә
Кирәк алар иблисләргә...

**Ветеран агитатор**

*Г.Афзалга ияреп*

Элек нотыклар сөйләдек,
Сулар йота-йота...
Бүлмә салкын, тамак та ач.
Әллә инде шул елларның
Ялганнары тота?..

* * *

*Куштанга*

— Түрәләр янәшәсендә
Йөререм кем юраган?
— Шунда бул, килешә сиңа,
Аккан-тамганны чәлергә
Тиеш кулын юмаган.

* * *

Бер киткән килми —
Үткән гел артта...
Көн үткән саен,
Гомерләр кими,
Үкенү арта...

* * *

Май чүлмәге, диләр,
Тышыннан билгеле...
Бу күмер чүлмәгең
Күршеңнән
Алган идеңме?..

* * *

Кяферлек — шайтан бакчасы,
Чәчелсә бер уч орлык,
Күкрәп үсәр имансызлык;
Оныкларның оныклары
Мең ел тәгам кылырлык.

* * *

*Т.Миңнуллинга*

Таяну ноктасын эзли, таптисәме? —
Уеннан уймак чыгармакта исәбе...
Фатихасын Шекспирның алып ул,
Ат уйната түр сәхнәдә — Алып ул...
Ни әйтмә, татар Туфанлы халык шул!..

* * *

Һәр исемдә шигырь бар.
Исем — җисем бизәге...

Фатиха — Хак ихтыяры:
Әйткәне, үтәлгәне...
Рухны — бөеклегенә,
Иманы биеклегенә
Тиң итеп күтәргәне...

* * *

Үҗәт тырышлык кирәктер

Ни булса майтарырга...
Тама-тама таш ярып та
Булмый икән, булмый икән
Яшьлекне кайтарырга...

* * *

Вакыт — матдәнең беренчел
Сан, сыйфат берәмлеге...
Галәмнең тирән төбеннән,
Үткәннән килер көненә
Сузылып кергәнлеге...

* * *

Ут — матдәнең кайчан да бер
Әвереләчәк хәле...
Вулкан-таулар эчләрендә,
Күкнең чиксез чикләрендә
Дөрләп яначак мәле...

* * *

Сүрелде дә... сүнде учак, —
Өелеп калды көле...
Җил себереп үтәр берчак:
Күчеп киткән авыл кебек
Караеп калыр төбе...

* * *

Ишенә куш булалган —
Бәхетенә кинәнгән...
Ишеннән борын чөйгән —
Үрелеп өзә алмаган
Чикләвеген имәннән...

* * *

Кайчан да булса китәсе,
Көттереп торма озак...
Кисел бу шакшы дөньядан,
Коллыкта калдырырга дип,
Корганчы шайтан тозак...

**АДӘМ БАЛАСЫНА**

* * *

...Тәннең китәсе юк,
Җанның каласы юк...
Адәм баласының
Шуны үзгәртерлек
Һичбер чарасы юк...

* * *

...Данлау, мактау бары
Шайтан имезлеге...
Адәм баласының
Дулап дауламасын
Өчен тигезлеген...

* * *

...Барысы буйсынган
Көтү Анасы бар...
Адәм баласына
Карусыз бүредән
Гыйбрәт аласы бар...

* * *

...Ялган дәрәҗә, дан —
Салпы якка салам...
Адәм баласына
Масаеп азсынга
Шайтан сузган хәрам...

* * *

...Бозлык чорында да
Тәнне тән җылыткан...
Адәм баласына
Ана сөте белән
Керерен җен йоткан...

* * *

Алашага — тышау...
Айгырга — арата.
Адәм баласының
Башында бармы уй
Шул хәлгә карата?

* * *

Хөрмә һәм Хур кызы —
Оҗмах җимешләре...
Адәм баласының
Күңле шайтан коткы-
сында килеш әле...

* * *

Кешелек — чоңгылда:
Бик астан менәре...

Адәм баласының
Җан кыюдан ары
Юк оста һөнәре...

* * *

Хәләл гомер иткән
Тәмугта янмаган...
Адәм баласының
Нәфсе мәңге чикмәс
Тыелган алмадан.

* * *

...Хатадан хали зат —
Кул кушрып утырган...
Адәм баласының
Басып торганы да
Йөз еглып, йөз торган...

* * *

...Туган туганыннан
Йөз чөергән заман...
Адәм баласына
Бәхет чит-ятлардан
Явар сыман һаман...

* * *

...Таңнар атып торыр,
Кояш батып торыр...
Адәм баласының
Әрәм гомеренә
Күк шаккатып торыр...

* * *

...Сөю — канның, җанның
Шашып котыруы...
Адәм баласының
Шул татлы газаптан
Юктыр котылуы...

* * *

Нәфесен тыялган —
Күңеле камил зат.
Адәм баласына
Гап-гади хакыйкать
Нилектән шулай ят?

* * *

Һәркемнән шикләнгән —
Үзенә бикләнгән...
Адәм баласының
Килере-табары
Учында чикләнгән...

* * *

«Дөнья куласасы —
Әйләнеп басасы...»
Адәм баласына
Әллә шуны язып
Муйнына асасы?!

* * *

Тугры юл — савапка,
Кыек юл — газапка...
Адәм баласының
Кыйбласызлыгы
Газаплы азакка...

* * *

Дошманлык — шайтанның
Җәтмәсен корышы...
Адәм баласының
Бер-берсен каргашып,
Орышып торышы...

* * *

Хиссез мәгънә — таштыр,
Уйны уй буташтыр...
Адәм баласының
Шигырьле мизгеле —
Күкләргә тоташтыр...

* * *

Кошлар ел да кайтып
Кора үз оясын...
Адәм баласына,
Оятын уятып,
Куышын корасы!..

* * *

Урман, дала, кырда
Кыргый эт көтүе...
Адәм баласының
Көтеп йөриме алар
Мур кырып бетүен?

* * *

Туган туфрагыннан
Көчләп кубарылган
Адәм баласының
Юк кайтыр Ватаны,
Аты тугарылган.

* * *

Хәер акчасын да
Алыр иде көрәп...
Адәм баласының
Чүпле бакчасында
Сынык саплы көрәк...

* * *

...Нәфесе чигенгән
Һәр адым җаваплы...
Адәм баласының
Чамасы чигеннән
Чыкмавы саваплы...

* * *

Вөждан мыскалында
Явызлык, игелек...
Адәм баласының
Уе корсагында
Шул әле иң элек...

* * *

Эт — дус, бүре — дошман.
Һич юк бутасы...
Адәм баласының
Теккән эт тиресе
Бүреге, унтасы...

* * *

Козгын тавышында
Фаразның шомлысы...
Адәм баласының
Җирдә шүрләп үтә
Бер карыш тормышы.

* * *

Хәерче илнең дә
Үзенчә бае бар...
Адәм баласының
Бер-берсе әҗерен

Чәлергә җае бар.

* * *

Күтеп килмәс бәхет,
Көтми килер кайгы...
Адәм баласының
Үтәрме бер көне
Шул хәленнән айры?

* * *

Арты — каз мендәрдә,
Телендә — бал да май...
Адәм баласының
Картайган көннәрдә
Чалма, чапаны — җай!..

* * *

Көләргә теләсәң,
Бетәрме хөрәсән?..
Адәм баласының
Һәрберсе эч катып
Көләрлек бер әсәр...

* * *

Кызыл шигырь язып
Дан-шөһрәт казанган
Адәм баласының
Иҗатын җирлиләр
Үзеннән алдарак...

* * *

Ай тотылган төндә
Күңелне шом баса...
Адәм баласының
Бердәнбер тугыры
Юлдашы шул ласа...

* * *

Гел корбаннан тора
Җирдәге тормышы...
Адәм баласының
Чарасызлыгымы
Тормышын кормышы?..

* * *

Ике дөньяда да

Мал, дан бүлеше бар...
Адәм баласының
Савабынча табар
Алтын-көмеше бар...

* * *

Байлык — бер айлыктыр,
Ярлылык — гомерлек...
Адәм баласына
Бетмәс байлык — Иман,
Оҗмахка керерлек!

* * *

Тиранны астылар —
Хөкемдарга хөкем...
Адәм баласына
Юкса күпме гасыр
Кисәтелде бу көн!..

* * *

Язып асыйкмы дип
«Мирас орлыгыннан»...
Адәм баласына
Котылу насыйпмы
Нәфсе коллыгыннан?..

* * *

Үзендә булмаса,
Ничек тә ул түзәр...
Адәм баласының
Көндәше мал тапса,
Эчтән телеп өзәр...

* * *

Мыскалга салынган
Дөнья малы, гаме...
Адәм баласына
Шайтан сузып тора
Тыелган тәгамне...

* * *

Ярда яткан балык —
Нибары үләксә...
Адәм баласының
Хәле шул балыктай,
Чит ярга эләксә...

* * *

Гап-гади тәгәрмәч
Киткәнче тәгәрәп...
Адәм баласына
Мәгарәдән чыгу
Бойрылды элгәрәк...

* * *

Басынкы бу инеш
Язларда ярсулы...
Адәм баласының
Гомре шуңарга иш:
Ярлы һәм ташулы...

* * *

Соңгы барыш — зират,
Соңгы кичү — сират...
Адәм балалары
Сабыр итеп баскан
Иң беренче чират.

**Алтыюллыклар**

* * *

Кем чигеп үргән читән бу,
Кем йөреп салган сукмак?
Яр ярылып аерылган —
Ишелми калган туктап.
Өзелмәгән бер тамырдан
Тал курпы килә сутлап...

* * *

Үргә аккан чишмә суын
Күреп хәйран калганым бар,
Үргә аккан инеш-суга
Карап күзем талганы бар...
...Табигатьнең без белмәгән
Илаһи бер ялганы бар...

* * *

Куначаңа җеннәр оялаган,
Асып куйган купшы пәрдәсен.
Дәрәҗәңдә күпме күтәрелмә,
Рухың белән бары кәрлә син.
Инде килер көнең нинди дисәң,
Ярда яткан балык хәлдә син...

* * *

*Бер түрәчеккә*

Эткә ыргыткан бер сөяк—
Бүген тоткан тәхетең.
Тәхетленең артын сөртү
Булды бөтен бәхетең...
...Түмгәк булып та калмассың,
Ишелгәчтен ләхетең...

* * *

Нидер язмак булып утырам да...
Исемеңне язып куямын...
Ак бит тула синең исем белән,
Бүлмәм тула синең исем белән,
Үзеңне дә янда тоямын...
Син берүзең — шигъри дөньяммы?

* * *

Сынды җәй —
Сарылды
Сарылык...
Сулды гөл:
Сабырлык,
Сабырлык...

**Таш, боз явып торса да...**

Бәйрәм көне дә аңа гел кырын:
Кышын дулап буран котырыр;
Яз, күз сыктап явар җепшек кар;
Җәен яңгыр яшенләп кояр...
Таш, боз явып торса да торыр,
Сабан туен татар уздырыр!..

* * *

Җилләрдә җиллэт кереңне,
Юл өйрәт юлаучыга...
Яттан йозакла сереңне,
Ерак тор юраучыдан...
Савабы булыр йә булмас...
Хәер бир сораучыга...

* * *

Кырлач буе яңгыр койды,
Күрмәгән ышанмас та...
Килде дә керде бу тойгы —
Күңелләр сискәнеп куйды:
Кешем, ниләр кылыр идең,
Кырлач килсә ыспаста?..

* * *

Нур очына кунып,
Урап кайтсам әгәр
Киләчәктән,
Сөенерме күңел?
Әллә көенерме
Күрәчәктән?

**Сүз соңы — нокта**

Ни йөртә кешене
Әле анда, әле монда?
Форсат-җай эзләү эшеме,
Ил-йорты, килер төшеме?..
Сорауның чиге юк та,
Әйтер сүз соңы — нокта...

*** * ***

Теләгәндерме берәрсе
Теткәләнсен дип җаны;
Көтмәгәндер дә, күрәсең,
Шулай түзем торасымны.
Югалтканнар гына белер
Яшеренеп еласымны.

**Айсылуга**

Ачыласы күпме
Йолдызлар бар күктә,
Сабыр гына көтә үз чиратын.
Ышан, көт, өметлән,
Ләкин һич сүндермә
Учагың — өметең —
чылатып!

*** * ***

Кунак кына булган
Бу җиһанда
Мәңге һичкем калмый.
— Күңелемне юам,
Иман җыям:
Җан хакы да бар, дим.

**Ил бәхете**

Һәркем
Бәхетле тик шул чакта:
Илең булса иректе;
Ил агаң — игелекле;
Туган — бергә тиң-тигез;
Торган җир булса газиз.

**Өмет**

Ялгызлык — явыз чир,
Теләгел бәгырьне.
Кызганма, кыйнасын, кыйнасын.
Көткәнем үткәннән
Барыбер кадерле,
Өметем — яшәвем кыйбласы.

* * *

Килер көннәр
Кайчан да бер
Очраштырса безнең сукмакны,
Шул мизгелдә
Мин вакытны
Торыр идем мәңге туктатып...

**Ир-ат**

Тимер куллар
Тимер атлар
Таптылар да уйлап,
Мыскылланып,
Мескенләнеп
Калды җирдә ир-ат...

**Әбугалисина**

Башын тоткан,
Аптырашта
Әбугалисина:
— Кая киткән
Мең ел элек
Булган медицина?

* * *

Акны ак дидек,
Караны — кара.
Хәләл хак бирдек,
Карап:
Дөнья малына
Һәм дүрт ягына...

**Белсәгез иде**

— Чакырылмаган кунак
Татардан яманрак, —
Дип әйткән, ди урыслар...
— Китә белмәгән кунак
Яманнан яманрак —
Белсәгез иде, дуслар...

* * *

Тама-тама таш ярсак та:
Төш чыкмады эченнән...
Потлап-потлап тир аккан да,
Мичкәләп су эчелгән...
...Өлкән туган өчен эшләп,
Гомеркәйләр кичелгән...

* * *

Әле дөнья ялгыда...
Тудырыр кем тулгагы!..
Кендеген бәйләп кисәргә
Кем кулы булыр тагы?..
Анык белеп, күреп тора
Хак Хода үзе бары...

* * *

И Ханбикә, исемеңне таплададылар,
Синнән яман гаеплене тапмадылар...
Хакыйкатьтә: күрәләтә яла ягып,
Үзләренең хыянәтен акладылар...
...Тарихында шөһрәт тоткан шул халыкны,
Тары ярмасына тиңләп вакладылар...

* * *

Кырлач таң шәмәхәсендә
Бердәнбер уяу — Чулпан...
Сыкыдан сырган юрганын
Ябып җир төнгә чумган...
...Йокысыз чыккан бүлмәмнең
Тәрәзенә җәй сызган...

* * *

Агыйделнең аръягыннан
Таң җиле куйды исеп...
Бозга төрелгән талларның
Итәк-җиңнәрен кисеп...
...Бөреләр сузды иренен...
Бизәнми калсын ничек!..

* * *

...Хәбәрләр... төрледән төрле...
Әйтелгәне, язганы...
Үзара нокта-өтерле.
Бар чыны, бар ялганы...
...Әйткән түгел... ишеткәннән
Колакны кызартканы...

**Бу баш**

Сылудан да сылуракны эзли Күз;
Тел туктаусыз сөйләп тора ялган сүз;
— Зурысын?! — дип ачылган азгын Авыз;
Гел мактауны көтеп тора пар Колак:
— Никадәрле әрәмтамак үрчеттем?! — дип,
Башын кашып тора бу Баш, аптырап...

**Килмәс димә...**

Түшеңә орден-медальләр тагарсың,
Мәҗлесләрдән мәҗлесләргә барырсың...
Күтелмәгән хөрмәтләргә торырсың.
Булган-булмаганны сөйләп арырсың.
— Мин минме? — дип, күзләргә багарсың...
Сакаллы сабый хәлендә калырсың...

**Бәлки**

Кемнедер кимсетер булсаң...
Орынма каләмеңә...
Сүзеңә түгел, кешеләр
Ышаныр гамәлеңә...
Дәшми кала алу бүген —
Татулык әмәле дә?..

*** * ***

Хакимият — хак өммият,
Алып килер дип хөррият,
Җиткерсә дә халык зарын...
Хакыйкатьтә булып чыкты
Ул рәхимсез хөкемият:
Кырып талап алды барын...

*** * ***

...Балта башта ук
баш чабар өчен
уйлап табылган...
Ничә чабасы:
йөз үткенлеге
һәм дә сабыннан...

*** * ***

Арыган атка
Атландың ни дә
Атланмадың ни?!
Ал биргәч ятка,
Акландың ни дә
Акланмадың ни?!

**Җидеюллыклар**

* * *

Болыт куерып каралды.
Томан куерып агарды... —
Болытлы, томанлы иртә...
Каеннар тора караеп.
Күңелем калды сагаеп, —
Күк адаштырып кояшны
Кайларда йөртә?

* * *

Агыйделне боз тоткандыр,
Йокыга талгандыр яры...
Тал-курасын сызгырткандыр
Кышның беренче бураны...
...Ялгызым калган бу төндә,
Бәсле тәрәзәмә багып,
Уйлап утырам шуларны...

* * *

*Зәнфирәгә*

Заманына карап туа
Әйтер сүз, җырлар җыры...
«Ни чәчсәң — шуны урырсың!» —
Фәлсәфи ягы шулдыр:
Исән чакта ниләр кылсаң,
Раббың каршысына басып
Әйтәсең булыр туры!..

* * *

Эчемдәге
тышымда, дип
лаф органнан
ерак тор син:
исенә һәм
төсенә бит
буялырсың...

**Сигезьюллыклар**

* * *

...Халыклар,
дәүләтләр
хакында
күзаллап,
гөманлап
яза ала
тик татар
әдибе...

* * *

Әткәң-әнкәң фатихасы
Имин итәр ил-көнеңне,
Рухлары нурга коенсын!..
Үткелләрне үткәндә дә,
Зилзиләләр искәндә дә
Куллары җылысын тоярсың...
Әткәң-әнкәң фатихасы—
Һәрчак шуларга сыен Син!..

* * *

Ак болыт кичте Иделне,
Табанын да чылатмый.
Йомшак җил үтте йөгереп,
Бер дулкын да чыгартмый.
Торналар очып үттеләр,
Аккошлар, кыр казлары.
Хәтеренә чорный Идел
Төсләрен, авазларын...

* * *

Кичерегез мине, зинһар өчен,
Язылмыйча калган җырларым,
Мин адашып читтә озак йөрдем,
Инде кайтып гафу сорадым:
— Кичерегез, зинһар, газәлләрем,
Хәнкәлләрем, дүртьюллыкларым,
Китмәскә дип кайттым, газәлләрем!
Тик сез генә чит-ят итмәгез,
Язылмыйча калган җырларым...

* * *

...Почмаклар:
текә маңгайлы,
кылыч борынлы,
пычактай үткен,
сөңгедәй очлы;
теләсәң сыенырга
йә калырга качып,
никадәрле
үзгәрергә кирәк
шуларга яраклашып?..

* * *

— Шигырь шөгылеңме? — дисең,
Шөгыль бит ул — кул эше.
Шигырь, дустым, Илаһының
Җанга өргән сулышы!
Чиксезлекнең аһәңе ул,
Мәңгелекнең агышы!
— Шигырь шөгылеңме? — дисең,
Бу — гөнаһсыз ялгышың...

* * *

Урам тутырып үттеләр,
Үр ягына киттеләр...
Артларыннан үкси-үкси
Өреп барды бер көчек...
Гүргә илтеп керттеләр...
Китә бара кеше
Үр-гомерләрен кичеп...
Озатып калыр кем, ничек?

* * *

Йөзләгән күз багып торсын әле
Сулыш алмый тынып калуларын...
Чайкалмасын, тоныкмасын дип,
Чүгеп чишмәдән су алуларын...
Мөлдерәмә тулы чиләгенә
Кояшны хәтта учлап салды...
Чишмә читендәге чуерташка
Яшь кәләшнең шатлык яше тамды...

**Аны гына күзлим**

Күркәмлекне, шундый гүзәллекне
Табигать һич юкка бирмәгән;
Белмим, кайчангача түзәрмендер, —
Аны гына күзлим иртәдән.
Әлегәчә йөрим сиздермичә,
Рәхмәтеңнән, Тәңрем, ташлама;
Инде белмим ниләр эшләремне, —
Язлар быел иртә башлана...

**И күңел...**

Әрнемә, рәнҗемә, и күңел,
«Беткән бу», — димәсен берәрсе.
Дәвере болганчык, белмәссең,
Уткамы, сугамы керәсе...

Язмышларны язган без түгел,
Әрнемә, рәнҗемә, и күңел,
Безгәчә килгәннәр, киткәннәр,
Димәк, без дә мәңгелек түгел.

* * *

Аркалары белән әйләнеп яткан
Коелган тал яфраклары күл өстендә...
Офык читендә болытларга ут капкан:
әллә кояш баткан,
әллә таң аткан.
Бераздан шәфәкъ-кызыллык
югалыр эреп:
төнгәме,
көнгәме?

**Кызыл кар явар микән**

Кыйбласызларга
Кай яктан
Чыкса да Кояш — барыбер;
(Аркаларын җылытырга
Борылып яту да җитә.)
Уйларымны бутады гел
Офык читендәге кызыл шәфәкъ:
Явармы кызыл кар бирегә?..

**И сабый**

Колагыңа
Иман сүзе
Пышылдадым,
И сабый...
Аңладыңмы,
Болай гына
Елмайдыңмы,
И сабый?!

* * *

Гомерләрнең көзе түгел,
Җәйге чагы,
Дөнья йөге арбасына
Бәйле чагы.
Үргә менеп, каерылып
Бер карагач:
— Сөбханалла, иншалла! — дип
Әйтер чагы.

* * *

Минем хыял —
Агыйделнең
Аръягында
Болындыр.
Бар теләгәнем —
Болындагы
Ак тояклы
Колындыр...

**Моң**

Җаннан бүленгән халәт — моң,
Җаннарга җитәр өчен.
Җырга-көйгә әверелеп,
Галәмгә китәр өчен...
Җаныңны тыңлап кара да
Моңлан әле, и кешем.
Дөнья фани. Моңлы мизгел —
Мәңгелекнең бер төше...

* * *

Уеңда ни, гамәлеңдә,
Каләмеңнән ни тама?
Барлап, белеп тора галәм —
Бер кыенлык юк аңа...
Тели — бора сине уңга,
Тели — сулдан җибәрә...
Чыгарганчы туры юлга
Җилләрендә җилгәрә...

**Җил генә...**

Яфраклар ни сөйли җилгә:
Аркаларын ачып?..
Чәчәкләр ни сөйли җилгә:
Ятып бетеп җиргә?..
...Беркем беркемгә кичерми
мәҗбүри мохтаҗлык...
...Җил генә куя таләбен,
карамый бернигә?

* * *

Үзеннән өстен бер көнне
Шәүләсенә басылыр...
Үзен өскә чөйгән телен
Тешләп түбән асылыр...
Гыйбрәтләнер өчен мисал
Юк ерактан эзләсе...
Әүвәл үзем өчен шушы
Сигез юлның тезмәсе...

* * *

«Кайту ягы якынрак», —
Таныш сукмак, янәсе...
Ничә тапкыр узып киттем
Авылымнан янәшә...
...Чалманарат, кайтасым бар
бәхиллегеңне сорап...
Китү-кайту дөньясында
Ара якын, юл ерак...

* * *

Сандугач өзә... өзелә,
Алыр кем үтеп ары...
Сабыен алып тезенә
Иркәли-сөя бары...
Җәйләр авышкач көзенә,
Кинәттән туктап калыр...
Баласын очырган көне
Ярты гомерен алыр...

* * *

Каракның кулын кискәннәр,
Ялганчының — телен...
Иманнан ваз кичкәннәрне
Яндырганнар тере...
Уйнаш, ришвәт төрләрнең
Төшмәгән түреннән.
Меңнәрчә ел ук электән
Бүгенге күренгән...

# ТУЛГАН АЙГА КАРАП

## АККОШ КҮЛЕНДӘ

Җәйге иртә... Чап-чал Туфан
Гөлләр белән сөйләшеп...
Аккош күле аланында
Йөри тиңләп, серләшеп.

Каен, чыршы, һәр куакны
Иркәләп үтә, назлап:
Гүя чакырып кунакка
Дусларын җыеп алган...

Шигырь укый салмак кына:
Мөкиббәндә гөлләре.
Шагыйрьнең ашкынып юлга
Чыгып китәр көннәре...

Арымаса армый икән
Озын, озак сәфәрдән.
Дәрвиш булып килгән җиргә,
Ни көтәсең Хәсәннән...

Ул үтәсе чакрымнарны,
Инеш, күлләр, даланы
Кем үтәр хәбәр җиткереп,
Туар чорлар катына:
Ул җырларын бәйләп бара
Тургайлар канатына,

Ак болытка урап куя,
Менгерә кыя-тауга,
Шигырь чәчеп йөри Туфан
Дала, үзән, тугайда.

Шытып чыгарлар гөл булып,
Дөньясы шау чәчәккә
Күмелер дә, ни могҗиза —
Барсы калыр гаҗәпкә.

Таш кыяда бердәнбер гөл:
Ул Туфан җыры булыр;
Котыпта бердәнбер куак;
Ул Туфан җыры булыр;
Чүлдә явар беркөн тулып:

Ул Туфан җыры булыр,
Оныклары тагын мең ел
Шигырь чәчеп, җыр урыр!..

Әлегә Аккош күлендә,
Гөлләргә сак кагылып,
Шигырь сөйләп йөри Туфан,
Дәрвишлеген сагынып...

**КЕМНЕҢ ДӘ БУЛСА БАРЫБЕР**

Ихтыярсызмын бүген дә
Уйларымның иркендә...
Йолдызлар тулган күгендә...
Юллар шунда илтер дә...

Ихтыярсыз килгәнмен дә
Шулай тагын китәрмен...
Кемнедер бик тә бәхетле
Йә бәхетсез итәрмен...

Сизми дә калырлар әле:
Эрермен, югалырмын...
Кемнең дә булса барыбыр
Хәтерендә калырмын...

Тавышымны, карашымны,
Буй-сынымны төсмерләп: —
Кайдадыр күргәнем бар, — дип
Сорарлар берәрсеннән...

...Чарасыз кеше гомергә.
Күкләр ала үзенә...
Сызган бер кашы түгел лә,
Һичкем дөнья күзенә...

Китәрбез... китеп торалар,
Әйтәлми әйтерен дә...
Кемнең дә булса барыбыр
Калырбыз хәтерендә...
*** * ***

Кояш — бер генә...
Күпме балкысаң да —
Алыштыра алмассың...
(Ул да оялып, кызарып,
Офык артына кача...)
Ай — бер генә...
Ул да: бер тула,
Бер юылып бетә...
Кеше булуга
Ни җитә?

**БАБАҢ МОНОЛОГЫ**

— Ш-ш! Шом... Шик:
Күршедә — шпик...
Кем кемнән
Алданрак
Шалтыратыр?

Соңармавың
Хәерле бик!..
Җитмеш ел
Узгач та
Хәтергә төшә ник?..
— Ш-ш???

* * *

Өреп кабасын оныткан
Авызлар пешә тора.
Биргән вәгъдәсен оныткан
Түрәләр төшә тора.
Алар урынын дәгъвалап,
Өшегән-пешкән авызлар
Ызгыш-җәнҗаллар кора...
— Ни белән бетәр бу? — диеп,
Гыйбрәтле шул тамашаны
Күкләр күзәтеп тора...
Күкләр төз атып тора...

* * *

Карында яткан бер үк яралгы,
Тамырда ага бер ата каны...
Үчкә тарыган ике бертуган:
Төне караңгы, көне караңгы...
Хакның каргышы тоткан аларны...

Сак белән Сокның ишләре булып
Мәңгелек базда алар калырмы,
Әллә бер таңда тәүбәгә килеп,
Алар күгендә кара болытлар
Бер таралырмы, ярлыкалынып?..

## МӘСӘЛ

— Мә! — диделәр, — сөбханалла:
Тип-тигез аңкауларына
Фәрештәләр ап-актан
Энҗеләр тезеп китте!..

— Бир! — диделәр. Йа Раббым бер:
Әрекмәндәй колагына
Такыр табаны белән
Карт аю басып китте...

Күреп торып шул хәлләрне
Язарга насыйп итте...

## XXI ГАСЫР

*Заман антропологларына*

Күз белән каш арасы
Үлчәмендә үзгәлек...
Кайсы кавем баласы
Беләсеңне килсә бик,

Син аларга барырсың
Баш «үлчәмен» алырсың:
«Асаба кавем» диеп,
Язып бирер берәрсе...
Еларсың һәм көләрсең...

**ЧОРЫ БАШКА, ҖЫР БҮТӘН...**

— Китәмен, — дисең, — ерак,
Каласың, — дисең, — елап... —
Булгандыр шундый чорлар...
Җылы оя буш тормый...
Юлда яфрак кыштырдый.
Үзгәрде инде чорлар...
Җырлана үзгә җырлар:

— Алын ал итәсең бар,
Гөлен гөл итәсең бар.
Син үстергән бакчада,
Алга, гөлгә уралып,
Кемдер гамь итәсе бар...

* * *

Хак тарихны Бер Хак белә,
Галимнәр — гоманлыйлар...
Кайсы — белеп, кайсы белми
Күзгә карап алдыйлар.

Болгар — бөек, Урда — алтын...
Казна тулы Казаны,
Бар юллар шушында илткән...
Үзәк — дөнья базары.

Алыплары, шагыйрьләре
Дан-шөһрәтләр казанып,
Шаккатырган бу халыкның
Тарихы ни, азагы?
Каргыш тоткан, ул кичерә
Инкыйразы газабын...

* * *

Йә, ничекләр түзде икән,
Әнкәй безне бакканда,
Унберебез унбер яктан
Итәгеннән тартканда?..
Йә, ничек җиткерде икән,
Әткәй безне туйдырып?..
Хәтеремдә: кыш чыгайдек
Ике елкы суйдырып.

Әткәй-әнкәй күптәннән юк...
Хәтердә гел, хәтердә...
Тик бер көнгә кайтсыннар иде:

— Кичер! — диеп әйтергә?..

**ЮМАРТ ПАТША КӨТЕП ЯТЫП...**

Төш — өн уе:
 теләгәнең
килеп керә,
тормый сорап.
Аннан: һәркем
йөри шуны
чынга юрап...
Тавык — ярма,
балык — селәү,
буйдак — хатын,
халык юмарт
патша көтә...
Көтә-көтә
тәмам көтек
булып бетә...

Җимен капкач,
килә каба
балык — ярда,
аны көтә
майлы таба;

Савыт — тавык
сорап тора
закускага;

Буйдак буйдак
булып кала,
юлыкканчы
бер ятакка...
Һәм бер хата:
буйдаклыкка
куя нокта...

Юмарт патша
дигәне гел
һаман төштә
кала бирә...
— Нинди җай бар,
нинди җим бар,
аны бер чак
каптырырга?
— Халкым, — диеп
чаптырырга;
үзеннән күп
арттырырга;
балалары,
туганына
тиң итеп
яраттырырга???
— Әлдә йокы
бар әле, — дип
куанабыз
күреп кайчак
татлы төшләр;
Тавык ярма
ярып йөри;

балык чума,
йөзә суда;
юмарт патша
көтеп һаман,
безнең генә
яшәүләр ни
туда-сюда?!

**БОЛЬНИЦАДА ИШЕТКӘННӘР,
ЯКИ ЗАМАНА ТАКМАКЛАРЫ**

— Гәҗитләрдә хәбәрләр ни?
Ничек һава торышы?..
— Тынмый һаман татарларның
Галимнәре орышы...

— Нәрсә бүлешәләр тагын,
Гомерлек хәерчеләр?
— Шайтан белсен: берсен берсе
батыра нәҗесенә...

— Юкмыни шуларны җыеп,
Иманга өндәүчеләр?
— Алар үзләре ызгышта,
бер-берсен күрмәүчеләр...

— Кая карый пәйгамбәргә
Тиң күргән аксакаллар?
— Үзләре көн-төн талашта,
акылга аксак алар...

— Кая карый әдипләре,
рәссам вә көйчеләр?
— Кайсы эчә баш күтәрми,
бар битараф, көнчеләр...

— Нәрсә карый яңа байлар,
депутатлар, түрәләр?
— Алар да канлы көрәштә
Көн дә берсен күмәләр...

— Кайда безнең абыстайлар,
Ак әби, ак апалар?
— Бу хәлләрне — шәп сириал
карыйбыз! — дип яталар.

— Кая карый өлкән брат,
Юкмыни һичбер чара?
— Яклау эзләп бөтенесе
Шул Мәскәүләргә чаба...

**КАЕН КАЙГЫ КИТЕРӘМЕ?**

Каен утыртма, — диделәр, —
ихатаң эчләренә,
Үтмәс кайгылар төшәр, — дип, —
гомергә эчләреңә...

Каеннарыма сарылып,
елаган еллар булды...

Сөю, назларга тарыгып,
бәхетле чорлар булды...

Каен кайгы китердеме,
бәхетме бөреләнде?..
Мин аларга һичбер кайчан
авыр сүз тидермәдем.

Күрәселәр тәкъдиреңә
язылып куйган күктән...
Үткәнемә үкенмимен,
килерем көтмим күктән.

Тәгам иткән валчыгым да
хәләл табылган — инан...
Каһәрләп ташлап китмәде,
Җанымда булды иман...

Каен кайгы китерәме?
Сынап карасын һәркем...
Күкләрдән көтмим килерем,
Күккә китәрмен беркөн...

**ИНКАРЬ ИТЕП КАРА ШУНЫ**

Күрәзәче, багучылар
күрми, белми димәс идем:
Түрәләр дә качып кына
аларга гел килмәс иде.

Имче кулы сырхаулардан
араламый димәс идем:
Мең чакырым араларны
үтеп, гарип килмәс иде...

Күкләрдә, чиксез галәмдә
безгә тиң юк димәс идем:
Йолдызлардан нурлар булып,
Җиргә хәбәр иңмәс иде...

Җирдә, күктә һәрнәрсәне
пар яраткан Иҗатчыбыз
ихтыяры: «Бар бул» дигән
бер сүз җиткән, — без булганбыз!
...Инкарь итеп кара шуны!

**САБЫЙЛЫК ХАТИРӘСЕ**

Түрдә — киштә, бер очында:
Ашъяулыкка төйнәлмичә
Эпекәй төреп куелган;
Бер очында: ак яулыкка,
Дүрт почмагыннан төйнәлеп,
Сабаклар төреп куелган...
Әнкәйдән һәм Әбекәйдән:
— Рөхсәтсез кагылмаска! —
Колакка киртеп куелган...

**ИБЛИС**

Йомшак җәеп каты утырта ул,
аяламый калган һәркемне...
Дус-туганны каршы котырта ул,
сукыр тиен өчен һәркөнне.

Зиһеннәрен җуеп кына ала,
хәтерләрен үтә чуалтып.
Тарих төпкелендә батып кала
халыклар үз юлын югалтып.

Хаким, галимнәрен саташтыра,
Иман-кыйбласыннан яздыра...
Барысын җыеп маңкортлаштыра,
килер буыннарын аздыра...

**БУЛГАНЫ, БУЛМАГАНЫ**

Барын барлап торып була,
Югын да була табып...
Үткәнне күзаллап була:
Хәтердәген актарып...

Фаразлап була килерең...
Үрелеп буй җитмәсне
Өзеп, кабып, йотып була —
Һич тә исең китмәсен:
Тимердән су сыгып була...
Йолдызларның арасы
Чакрымына чыгып була —
Үҗәт ният чарасы...

Булмаганы: дөньясында
Барсын бергә майтарып
Бирсәң дә, ала алмассың
Яшьлегеңне кайтарып?!
— Эх!..

*** * ***

Скифлар — ерак бабайлар,
шанлы тарих арбасыннан
барыбер төшеп калганнар...
Ике дистә гасырдан соң
оныклары сабак алсын
дип әйтеп ниләр кыласың:
таралганнар, югалганнар?..

Болгарлар — ерак бабайлар,
тагын сибелеп беткәннәр...
Шул хәленә төшүләрен
кемнәрдер бик тә көткәннәр...
Ятып ауган шәһәрләрнең
көлләрен җилләр сипкәннәр...
Сәбәбен кем төшенгәндер?..

Казан ауганда бабайлар
бүлгәләнеп кырылганнар...
Казан-суның ярлары да
оешкан кан тутыгына
буылып гел тыгылганнар...

Биләгән тау, дала, кырда
өелеп калган курганнар?..

Гасырларның аръягыннан
саркып тора сагышлы моң:
искәртә ул, кисәтә ул...
Дөньяның шул куласасы
кинәт әйләнеп басарын...
Оныкларга әманәте —
Сакларга татар ыстанын...

**ҖИЛНЕҢ ЭЗЛӘГӘНЕ**

Җилнең эзләгәне бер кура,
Ышанмасаң үзеннән сора...
Табып алса, үтеп керә дә,
Кылын кылга тартып өрә дә,
Мең авазлы моңлы көй чыга:
Нур булып галәмгә тарала,
Күк балкышы моңнан ярала...

Җилнең эзләгәне бер кура...
Түр бакчада ярык йөз кура,
Җил кагылса, чинап зар чыга,
Зарга ияреп тагы әр чыга.
Ятлар ярып киткән куралар,
Ятлар ягып киткән куралар...
Җил кагылса, елап зыр чыга...

Җилнең эзләгәне бер кура...
Үр артында бер мең гүр тора...
Гүр өстендә ярык мең кура.
Җил кагылса, мөгрәп мур чыга...
Җилгә мурлы кура кирәкми,
Мең моңлы бер кура эзли ул,
Табарына өмет өзми ул...
Җилгә, Җиргә кирәк бер кура.

**ГОМЕР ИТКӘН ҺӘР КӨН — БӘХЕТ!**

*(1941 елда туганнар монологы)*

Илдә сугыш бара иде
без дөньяга килгәндә,
көн дә хәтәр хәбәр өйгә
дәһшәт булып иңгәндә...

Тәпи-тәпи йөреп киттек,
тик әткәйләр күрмәде...
Егылдык та торып бастык —
бары алга үрләдек.

Яздан — көзгә — яланаяк...
Буразнада балачак...
Кәлҗемәсе, юа ашы...
Хәтердә нык калачак...

Уелды үлмәс җыр булып
күңелгә Җиңү көне!!!
— Улым, — дип, әткәйнең тәү кат

кулына алган көне...

Шулай танытты чынбарлык,
корычтай чыныктырды...
Шуңа да нык безнең буын,
ихлас һәм җырлы-моңлы!..

Хурланмыйбыз, хурламыйбыз
гомер иткән заманны...
Хәрабәдән күтәрелеп
төзедек өр-яңаны!

Гомергә булдык Хәләлнең
бердәнбер кадерлесе...
Шуның белән без бәхетле —
аңларга әзерме сез?!

Гомер иткән һәр көн бәхет,
хәләл хакың белгәндә!..
Илдә сугыш бара иде
без дөньяга килгәндә...

**ЮАТЫП НИ ӘЙТӘ АЛАМ?**

Ананың сулган күзләре...
Толымы көмеш кенә...
Бала кайгысы күргәнне
шул хәлгә төшерттерә...

Бер ноктага төбәлде дә,
түгелде дә түгелде...
...Ирен, улын җуйган Ана —
сабакташым — теленде...

Җитмеш бернең августында
сынау, имтихан тотып,
авылның егет, кызлары
югары белем йорты
ишекләрен ачып кердек
чиксез теләкләр белән:
романтика — галәмне үк
яулап алырга теләп...
Вузлар, вузларга янәшә
конкурслар, кичәләр...
Артистлар, танкистлар белән
ярдәмләшү итәләр...
...Танышалар, кавышалар,
аралар якыная...
Биш ел биш ай булып үтә,
аннан чиксез Ватан буйлап
тарала кайсы кая...

Сабакташым — сәхнәбезнең
иң өметле гүзәлен
гашыйк итте танкист егет;
кавыштылар тиздән үк...
Хәрби хезмәтне танкист ир
көнбатышында башлый...
Аннан,
«интернациональ бурыч»

Әфганга илтеп ташлый...
Аяусыз сугышкан танкист,
орден-медальләр алган...
Тик соңгы орышта үзе
танкы эчендә янган...
Атасы эзеннән киткән
толның газиз ятиме:
— Үчен алам, — дигән, хәтта, —
мин капитан әтинең...
...Десантчы улы Чечняда
бер хәбәрсез югалган...
Кабере юк, кадере юк —
белми нигә юрарга?..

Буразна сызган йөзеннән
тәгәрәде тамчылар...
Юатып ни әйтә алам:
— Түз, сабакташ, бул чыдам?!

...Өч дистә ел узып киткән,
аккан су, аткан уктай...
Ил-йортта ниләр булганын
аңлап бетергән юк та...

Сабакташым — сәхнәбезнең
өметле гөл чәчәген,
кырау сукты бөресендә,
көйдереп киләчәген.
Ватан өчен башын салган
улының юк кабере...
Ватан дигәне чын ялган
булдымы — юк кадере?!

Танкистны да, артистны да
уенчы итте Ватан...
Халыкларны бер-берсенә
сугымчы итте Ватан.

Аяксыз, кулсыз яшь ирләр,
ятимнәрнең, толларның
күрмиме Ватан чатларда
хәер сорап торганын?..

Алар әҗере — учларга
салынган бакыр гына...
Тук чырайлар сорап тормый
чирканып акырырга...

Юатып ни әйтә алам,
ятимнәрне, толларны?..
Әллә уйнашчы Ватанга
без — уенчык, коллармы?..

Сулган йөзе төсле төссез
шәлен ябынган Ана —
сабакташым түгелде дә
китеп барды... юатырлык
нинди сүз әйтим Аңа?!

**БЕР ХӘБӘРСЕЗ ЮГАЛГАННАР...**

Мең үлемнән исән калганнар да
илдә кабат әсир ителгән...
Тоткын көне — өзеп ялганганы
берекмәс шул инде — кителгән...

Шайтан коткысында җаһил заман
күпме җанны кыйган угыннан...
Крематорийларның торбасыннан
канлы төтен күккә ургылган?..

...Җиңеп җиңсез кайткан җил-егетләр...
Буш балактан кайткан зәр-ирләр...
Сан тулмаган тәндә җан йөреткән —
качып китеп булмый тәкъдирдән...

Ярлыкалып исән калганнардан
кемдер кайтмый калган иленә...
Алар бер хәбәрсез югалганнар
йә күчкәннәр ятлар исменә...

Ят җирләрдә ятка якынаеп,
ояларын корган ятларда...
Бүген алар гөнаһына кереп
кем гаепләр, кемдер яклар да...

Җан һәм Вөҗдан — вакыт мыскалында,
күзең ачып йомган арада,
йә карала, йә агарып кала —
өс чыкканы — түбән табада...

Хак хөкемне хәтта вакыт түгел,
Бер Хак үзе генә чыгарыр...
Югалганнар — димәк, тәкъдиренә
тәгаенләнгәне шулайдыр...

Җанны биргән алырга да хаклы,
Җәбраил һәм Газраилләрнең
вазифасын бүлешкәннәр хакмы?
Колны сыендырган илләрнең
шәфкатенә шайтан күләгәсе
төште өшеттереп бәгырьне...
Вөҗдан һәм дан өчен түләнәсе
Бар кыйммәттән бер Җан кадерле!!!

...Алар бер хәбәрсез югалмаган,
хәтта җәсәдләрен җир алып
туфрак булгач, онык, торыннары
фатихасын сорап ялварып,
җаннар кайта туган нигезенә,
җилләр булып ятып елыйлар...
Кичерелгән бар да вакыт белән...
Ә үзләре гафу сорыйлар...

## КАВЕМЕМ — ЗУР ОЯМ

Киек Каз Юлында
мең еллык арада,
казлар каңгылдаша
кай якка карама.

Киек Каз Юлында
гел казлар тавышы:
кемнәрдер — аерылды,
кемнәрдер — кавышты...

Хәбәр иңә күктән —
үткәннән... килердән...
Кемгә ни, казларга
күктә дә җим кирәк!..
Канатларын җәеп
очарга юл кирәк;
тукталып тын алыр
өченгә күл кирәк;

Киек Каз Юлында
мең еллык арадан
үз ояң, кавемең
бармы — тор аралап!
Мәңгелек бик якын: —
мең тапкыр мең еллык
яктылык үлчәме...
Кавемең-ояңның
никадәр үрчеме?

Ерак юл якынаер —
канатлар талмаса,
яктылык нурыннан
азакка калмаса...
Киек Каз Юлында
кавемең барачак,
йолдыздай яначак.
Үз эзе калачак.

Атылган һәр йолдыз —
бер кавем хәбәре,
мәңгелек юлында
бүленгән әҗере...
Канаты талмаса,
кавемең барачак.
Киек Каз Юлында
нурланып яначак!

Киек Каз Юлына —
күкләргә омтылам.
Мәңгелек юлында
кавемем — зур оям!

**СҮТЕП ЯТАМ ХӘТЕР ЧОРНАГАННЫ**

Әйтеләсе әйтелеп беткән кебек,
Теленәсе йөрәк теленгән.
Хисләремнән акыл тора көлеп,
Көнем күптән айры төнемнән...

Инде азат дөнья ваклыгыннан,
Искитәрлек ни дә калмаган...
Гадидән дә гадиерәк бу яшәү:
Акыл чыккач — шуны аңлаган...

Берни бүләсе юк, түнәсе юк:

Тегесе юк, диеп, монысы...
Әзенә дә разый, барына — тук,
Дәгъваламый нәфес олысын...

Менә шундый халәт биләп ала
Күзләренә кергәч ир-атны.
Ярсып чыккан җирдән туктап кала:
Барып җитәренә еракмы?

Барып җитәр җире җирдәдер дә,
Җаны җитәр җире күктәдер...
Тәне туфрак булган бер мизгелдә,
Җанын сират аша үткәрер...

Әйтер сүзләр калган сыегаеп,
Йөрәк чынлап беткән тетелеп...
Йөз ярылган, төкләр беткән көеп,
Дөнья тәмугында өтелеп...

Хәтер калган: кылган, кылмаганы...
Үкенече — җанны тырмаганы...
Инде тәүбә итеп барысына,
Сүтеп ятам хәтер чорнаганны...

*** * ***

Тамыры тирән,
Сусамас сулмас.
Төге чалармас,
Йөз төсе уңмас.

Олпат бу имән
Күкләргә тигән,
Ап-ак болытлар
Чал башын игән.

Күкләргә шулай
Җитим бер дисәң,
Тамырың тирән
Булсын, и инсан!..

**ТЕРЕ СУ**

...Суның боз булып катмый торганы да була икән. Аны галимнәр «Суык су» дип йөртәләр... «Суык су» мәңгелек бозлыкта да катмый калып, бозны ашый-ашый бер агым булдыра. Шуннан еллар дәвамында боз эчендә зур-зур күлләр, дәрьялар хасил була һәм хәтта алар чакрымлаган боз тауларын җимереп аталар икән.

Суык су — үзгә су...
һичкайчан боз булмый.
Суык су — Тере су,
хәрәкәтсез тормый...

Тере су — бөтерчек,
боз арчып юл яра.
Бертын да тынмый ул,
ул тере, ул ага...

Бөтерчек Тере су,
бертын да тын тормый...
Боз-тауны, таш тауны
ун бармаклап тырмый.

Чакрымнар арасын
йөз еллар үтсә дә,
суык су — Тере су,
эсселәп бетсә дә,
ниятеннән чикми,
туктаусыз боз ашый,
мең еллык бозлыкның
карнында күл ясый...
Күл түгел, дәрья-су
боз-таулар эчендә,
теләге — зәһәр соң;
егәре — көчендә,
берчакны боз таулар
вулкандай ата да,
Тере су — дәрья-су
җиһанга тарала...

Суык су — Тере су
һичкайчан боз булмый,
бертын да ул тынмый —
туктаусыз боз тырмый.
Чакрымлы боз-кыя
диңгезгә шуыша,
артыннан — Тере су
дәрьясы куыша.

Табигать мең серле,
мәгънәле һәрберсе...
Суык су — Тере су
серләрнең серлесе...

Кеше дә бер тамчы
тере су лабаса.
Ул — мәңгелек юлчы,
юлы — боз-тау аша...

## ҖИЛ ХӘБӘРЕН ӘЙТЕП...

*Остазым Рөстәм Мингалимгә,*
*Илдар Юзеевнең вафаты уңаеннан...*

Озата баралмады җан дустын,
озатырга тиеш булса да...
...Ишек ачык — түргә җил узсын,
үзе узмый торсын тупсада...

Җил хәбәрен әйтеп, маңгае
сырларына үтте сыланып:
— Зил-зил, җил-җил — Юзи җибәргән,
керфекләре торды чыланып...

...Килде... үтте чорлар, дәверләр...
Какча сөяк сират үткәргән,
Йолдыз[1], Ямадыдан[2] ятимнәр,
хәрабәдән илне күтәргән...

Бар иде бит чорлар, дәверләр —
мәңге истән чыкмас бер отсаң...
Хәтер исән, әнә җил исә...

Җил җырыннан эзлә онытсаң...

Зил-зил, җил-җил — Юзи җибәргән
бәхиллеген—соңгы сәламен...
Ишек-түрле йөри Арыслан...
Җилме әйтсен бер-бер әмәлен?!

...Язылса да күктә чираты,
беркем белми кайчан китәрен...
Шыплап тулган татар зираты,
сөякләрен читкә этәреп,
мәңге үзенеке итәрен?..

Зил-зил, җил-җил, түргә үт әле,
үзе торып торсын тупсада...
Юзисез соң нишләр милләте,
тагын мең ел гомер булса да?!

**ЯҢА ГАСЫР ДИГӘНЕ ДӘ**

*(Рөстәм Мингалим белән әңгәмә)*

— Син ир булган кырыс гасыр,
мин буй җиткән кызыл гасыр
артта инде...
Икебез дә чал сакаллы
шәрә балкон сакчылары...
Картаелды...
— Дөньяның асылы — ялган,
белгән хәлдә мең ел алдан
алданабыз...
Алдап-йолдап дәү җиңүләр
яуладык, дип, шар ярабыз,
дан алабыз...
Хәтта сөю, мәхәббәт тә
корылган тоташ ялганга.
Гаҗәп үзе:
ямьсезгә — матурым, диеп,
куркакка — батырым, дип,
җыр язабыз!..
Бу сүзләрне үткән
гасырда ук әйткән
идең юкса,
вакыт кырыс...
Истәлекләр актарабыз:
фото-сурәт — ак-каралы,
чыны — соры...
Яңа гасыр дигәне дә,
шул ук солдат шинеледәй,
кытыршылы,
төсе соры...

**ЯЗ МИЗГЕЛЛӘРЕ**

Ташулар көтеп
пышылдый карлар:
— Диңгезгә кадәр
үтәсе юл бар...
Уйсу чокырлар
бүлеп калмасын,

ташысак ташыйк —
күмелсен ярлар...

Салкын аяз төн,
тулган Ай — бөтен,
тыңлап тор бертын,
йокламый беркем...
Шартлап ярыла
ярдан ярына
хәбәр: иртәгә —
боз кузгалыр көн...

Таллар бөредә,
җилләр өрүдә,
бозлар эрүдә,
күзләр көлүдә!..
Җырлашып бии
гөрләвекләре —
гашыйк барсына
тәүге күрүдә!

**ҖИЛДӘН ТУГАН, ДИП ӘЙТҮЛӘРЕ**

Кемдер хәтерли,
кемдер оныткан...
Сөләйман Солтан
сараенда мең
җария тоткан.

Сакчы, шымчылар,
кошаякчылар —
бар да печелгән,
ырудан калган
алаша ирләр...
Тимер ишекләр,
Евнух сакчылар:
җарияләрнең
ятакларыннан
ник бер тын чыгар?

...Хыянәткә юл
йозакланган, дип
инанган Солтан...
Әмма шунда да
тап-тар бер ярык
ябылмый калган:
кемдер чарасын
күргәнме алдан?

Узып чикләрне,
сак, җәтмәләрне
үтеп кергән җил...
Ул болын-кырдан
гөл-чәчәкләрнең
иң хуш исләрен
һәм орлыкларын
алган булган, ди,
һәр җариянең
йомшак учына
салган булган, ди...

Нәкъ тугыз айдан
Сөләйманның мең
улы туган, ди...

Кемдер хәтерли,
кемдер оныткан.
Җилдән туган, дип
әйтүләр, бәлки,
шул чорда чыккан?

**ЫШАНСАҢ-ЫШАНМАСАҢ ДА...**

*(Триптих)*

**I**

Ни-нәрсәгә алынуга,
уйлый идем азагын...
Каләмемә орынуга,
исемеңне язамын...
Бу — күңел кытыклануммы,
олгайгач бер азумы?..
Күрәләтә чыгалмаслык
төпсез чокыр казумы?!

**II**

Күз ачып йомган арада
эредең дә югалдың...
Әллә айга, әллә инде
йолдызларга юл алдың?..
Аек баштан шыр исереп,
басып торамын кана...
Иренемдә иренеңнең
эзләре дөрләп яна...

**III**

Син һаман ышанмыйсыңдыр:
бер мавыгу дип кенә
карыйсыңдыр... Ә мин калдым
хисләремнең типкенә...
Ышансаң-ышанмасаң да,
күңел: — Син! — дип җилкенә...
...Акланып булмас бу хәлдән
Язлар җиткән дип кенә...

*** * ***

*Рушаниягә*

Үткәннәре белән яши һәркем,
Киләчәге аның хыялда...
Хәтеремә мәңге уелган Син,
Берни көч юк аны юарга.

Язларымда — хисләр ташкынында,
Җәйләремдә — җиләс җилләрдә.
Көзен, кышын бергә ашкынылды,
Бергә җиттек җитәр җирләргә.

Үткелләрне үттек — гомер кичтек.
Аркадашым булдың, терәгем...
Килеремне беркөн ялгыз итмә,
Ялварган бердәнбер теләгем...

**КАРЛЫ ЯҢГЫР**

Язын каян иңгән көзләр моңы,
сагышка һич урын юк ласа?
Белсә белер апрель үзе моны,
ташулары тынып тыңласа...

Җепшек, яңгырлы көн калган качып,
сөякләрне сөеп җил исә...
Алмагачның бөреләре ачык —
мәңге ачылмас, әгәр йомдисә...

Өянкемә тиеп, иеп китте
кара күмер — болыт өеме...
Өемне дә кап-караңгы итте,
карлы яңгыр сагыш көеме?!

**ТИК СИН ГЕНӘ**

Ничәнче көн күңел тынгы белми,
ашкына да никтер ашкына...
Әйтерсең лә мәңге үтәлмәслек
бурыч төшкән инде башыма...

Яннарымда әгәр үзең булсаң,
җанкаема юл сабар идең...
Син генә, тик син генә шулай
Юатырлык сүз табар идең...

Билгесезлек теләә нидән җанны,
урын тапмыйм һаман үземә?
Төн озыны керфек какмый чыгам.
Пышылдыйсың: — Үтәр, түз генә...

Ярый әле хыялда булса да
чакыралам сине яныма...
Син берүзең, бары үзең генә
сихәт бираласың җаныма...

**ИРТӘ ЯЗДА**

Хисләреңне һичбер сиздермәдең,
серләрең гел булды йозакта...
Күңелемә барбер килеп кердең,
калырсың да анда озакка...

Хисләреңне һәрчак яшерсәң дә,
ят түгеллегемне беләмен...
Язлар быел иртә башланасы,
ярларымнан чыгу теләгем...

Ярларымнан чыгып агармын да,
синең ярларыңны табармын...
Язлар быел иртә башланасы,

күңелең тәрәзенә кагармын.

## ТӘРӘЗӘМДӘ ТУЛГАНАЙ

Югалтулар һаман булып тора
якыннардан якын затларны.
Мин сагынам сине, бик сагынам,
елый-елый укыйм хатларың...

Тәкъдирдәген кемнәр үзгәртала,
дәрьяны кем бора кирегә?..
Күзләр җитте кинәт, күзләр җитте,
сарылары йөзгә сибелә...

Күзләремә кереп барам шулай,
берьялгызым: түзсәң, түз генә...
Тәрәзәмдә тулгана Тулганай...
Миңа карый синең күз белән...

## КҮЗЛӘРГӘ КЕРДИСӘМ

Төсләр дә бихисап,
хисләр дә ташкын гел.
Күзләргә кердисәм,
язлардай ташыйм бер.

Күзләргә кердисәм,
ялкынга уралам.
Сап-сары кыңгырау —
сап-сары дугада.

Каеннар, таллар да
бизәнгән кызлардай.
Кай якка карама,
алар җыр сузгандай.

Талларда сарылык,
сагышлы моң гына.
Талларга сарылып
тыңлыймын тын гына.

Сап-сары төс алып
күзләрдә җыр яна.
Җыр-утка уралып
кем янмый түзала?!

Йөрәгем ут кына,
җаным — ут йомгагы.
Утырып янамын,
кем килеп коткарыр?

Күзләргә кердисәм,
җыр-моңга уралам.
Сап-сары кыңгырау —
сап-сары дугада!..

Күңелем — җиз кыңгырау,
күзләрдә чың ала.
Кайтаваз булып бер
чыңлармын дөньяда!

## ИЛҺАМИЯТ, РӘХМӘТ СИҢА!

Төннәр озын,
Көннәр кыска,
Кар-буранлы,
Салкын чакта,
Җан җылыга,
Күңел назга
Сусап, язны
Көткән чакта,
Берьялгызым
Карап айга
Сагынганда,
Юксынганда,
Шул сылу кыз
Сыйфатында
Килеп кердең
Хыялыма.
И сихри көч,
Илһамият,
Рәхмәт сиңа,
Рәхмәт сиңа!

## САГЫШ

Урынсызга рәнҗетелгән
Ничәмә-ничә җаннар,
Көз җиттисә, сагыш булып
Кайталар безнең янга.

Тәрәзәдә яңгыр түгел,
Күз яшьләре аларның.
Оныкларын эзли җаннар,
Өметләнеп табарын.

Кайсы калгандыр карында,
Кайсы түшәк чылатып.
Оныкларын эзли җаннар,
Бөтен дөнья буйлатып.

Оныкларын эзли җаннар,
Йөзләреннән төсмерләп.
Табыла да бит оныклар, —
Йөзләренә көз кергән.

## БУ — ЯШӘҮ КӨЕДЕР

Агыйдел ярлары
гөлҗимеш, миләшлек.
Дулкыннар ярларга
торалар гел дәшеп.

Дулкыннар нәниләр,
тын гына җил булса,
давылда, давылда
дулкыннар бик усал!..

Нәзек җил таң белән
Иделгә сер дәшсә,

дулкыннар, пышылдап,
ярларга күчерә;
аннан соң яфраклар —
берсеннән берсенә.

Бу — яшәү көедер!

Дулкыннар кебек үк
безнең дә бу җиргә
килүләр-китүләр,
гомерләр итүләр...

Дулкыннар тагы да
кагыла ярына.
Яр — елъязмачы —
эзләре языла.

## КАУРЫЙ БОЛЫТТА ТИБРӘЛӘ БЕР ТӨЙМӘ

...Ничек шулай
сайрый Тургай,
нокта гына кебек лә?!

*Р.Мингалим*

Кызу җәй
уртасы —
каурый
болытлар
читендә
бер төймә:
— Нишли ул?..
— Нишли ул?

Шул төймә
туктаусыз
тибрәлә,
талпына, —
әйтмәкче
буламы
бер сүз, Җир
катына?

Әллә соң
ул төймә
Киек Каз
Юлына
очарга
ашкынып
талпынган
бөркетме?

Кемнәрдер
күрә дә,
кемнәрдер
күрми шул;
кемнәрдер
сизә дә,
кемнәрдер
тоемсыз...

Әлегә
белмиләр,

әлегә
сизмиләр;
Ул — Тургай, —
бу чиксез
галәмнән
өр-яңа
җыр эзли!

Яңа җыр
җиһанга
бик кирәк,
шулчаклы, —
бәйләп үк
торыр ул
галәмгә
Җир шарын!

Кызу җәй
уртасы, —
яна Җир,
Җир көя...
Галәмдә
Җыр эзләп
тибрәлә
бер төймә!..

**ИЗГЕ СУКМАК**

Үлән баскан иске сукмак таныш,
Беләм аның кая илтәсен.
Урман уртасында умарталык:
Умартасы юк та, киртәсе.

Алан уртасында куш нарат юк,
Кисеп алган икән кайсысы?
Питрау көнне кортлык аланына
Авылның бар бала-чагасы
Җыела идек карга боткасына,
Сабантуйга җыелган сыман.
Кушучларда имән яфрагы,
Аңа нәкъ бер кашык бал сыя...

Умартачы Гаязетдин агай,
Бабасыннан калган һөнәре.
Югалтса да яуда аягын,
Югалтмаган олы йөрәген!

Агач табак, агач кашык кулда,
Дистәләгән күзләр төбәлгән.
Ак башлыгы ап-ак күлмәк кигән,
Агач аяк аерып терәлгән.

Ул бал сала имән яфрагына,
Һәр кушучка тулы бер кашык.
Безнең генәмени, үзенең дә
Бәхеткәе түгелә ташып!

Сабыр иткән — морадына җиткән, —
Иң ахырдан басып торганга,
Гаяз абый баллы шул калагын

Миңа бирде ялап куярга!..

Имән яфрагында юкә балы:
Тәме, төсе, исе хәтердә.
Телем йотып, онытмадым микән
Шул чагында рәхмәт әйтергә?

Тузганаклы шушы иске сукмак
Изге сукмак булган лабаса.
Авылым урманына кайткан саен,
Күңелемне татлы моң баса...
Күңелемне баллы моң баса!

## ЯШӘР ӨЧЕН

Кинәттән атылган йолдыз
Йөрәгемә кадалса,
Чыккан җанымны озатып,
Җиде адым баралсам,
Кайтарырга җанны тәнгә
Шунда куәт табармын:
Яшәр өчен синең белән
Мин яңадан яралып.

## БУЛДЫ, БУЛДЫ...

Кан көндәше шагыйрьләрне
Һәр тиран үзенчә кырган:
Кайсы өзгән чабып башын,
Кайсы данга тончыктырган...

Булды, булды — яшәдек без
Тукайсыз заман.
Аннан соң гомер кичердек
Туфансыз заман.

Җәлилсез дә яшәдек ич —
Хәтерләр исән;
Телне тешләтте замана,
«Исхакый» дисәң...

Зурлыйсымы, хурлыйсымы
Бүгенге көнне?
«Сукыр тәкә» уйныйбыз күк,
Бәйләми күзне...

## ЧОРЫНДА БЕРДӘНБЕР БУЛА...

Родился я в соломе в час рассвета, —
Так хорошо на свете быть никем!..

*Пьер Жан Беранже*

Ялгышларны язмышларга
сылтау да ансат түгел.
Кемдер алдында аклану
әлегә максат түгел.

Заманасын хурларга да
ашкынып тормыйм юкса.
Мактарлыгын да тапмыймын,
түре гел булды тупса...

Ата-ананы сайлап булмый...
Туган җир дә бер генә.
Кемдер олтан, кемдер солтан
язмышының иркендә.

Заманны да сайлап булмый,
үзе безне сайлый ул.
Калыбына-кысасына
кирәгенчә җайлый ул.

Аннан, бакыр тиен сыман,
сугып тора бер көйгә.
Җайлый заман, ямый заман,
калдырмыйча бер җөй дә.

Меңнән бере сайланмый да,
җайланмый да калыпка.
Чорына бердәнбер була,
аннан булмый калып та.

## ЯЛГАН СҮЗ

Яман сүзнең күңелдән һич
заты китмәс...

*Акмулла*

Ялган сүз — арттан атылган
агулы уктыр.
Зәһәрен йолкып алырлык
дәвасы юктыр.

Ялган сүз — җанга кадалган
тутыккан кадак:
тартып алсаң-алмасаң да,
эш үткән — харап...

Ялган сүз — оныкларыңа
күчеп барачак.
Яманат булып ыруда
мәңге калачак.

## ЕГЫЛДЫК ТА ТОРДЫК...

Егылсак, күргән-белгәннәр
Яхшыга юрасыннар.

*Р.Фәйзуллин*

Егылдык та тордык, егылдык та,
яра-эзләр ятты йөзләргә...
Заманасы килде... аты корсын...
без җәйләрдә кердек көзләргә.

Егылдык та тордык, гел үзебез
Ванька-встанька торган шикелле...
Нинди заман килә төйнәп йодрык,
сукса торырбызмы, икеле?!

Заманадамыни, тәкъдирләргә
язылганы шулдыр чынлыкта.
Егыл да тор, егыл да тор, кеше.

Торалмасаң, сиңа бер нокта...

## КӨЗДӘ БЕР МӘЛ

*(«Ел фасыллары» циклыннан)*

Бөтен тирә хәрәкәтсез,
Дөнья тынып калган сыман.
Күл өстендә каз мамыгы
Йокысына талган сыман.

Мәрткә киткән тал, ярлары,
Сызгырмый бер курасы да.
Ак болытлар туктап калган
Җитеп күлнең уртасына.

Гаҗәп тынлык.
Сихри тынлык...
Шунда кинәт сизеп калдым:
Камышлыклар арасыннан
Йөз күз нурын тотып алдым.

Таллар, ярлар, камышлары,
Куралары җырлап тора
Әрәмәдә алтын көзнең
Мең бер кылы чыңлап тора!..

Кыр казлары китеп бара,
Язлар җиткәч, кайтырлар бер...
Алтын көзнең илаһи вә
Күңелләрдә калыр мәле!..

## ЯЗНЫҢ ТӘҮГЕ КӨННӘРЕ

Тып-тып, тып-тып тамчы тама,
Тамып тора бер җайга.
Чыңлап тора, җырлап тора,
Сихри тамчы бугай ла.

Тамчы тама, тамчы тама,
Ул — шатлык тамчылары.
Тама-тама табигатьнең,
Шәт, язны каршылавы.

Көлешеп тама тамчылар,
Рәхәт шатлыкка тулып.
Күр, ничек бөре ачыла —
Кояшка йөзен борып.

Тоеп кал, и, сизеп кал син
Бөреләрнең шул хәлен.
Җирне күкләргә бәйләгән
Мәңгелекнең бер мәлен!..

## ЯЗДАН ҖӘЙГӘ КҮЧКӘНДӘ

Мөтә ташып ярларына
чигеп утырды,
балан, шомырт чәчкәләре

балланып тулды.

Талларында сандугачлар
бер дә тынмады.
Тургайлар да болытларга
җитеп җырлады.
Бал кортлары үзләренә
тынгы бирмичә,
чакрымнарны урап кайтты
ничәмә-ничә.

Монда гына күбәләкләр
яңгыры бугай.
Мең төрле төс, мең бер аваз
яңгырый бугай.
Бар да җырлый, җырлап һичкем
арымый бугай.
Монда кояш бер чыга да
баемый бугай.

Мөтә-инеш яры текә,
чакматаш комлы.
Мөтә суы алтын тәңкә,
көмеш чулпылы.
Сикереп биеп, бөтерелеп,
ташларны үбеп,
күбекләнеп ага инеш
кеткелдәп көлеп!..

Табигатьнең күңелләргә
хуштан хуш чагы.
Чакырып ала үзенә
җәеп кочагын...

**КӨЗ — КӨТЕП АЛГАНЫМ**

Көз — көтеп алганым:
өзелгән ялганып
бәйләнер төенгә —
беленмәс җөе дә.

Көз — көтеп алганым:
алтынсу таңнарым,
тулыр ла күңелем
алмадай балланып.

Көз — көтеп алганым:
уйларым — көмеш су,
күңелем юылып
илһамга туенсын!..

Көзләрдә янганым,
күмергә калганым,
язларда ташыйм, дип,
йөргәнмен алданып.

Көз — көтеп алганым:
өметләнеп, теләп,
йолдызлар атканын.
Төнозын бакканым —
Киек Каз Юлында

канатым какканын.

**СИҢА КАЙТЫР ЮЛЫМ**

Сиңа кайтыр юлым ерак —
Тауларны бар кичәсе...
Бүген айның ничәсе?

Сиңа кайтыр юлым озак —
Үткелләрне үтәсе,
Үткәннәрне сүтәсе.

Сиңа кайтыр юлым урау —
Карурманнар урасы:
Кыры, кылган, курасы.

Сиңа кайтыр юлым диңгез —
Яр белә яр арасын
Дулкыннардай ярасым...

Сиңа кайтыр юлым — күктә,
Хыялым уйларымда —
Киек Каз Юлларында.

# Гыйбарәләр

## 1

* * *

«Бер йотым су» дигән төшенчә бик тә мәгънәле, гыйбрәтле сүз бугай... Сусау — тәннең, канның кибүе... Канның куеруы һәм тәннең үлеме... Бер йотым су гына соңгы чиктә беркемне дә коткарып кала алмый... Ә шул бер йотым суны авызыңа салучың булмаса — барасы җиреңдә дә яратмаслар кебек... Анда фатихасыз килгән кебектер...

* * *

Мин ачлыкны күрмәдем. Ачлык күргәннәрне һәм ачыкканнарны күрдем. Ачлык күргәннәрнең дә, ачыкканнарның да саулыгы «начар» булмаган, аларның күбесенең гомерләре озын... Бу беренче караш-ка шулай кебек... Ачлыкның иң ачысын татыганнар барыбер бу дөньядан китеп барган... Соңгы чиккә җитеп ачыкмаганнар... чыннан да озак яши... Ураза тотучылар да гомерләрен озайтасылары килә. Ураза — эчке энергияне бераз саклау, ачлык кебек иң зур фаҗигагә әзерләнү дәдер, бәлки...

* * *

Ачлык — иң каһәрле каза... Ул һәркемне иң оятсыз хилаф эшләргә этәрә. Аны хәтта дошманының каршына китереп тезләндерә...

* * *

Ачлыктан саклану өчен ризык маясын булдыру — котылгысыз канун... Ачлыкның иң ачы хәсрәтен кичергән кыргый җәнлекләр аны беркайчан да әрәм-шәрәм итми... Ризыкларын яшерен урыннарга ка-чырып куялар. Бик авыр чакта, мохтаҗлык килгәч казып алып, тәгам кылалар.

* * *

Ачларны тамак ялына эшләтү, бозыклык кылуга һәм ул теләмәгән эшләргә дучар итү — иң зур гөнаһ. Аллаһы тарафыннан катгый һәм котылгысыз гаепләнәчәк гөнаһ.

* * *

Яшьли үлеп киткән кешеләр хакында: «Гомере беткәндер», — диләр. Еш кына: «Җыяр ризыгы беткәндер», — диләр... Ризык — гомер итүнең, яшәүнең иң хәлиткеч чыганагыдыр.

* * *

Ризыкны өлешкә бүлү, һәркемгә тигез өлеш чыгару — мактаулы күренеш. Кеше өлешенә, кеше ризыгына керү — иң олы хаталык һәм гөнаһ.

* * *

Бүләк итеп ризык алып бару күркәм күренеш... Кунакка барганда күчтәнәч-ризык белән бару һәм кунактан күчтәнәч-ризык алып кайту — бик күркәм йола...

* * *

Бала ризыгына керү һәм бала өлешен түләүдән баш тарту — зур гөнаһ.

* * *

Ризык белән сихер итү, бозым кертү — иң зур җинаять һәм түбәнлек.

* * *

Ризыкны таләп ителгәнчә әзерләмәү, тәмсез итеп әзерләү — зур гөнаһ. Ул ризыкны әрәм итүгә, бозуга тиң.

* * *

Ризыкка табынуда гөнаһ юк. Һәр ризык — Аллаһы бүләге.

* * *

Хәләл ризык — иң беренче чиратта — үзең үстергән, үзең эшләп тапканга алынган бисмиллалы ризык.

* * *

Кешенең ризыгын тартып алу — аның иминлеген, гомерен тартып алуга тиң.

* * *

Ризыктан баш тарту, ачлык игълан итү — гадәттән тыш рәнҗү билгесе...

* * *

Ризыктан разый булу фарыз...

* * *

Ураза — тән һәм җан камиллеге юлындагы бер фарыз күренеш. Изге китаптан да үтемлерәк итеп Ураза хакында берни әйтеп булмас. Ул — үзенчәлекле ризыклану һәм Ходайга бару юлында билгеле бер адым.

Ураза — йола һәм иманлылык билгесе.

* * *

Ризыктан зур булып булмый, әмма тамак колы булырга да ярамый.

## 2

* * *

Әнкәй безне күршенең тәлинкәсенә карамаска өйрәтте. Димәк, үз тәлинкәңдәгене дә күршегә күрсәтүнең хаҗәте юк.

* * *

Күрше белән ике арада һәрчак коймаң, киртәң һәм капкаң булсын.

* * *

Күршенең тавыгы гына түгел, әтәче дә күркә булып күренергә мөмкин.

* * *

Күршең чакырмый торып түргә узма. Күршеңне кухня һәм кунак бүлмәсеннән ары уздырма.

* * *

Күршеңнән көнләшеп яшәмә, ул үзе синнән көнләшерлек итеп яшә.

* * *

Күршең өлешенә кул салма, күз атма.

* * *

Күршеңне беренче булып сәламлә.

* * *

Күрше хакы Аллаһы хакы булганда, аңа үз хакыңны куйма...

* * *

Күршең көйсез һәм көнче булса, аны көйләү — мәгънәсезлек.

* * *

Күршеңдә гарип булса, аңа һәрчак хәерле бул.

* * *

Күзең белән күрсәң дә, күршең гөнаһына кермә.

## 3

* * *

Дусларның, ир белән хатынның ялганы — хыянәттер. Хыянәтне кичерү — үзе зур хыянәт. Хыянәтне кичерү — көчсезлек!

* * *

Хыянәтче белән уртаклык — мескенлек өстендәге мескенлек...

* * *

Җавапсыз хисләрдән арына алмаганнарны бары түбәнлек көтә.

* * *

Хыянәтнең күзе — юеш, бите — тимгелле, үзе исле булыр...

* * *

Һәр ялтыраган алтын булмаган кебек, һәр калтыраган да куркак йә алкаш түгел.

* * *

Иң куркак кешенең дә үз гомерендә бер кечкенә генә булса да батырлык кылып шаккатырасы килә...

* * *

Куркактан кирәк кадәрен һәрчак алып була. Куркакныкы уртак булыр.

* * *

Куркак ялганчыдан да куркынычрак.

* * *

Куркак — һәрчак телсез, күзсез һәм саңгырау.

* * *

Куркак уртага елышыр.

* * *

Куркаклардан курыкмаганны куркыныч көтә.

* * *

Балаларың, туганнарың, якыннарың өчен куркып, борчылып яшәү — куркаклык түгел.

* * *

Куркакның киләсе күп булыр...

## 4

* * *

Байлык: ирне — ирәйтә;
Хатынны — хөсетләндерә;
Балаларын башбирмәс итә.

* * *

Байлык мәңгелек булмаса да — бетәрлек түгел, ул — кулдан-кулга күчеп йөри.

* * *

Байның бастырыгы юан була...

* * *

Булдыксыз баемас. Баеса да бәрәкәтен белмәс.

* * *

Урламый баеганнар да бар. Әмма алар бур байлардан ярлырак.

* * *

Байлык — һичшиксез, өстенлек. Маясы булган билгеле мөмкинлекләргә, абруйга, дәрәҗәгә ия. Һичьюгы, гаиләсендә кирәкле кешегә әверелә.

* * *

Бай биргән белән генә бөтәеп булмый.

* * *

Бик борынгыдан сакланып калган каберлекләр — бар да байларныкы... Яр ишелгәндә ярдан тырпаеп килеп чыккан сөякләр — ярлыларныкы...

* * *

...Чүплектә гомер иткән бомжларның да байлары бар.

* * *

Байлар өчен дә, бурлар өчен дә үз кануннары булган һәм бар.

* * *

Байлыкка кызыкмау — күркәм сыйфат, әмма өстенлек түгел. Кызыкмый торып, баеп булмый.

* * *

Алтын — «алдын» сүзенә аваздаш. Алдын — алдынгы мәгънәсен аңлата. Алтын — иң-иң өстен сыйфатларга ия төшенчә булырга чыннан да хаклыдыр... Дөньякүләм танылучыларга алтыннан ясалган билгеләр бирү — күркәм йола...

* * *

Алтын затлылык һәм байлык билгесе, әмма аңа байлык билгесе дип кенә карау өстенлек итә башлаганнан алып ул сугыш-талаулар, пиратлык, ришвәтчелек кебек затсыз күренешләргә сәбәпче була бара, гәрчә алтынның бередә бер «гаебе» булмаса да...

* * *

Алтынның үзен дә матурлау, бизәндерү кирәк. Алтыннан матурлык тудыручылар — һәрчак зәвыклы, затлы һәм зыязатлылар.

* * *

Алтын — затлылык һәм байлык билгесе... Алтын җирдә аунап ятмас — таш астында булыр... Ташларны күчерә-күчерә юллар, шәһәрләр төзе, бакчалар кор, җимеш-гөлләр үстер — баерсың, матураерсың — затлы, алтынлы булырсың!

* * *

Иң кадерле кешеләреңә — балаларыңа, сөйгәннәреңә: «Алтыным!» — дип эндәшүдә гөнаһ юк. Бу — алтынның «бәһа»сен күтәрүдән бигрәк ярату-мәхәббәт, туганлык хисенең көчен һәм ихласлыгын күрсәтә...

* * *

Алтыннан ясалган сугыш кораллары кан коюда куллануга затлылыгын җуя...

* * *

Ботка ашау өчен генә алтын тешләр, алтын кашыкларның хаҗәте юк...

* * *

Алтын — табигый хәзинә... һәм иҗади сәнгать биеклеге... Аңа һәрчак ихтыяҗ зур.

* * *

Алтынга битарафлык — талымсызлык чагылышы. Байлыккамы, матурлыккамы?..

* * *

Алтынсыз да яшәп була, әмма алтын көзсез һәм дә хатын-кызсыз — күңелсез...

* * *

Акылсызның авызына алтын теш куеп кына акыллы сүз сөйләтеп булмас.

* * *

Алтын бәһасенә торырлык сүзләр дә бар. Шуңар аларны иң кирәк булганчыга кадәр дәшми саклап торуың — алтынга тиң...

* * *

Көмешне алтын белән йөгертү матур битне тагын да бизәүгә тиң булса, алтынны көмеш белән йөгертү матур биткә корым сөртүгә тиң булыр иде...

* * *

Алтынның бәһасе үзгәреп торса да, чын кыйммәте затлылыгы биеклегендә калыр.

* * *

Алтын һичкемне үзенең колы итми, ә үз кыйммәте дәрәҗәсенә, камиллеге, затлылыгына омтылуга чакыра... Алтыны булган кол һичкайчан затлы булмас...

* * *

Алтынлы булу акыллылык билгесе түгел, әмма акылсызда алтын озак тормас, затсызга әйләнер...

* * *

Алтыннан агу качар...

* * *

Алтындагы галәми мәгънәгә ия, вакыт һәм чиксезлек төшенчәләре чагылыш табу — алтынчы-иҗатчының иң бөек омтылышы...

* * *

Халкына матди һәм рухи байлык, алгарышка этәргеч ясый торган һәрнәрсәне, һәркемне алтынга-хәзинәгә тиңләүдә гөнаһ юк... Әмма барлык байлыкның һәм рухи байлыкның асылы — Аллаһы кодрәте һәм иманлыкта... Имансыз халык тау-тау алтыннарын да җуеп, дәүләтсез, илсез, телсез, көчсез калып яшәүдән туктый... Кемнеңдер колына, эш коралына, чималына әверелә... Изге китапта һәм тарихта бу хакта гыйбрәтләр бихисап...

* * *

Алтынлы — алтын иясе — дан һәм вөҗдан сынавына дучар...

**5**

* * *

Иман — кеше һәм кешелек рухы ирешәсе иң югары дәрәҗәдәге камиллек һәм халәт!

* * *

«Иманын җуйган» дигән гыйбарә бар. Җуйганчы, югалтканчы аның бит әле иң әүвәл булуы кирәк. Имансызлык дәвере әле дә дәвам итә. Шул ук вакытта иманга кайту да күзәтелә... Аның иң беренче зарури адымы —тәүбәгә килү, тәүбә итү.

* * *

Тәүбә кылып иман юлына чыкканнарның йөзе нурлы, эшләре уң!..

* * *

Татарда «иманын укытам» дигән сүз бар... Ул кемне дә булса тәүбә иттерәм, гөнаһларыннан арындырам һәм иманга китерәм дигән мәгънәне аңлатадыр... Әмма имансызлык чорында «иманыңны укытам» дип сүгенәләр.

* * *

«Иманын саткан» дигән гыйбарә дин кагыйдәләрен, кануннарын үтәүдән читләшкән, оятын, намусын югалткан һәм шул сәбәпле әшәкелек эшләргә сәләтле кешеләргә әйтелә...

* * *

Иман — җан камиллеге, Аллаһыга сыену һәм Аңа бару өчен иң туры юлны табу чыганагы.

* * *

Иман — җан ирешәсе биеклек булып кала, һәм аңа фәкать тирән ышану һәм камиллек аша гына ирешергә мөмкин.

* * *

«Иманыңны сакла» дип әйтүгә караганда — «Имансызлыктан саклан» дип әйтү дөресрәктер...

* * *

Иманлы булу өчен намаз уку гына җитми... Коръән намазлы, догалы булып та, имансыз булучылар хакында китаплы көферләр дип күрсәтә... Әмма догасыз, намазсыз, хәерсез килеш иманлы булып булмый... Иманга юл Ана карынында ук башлана һәм гомер буе дәвам итә...

**6**

* * *

Ирек — дөньядагы иң кадерле, иң мөкатдәс халәт. Тулы ireккә ирешү хәтта мөмкин дә түгелдер... Әмма җан, вөҗдан иреге — бер Аллаһыга сыену, Иманга бару мөмкинлеге... Андый ирекле җәмгыять кайда соң? Рәсәйдәге вәзгыять һәрчак вөҗдан ирекен изүгә, басуга корылган булды.

* * *

Һәркем бәхетле тик шул чакта:

Иле булса ирекле,
Ил башы — игелекле...

* * *

Ирек яулап алына һәм саклангандa гына булырга мөмкин. Ирекле булу башкаларның ирeген кысарга хокук бирми.

* * *

Ирек — чиксез зур байлык... Бар да үзеңдә һәм үзеңнеке... Үзеңә һәм тәкъдиреңә язылганы... Байлыкны югалту куркынычы һәрчак булган кебек — ирекне югалту куркынычы да һәрчак бар.

* * *

Ирекка туйган зат булмас... Ирекнең чиге юк... Әмма ихтыяҗны, нәфесне чикли белү беркайчан да зарарлы булмас.

* * *

Көндәлек мәшәкатьләрен үз вакытында хәл итеп барган, иренмәгән кеше һәрчак ирекле.

* * *

Ireклегe ияреп тә ирекле булуың икеле...

* * *

Ирексезләү — көчсезлекнең беренче билгесе.

* * *

Ирдән аерылу — ирекле булу, диючеләр, беркайчан да чын ирекне аңламас.

* * *

Илсез һичбер кеше, һичбер халык ирекле була алмый... Илен җуйган —ирeген җуйган.

* * *

Илсез милләт — телсез халык.
Мескенрәк кем бар тагы?

* * *

Ил башы таякка таянса,
Иле дә таякка калыр.

* * *

Тарих тәгәрмәчен тизләтердәй, яки борып җибәрердәй шәхесләр гасырларга бер генә туа диләр... Берүк шулай гына булсын.

# 7

* * *

Исерекнең телендә ни булмас, дисәләр дә, иң кирәкле сүзне еш кына кешене исертеп алалар.

* * *

Исерек хатын-кыз чиркандыра.

* * *

Айнымас хатын — ахырзаман билгесе.

* * *

Айнымасның аты булмас.

* * *

Исерекнең һәр көне искечә башлана, гадәттәгечә тәмамлана...

* * *

Рәсәйдә иң очсыз кол — эчкече.

* * *

Исерек халык үз иленә, үз заманына һәрчак лаек...

* * *

Айнымас халыкның мулласы гына аек булмас...

* * *

Исерекне айнытып була, аек килеш тотып булмый.

* * *

Хәмер — ирнең бар хәлен алыр да шайтанга бирер.

* * *

Хәмер — шайтан суы, никадәр күп эчәсең, шулкадәр иблисләнәсең, көферләнәсең.

* * *

Хәмер канны кыздыра, акылны боздыра...

* * *

Хезмәт хакын хәмер белән түләгән дәүләтнең гомере озын булмас...

## 8

* * *

Ахмаклыктан көлүдә язык юк, ахмактан көлүдә мәгънә юк.

* * *

Ахмак теленең тезгене өзек...

* * *

Ахмак юләрдән акыллырак, әмма юләр ахмактан әдәплерәк...

* * *

Аңгырага аңлата-аңлата ахмаклануың бар...

* * *

Аңгырага дөньяның дүрт ягы да бер...

* * *

Ахмакның күзе кызылга кызыгыр.

* * *

Ахмакка: «Син — ахмак» — дип әйткән, үзе дә аның сыңары булыр...

* * *

«Ахмакларны чәчеп үстермиләр» дигән җөмләдән аларны чүп үләнгә тиңләүне аңлау кирәктер... Әмма чүп үләненнән чүпләп кенә арынып булмый.

* * *

Ахмаклар арасында акыллының акылы артмый.

## 9

* * *

Үз-үзенә гашыйк — башкаларның да аңа мәхәббәтле булуын тели, хәтта күпмедер таләп тә итә.

* * *

Үз-үзенә гашыйк кемгәдер гашыйк була алмый, кемнеңдер иң кайнар гыйшкын үзенә кабул гына итә ала...

* * *

Үз-үзенә гашыйк үзеннән матурраклар булуга ышанмас һәм башкаларның да ышануын теләмәс...

* * *

Үз-үзенә гашыйкның аерылгысыз юлдашы — көзге.

* * *

Үз-үзенә гашыйк, булдыклыны таныган очракта да, үзен аның остазы дип тануларын теләр...

* * *

Үз-үзенә гашыйк тыштан һәрчак ялтырар, эчтән калтыраганлыгын сиздермәс.

* * *

Үз-үзенә гашыйк үзе вафат булганнан соң дөньяның, туганнарының, якыннарының нинди зур югалту кичерәчәкләрен һәрчак күз алдында тота һәм үзен-үзе саклабрак, алар хакына озаграк яшәргә омтыла...

* * *

Үз-үзенә гашыйк көзгедән караган саен: «Сынлы сәнгатьтә дә, әдәбиятта да әлегәчә камил портрет һәм образ иҗат ителмәгән», — дип раслар...

* * *

Үз-үзенә гашыйк һичшиксез оҗмахта да үзенең иң өстен булачагына тулысынча ышана...

* * *

Үз-үзенә гашыйк үз исемен карга булса да язып китәр.

## 10

* * *

Һәркем өчен иң якын сүз — «Мин» сүзе!..

* * *

Мин-минлекле кеше һәрчак түрәлеккә үрмәли.

* * *

Мин-минлек беренче карашка гына кыюлык, тәвәккәллек кебек, чынлыкта исә мин-минлек үзеңне «мин» кысаларына бикләп, читләр фикерен тулысынча инкарь итүгә корылган.

* * *

Мин-минлеклеләр гадәттә күпмедер сәләткә һәм физик көчкә дә ияләр. Үзләренә югары рейтинг билгеләп, үзләреннән күпкә сәләтле һәм көчлеләргә каршы чыгып, алар тарафыннан изеп тә ташланалар... Әмма тәүбәгә генә килмиләр.

* * *

Мин-минлекле үз дигәнен үз гаиләсендә булса да итмичә калмый.

* * *

Мин-минлекле үзенә карусызларны кимсетми, үзен алардан беркайчан да кимсеттерми.

* * *

Мин-минлекнең азганы — тәкәббер.

* * *

Тәкәббер — үз туганнарына да түбәнсетеп карый.

* * *

Тәкәббер хатын-кызлар гаиләсендә ирен изеп яшәү белән генә чикләнмиләр, тирәсендәге барлык хатын-кызлар белән яшерен яки ачыктан-ачык көрәш алып баралар.

* * *

Тәкәбберләр башкалардан гел гаеп эзләр. Гаеп тапмасалар, аларны: «Сәләтсез, көчсез, ямьсез», — дип хурлар.

* * *

Тәкәббер үз тигезләре арасында игътибарны бермә-бер артыгы белән таләп итәр. Үз бәяләмәсе һәрчак бермә-бер артык булыр.

* * *

Түрә хатыннары, үз сәләтләре һәм матурлыкларыннан бигрәк, ирләренең абруе, сәләте, көченә таянып тәкәбберләнер, өстенлек итәргә тырышыр.

* * *

Тәкәббер Илбашы һәм аның тәкәббер хатыны — бу илнең милли фаҗигасе.

* * *

Тәкәббер — «тәкә» + «бер» сүзләреннән тора. Ягъни «көтүдә бар да сарык, тәкә — бердәнбер». Бердәнбер булырга бик теләгәннәр — тәкәббер дә инде...

* * *

Хәерче мин-минлеге һәм тәкәбберлеге бары тик мыскылга, көлүгә генә этәрә... «Хәерче баеп алса, чабатасын түргә элер», — диюләре шуңа гыйбарәдер...

## 11

* * *

Төш күрү — кеше тормышындагы могҗиза. Аның өчен нинди дә булса тырышлык, көч кую, чыгымнар да таләп ителми... Һәркем төшне үзенчә күрә һәм үзенчә юрарга да тиеш. «Тавык төшенә тары керә», дию һәрчак дөрескә туры килми.

* * *

Төштә әрвахларны күрү, алар белән аралашу — җан һәм рухның хаклыгын раслаучы дәлил...

* * *

Төш татлы хыял икән — тәмен югалтма...

* * *

Төш кәефне төшерерлек икән, кичекмәстән дога укы һәм хәер бир.

* * *

Төштә ашаган белән өндә тук булмассың. Йокыдан иртә тор, шөгыленә кереш, үзең һәм гаиләң ашлы булыр!

* * *

Тавык төшенә — бөртек,
Буйдакка — хатын,
Халыкка юмарт патша керер;
Өндә һичберсенә шуларны китереп бирмәсләр...

* * *

Төштә ашаган тешкә керми...

* * *

Төшне сукыр да күрә, төштә сукбай да түрә.

## 12

* * *

Биектән, берсүзсез, бар да күренә...
Күпләр арасыннан берәү күренмәскә дә мөмкин...

* * *

Бер — иң кечкенә сан, бер — бердәнбер булганда бик тә кыйммәт, әһәмиятле һәм кадерле...

* * *

Берне берни эшләтеп булмый.
Бер — бер кулга гына,
Бүлә калсаң, берәүгә дә берәр тими.

* * *

Бәрәкәтле булса, бер дә бик җитә.

* * *

Бердәнбер бала нык биетер...

* * *

Бердәнбер буласы килгәннәр бихисап...
Бихисап арасында да бердәнбер берәү генә.

* * *

Бердәнберем дигәненә үзең дә бердәнберме?

* * *

Бер тарыдан ботка пешермиләр,
Бер ел тотмый патша төшермиләр.

* * *

Бар халыклар, илләр, галәмнәр өчен берәү генә бердәнбер — Бер Хак Тәгалә — Аллаһы үзе генә.

* * *

Хак Тәгалә тереклекне һәм әгъзаларны пар яраткан.
Пар булмыйча бар була алмыйсың...

## 13

* * *

Үзеңә үчленең туган-тумачасы белән «булашма», әмма аларның берсен дә күз уңыңнан җибәрмә...

* * *

Хәйлә — кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең иң киң таралганы... Хәйлә мәкерсез булмый, һәм ул күп очракта көндәшеңне, дошманыңны алдау, төпкә утырту өчен эшләнә...

* * *

Чын хәйләкәрнең хәйләсен сизеп булмый, йә ул вакытлар үткәч кенә ачыла...

* * *

Хәйлә — осталык. Ул — белем һәм тәҗрибә белән беррәттән һәр аерым очракны дөрес аңлауны, үз файдаңа куллануны таләп итә...

* * *

Хәрбиләрнең үз хәйләсе. Хәйлә — көч, осталык.
Кайсы якның булса да хәйләсе өстен чыгарга тиеш, кайсы булса да үз җиңелүен таныганчыга кадәр.

* * *

Хәйләкәр кулын буямас, читләр кулы белән кызу тотар, читләрне үзара бәрелештереп үзенә файда табар...

* * *

Хәйләкәр — һәрчак сәләт иясе, сүзгә оста, өлгер... Иң-иң кирәк чакта иң кирәкле урында була белә...

* * *

Хәйләкәр — оста стратегик һәм тактик... Бик мөһим булганда, бер адым алга күчешкә ирешү өчен ул ике-өч адым чигенеш ясарга, урап узарга, кемнеңдер өстенә басып үтәргә дә мөмкин...

* * *

Хәйләсез көндәш булмас...

* * *

Палачка хәйләкәр булуның ихтыяҗы юк: иң мөһиме, йөз япмасында күз тишеге, балтасы саллы һәм үткен булсын...

* * *

Һәр эштә осталык, ысул, аз көч куеп, олы нәтиҗәгә ирешергә омтылу бар — бу да хәйлә! Хәйлә һөҗүм итү, яулап алу, нәрсәгә булса да ирешү чарасы гына түгел, ә нинди дә булса саклану ысулы, чарасы да!

* * *

Иң явыз хәйләкәр, хәйлә иясе — шайтандыр... Ул мәңгелек көндәше кешенең күңеленә, рухына, җанына үтеп керү өчен бөтенесен дә эшли һәм үтеп кереп, буыннан буынга күчеп, шунда әзергә-бәзер гомер кичерә.

* * *

Шайтаннар, сихерчеләр, ымчылар хәйләсеннән саклану өчен иң үтемле чара — Иман!!!

## 14

* * *

Иҗат — алгарышның беренче шарты, әмма иҗатчы җәмгыятьтә беркайчан да түрдә булмаган.

* * *

Иҗат — рух талпынуы, кузгалуы, чистарынуы, рух ихтыяҗы.

* * *

Чын Иҗат — Аллаһы рәхмәте һәм фатихасы, Аллаһы фатихасы алган иҗатчы — пәйгамбәр.

* * *

Иҗатчы — рухи азатлыкка омтылучы, шуны яулаучы...

* * *

Иҗатчы һәм Хаким — һәрчак көндәшләр. Соңгысы җәмгыятьтә үз абруен һәм өстенлеген саклап калу өчен иҗатчыны үз ягына аударып, «сарай җырчысы» ясый... Хәйлә белән аны данга күмә... Әгәр инде иҗатчы аңа күнмәсә, хаким-тиран аны дарга менгерә...

* * *

Иҗатчының үз кыйбласы булмаса, аның иҗаты да урта кул булыр.

* * *

Иҗатчы — һәрчак миссионер, буыннарның, чорларның рухи чылбырын төзүче һәм тоташтыручы.

* * *

Иҗатчыны үзе теләгәннән артык берьялгызы калдырмагыз.

* * *

Иҗатчы өчен әдәби караклыкта, плагиатлыкта гаепләү һәм шикләнүдән дә түбәнрәк мыскыллау юк...

* * *

Пәйгамбәрләр мең елга бер генә туа. Үзеннән соң иҗаты йөз ел яшәгәннәр дә — пәйгамбәр!..

* * *

Даһи иҗатчыны тудырган Ата-Ана да, Халык та рухи югарылыкта.

* * *

Даһи иҗат — шул ук догалык!..

* * *

Балалардагы иң олы ихтыяҗ — мөстәкыйльлек һәм иҗади шөгыль. Мөстәкыйльлеккә ирешү-ирештерү җиңел түгел, аңа иҗади шөгыль аша ирешеп була... Иҗат — һәрвакыт мөстәкыйльлек...

* * *

Остазлык — иҗади хезмәт. Сәләтле иҗатчы табу һәм остазлык итү иҗади осталык, түземлек таләп итә...

* * *

Иҗатчының төп хөкемдары — вакыт.

* * *

Сараенда шагыйрь тоткан патша — һәрчак затлы... Иле, дәүләте — зыязатлы.

* * *

Сарай шагыйре — вәзир, казый, илче, киңәшчеләрнең иң-иң җаваплысы...

* * *

Шагыйрь үзе бер дөнья, дәүләт... Шигырьләре — аның таулары, елгалары гына түгел, ә мәктәпләре, мәдрәсәләре, хәтта кануннары да.

* * *

Шагыйрьне олылап пәйгамбәргә тиңләү — һич кенә дә икенчесен кечерәйтү түгел...

* * *

Шагыйрь — шәрабсыз дә исерек.

* * *

Шагыйрьнең сәрхушлеге — шигырьдән чигенүеннән бигрәк шайтанга килеше...

* * *

Шайтанга да шигырь кирәк...

* * *

Шагыйрьнең нәфрәте дә мәхәббәтеннән килә.

* * *

Шагыйрьнең дә исеме бер генә түгел...

* * *

Шагыйрьнең китабы берәү генә була. Бөтен гомере буе язган барлык шигырьләренең иң асыллары, илаһының нурына манып язылганнары, тупланганы...

* * *

Шагыйрьдән: «Кайда, кем булып эшлисең?» — дип сорау әдәпсезлек...

* * *

Шагыйрьлек һөнәр түгел, кәсеп иткән шагыйрь — көнлекче...

* * *

Шагыйрь — күзләре күрмәсә дә, сукыр түгел!..

* * *

Шагыйрьнең Анасы — изге җан!

* * *

Шагыйрь — иҗатта мәңге ач һәм шыр ялангач...

* * *

Шагыйрь сугыштан ярасыз чыкмас...

* * *

Шагыйрьнең сугыш каһарманына дан җырлавы аның фаҗигасе. Сугыш каһарманының фаҗигасен ачуы — аның шагыйрьлеге дәрәҗәсе...

* * *

Ялгызлык шагыйрьне җанына якынайтыр.

* * *

Шагыйрь салган күперләрне бер ташкын да җимерә алмый!..

* * *

Шагыйрьгә: «Соңардың», — димәгез.

* * *

Шагыйрьнең йөзе генә шадра булырга мөмкин.

* * *

Шагыйрь энәсе — һәрчак саплаулы...

* * *

Шагыйрь — Аллаһының иң иркле колы.

* * *

Шагыйрьне дә шайтаннан бары Иман гына йола ала.

* * *

Шагыйрь теләгәне — бер Аккош күледер.

* * *

Шагыйрь — Шаһ ир.

* * *

Шагыйрь — барлык ел фасылларын берьюлы үткәрүче.

* * *

Шагыйрен хәер эстәткән илнең киләчәге юк.

* * *

Үз әсәренә әсир әдип — аягөсте төш күрүче.

* * *

Шигырь — җанга бәлзәм, шуңар аны да тамчылап кына эчү фарыз.

* * *

Шигырьдән бизгәннең күңеле тутыгыр...

* * *

Шигырь аһәңендә галәми мәгънә, моң бар.

* * *

Шигырь — кояш ул, күктә һәм күңелдә,
Үзеңә якынайт, йөрәгең белән үрел дә...

* * *

Шигырь — рухның шифалы тамчысы.

* * *

Шигырь — ут, яшеннең дәһшәтле камчысы...

* * *

Шагыйрь — милләт бишеге сагында торучы фәрештә.

* * *

Һәр шагыйрь — милләт бакчасы, һәр шигырь — милли җимеш... Керә күрмә, өзә күрмә, пешеп җитмәгән килеш.

## 15

* * *

Исем — җисемнең тамгасы. Ата-Ана баласына исемне аның нинди булуын теләгәннән чыгып кушадыр... Исемдә зурлык, көчлелек, миһербанлылык сыйфатлары кушылуы бик тә күркәм.

* * *

Һәркем кимендә өч исемне: бабасыныкын, атасыныкын һәм үзенекен йөртә... Ике буын аның исеменә бәйле — улы, оныгы. Биш буынга исемең бәйле икән, аларга лаеклы булу нинди җаваплылык!

* * *

Исеме җисеменә туры да килмәскә мөмкин, ә кушамат һәрвакыт мач...

* * *

Җисеме һәм әһәмияте чиксез зур булганнарның да исемнәре бик кечкенә һәм кыска булырга мөмкин: су, күл, күк, һава, Кояш, Ай, Җир, Оҗмах, Аллаһ, Җан...

* * *

Исеменә исем китте,
Җисеменә хисем хуш!

* * *

Исемнәр искерә,
Җисемнәр төс бирә...

* * *

Мәртәбәле исем мөртәткә дә бирелә... Шуңа күрә андый исемнәргә исең китмәсен, Аллаһы биргән Кеше дигән исемгә лаек булырга тырыш.

## 16

* * *

Дәрәҗә кешене озаклап күтәреп тора алмый,
Кеше үзе дәрәҗәне күтәрергә тиеш — хәленчә...

* * *

Кешенең дәрәҗәсе һәрчак үзе белән...

* * *

Дәрәҗә — әхлакый төшенчә... Аны биек урындагы эш яки дәрәҗәле эш урыны белән бутарга ярамый, һәр дәрәҗәле урындагы бәндә дәрәҗәле түгел.

* * *

Сатып алган дәрәҗәне дә саклау кыен.

* * *

Дәрәҗәгә сыен, әмма аның колы булма. Үз дәрәҗәңә дә сыен, үз дәрәҗәңнең дә колы булма...

* * *

Дәрәҗәле — иң беренче чиратта ирекле һәм эшлекле.
Тик эшлекле кол беркайчан да дәрәҗәле булмас.

* * *

Дәрәҗәле кунакка да тыйнак булу фарыз.

* * *

Тату гаилә башы булу — һәрчак олуг дәрәҗә.

* * *

Дәрәҗәсенә карап хөрмәт итү — гаделсезлек түгел.

* * *

Һәрчак дәрәҗәңнән өстен бул...

* * *

Бар белгәнен башкаларга белдерүчене бер үк вакытта галим дип тә, бушбугаз дип тә атарга мөмкин.

## 17

* * *

Туган йортын сагынудан туктаган — туганлыктан бизгән. Үткәненнән ваз кичкән...

* * *

Туган йортта тыгын булмый: булса да сыеныр урын табыла.

* * *

Туган йортларын бүлгән (сатып акчасын бүлгән) туганнарның кайтыр юлы киселгән.

* * *

Туган йорттан туганын читләштергән — туганлык чылбырын өзүче...

* * *

Туган рәнҗеше туганга төшә... Туганын кичерә алган — саваплы.

* * *

Туган йортны төзек тоту — шунда торган туганның һәм барлык бертуганнарның бурычы.

* * *

Туган йортта барлык бертуганнарның да өлеше бар... Әмма Туган йорт — төпчекнеке... Туганнар арасында гарип булса, туган йортта аның сыенып җире түрдән булырга тиеш...

* * *

Туган йортында газаплар күрсәң дә, аннан бөтенләй киселмә, гомерең азагында шунда кайтып сыенырга язмасын...

* * *

Туган йорт — туганлыкның тирән тамыры...

## 18

* * *

Гаилә өч буын — бабай-әби, ата-ана, балалар булганда гына тулы була. XX гасыр ятим гаиләләр, тулы булмаган гаиләләр гасыры булды. Тулы булмаган гаиләдә борынгы йолалар югала...

* * *

Гаиләдә сорыкортлылыкка юл куймау — иң әһәмиятле шарт.

* * *

Һәр гаиләнең көтелмәгән хәлләр, авырлыкларны җиңеләйтү өчен маясын булдыру — ата-ана вазифасы.

* * *

Гаиләң тормышына чит-ятларның йогынтысын кертү — ятимлек, ялгызлык, гаиләне таркатуга төп сәбәп.

* * *

Гаиләсендә балалары юклар — бу дөньяга соңгы тапкыр килүчеләр...

* * *

Кыюсыз ирләргә комсыз хатыннар насыйпмы?

* * *

Хатыннарга — акылына, ирләргә хатынына карап бәя бирәләр...

* * *

Ирне  ир иткән — хатын,
Ирне  хатын иткән — үзе...

* * *

Тәкъдиреңә ни язганын кемнәндер юратма, бабаңнарның, ата-анаңның гомер юлларын ныклап өйрән һәм үзеңә нәтиҗәләр яса.

* * *

Син кичергән кыенлыкларда үзеңнең кайчандыр җибәргән ялгышлыгың сәбәпледер... Шуны ачыкла һәм балаларыңны шул ялгышны кабатлаудан арала...

## 19

* * *

Гадилек — кешенең һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең иң аңлаешлысы...

* * *

Гадилек: холык, фигыле камил — дуамал түгеллекне, үзенә күтәренке бәя таләп итмәүне һәм гаделлек ягында торуны чагылдыра.

* * *

Гадилек — һәркем күтәрелә ала, әмма һәркем шунда кала алмый торган биеклек.

* * *

Гадилек — ныклык һәм ышаныч билгесе.

* * *

Гадилек — күпчелек халык гомер итә торган мохит.

* * *

Нәфесен йөгәнләгән — һәрчак гади.

* * *

Ярлылык — гадилек билгесе түгел, ул — мохтаҗлык билгесе.

## 20

* * *

Көлү — табигый халәтнең тышкы билгесе, чагылышы...

* * *

Бәхетле кеше елмайганда иреннәре генә түгел, ә күзе, йөзе, карашы, гомумән, бөтен тәне елмая, рәхәт дулкынлану кичерә.

* * *

Елмаю — күңелнең госел коенуы.

* * *

Хәсрәтле кеше янында көлү, аны көлдерергә тырышу — тәрбиясезлек, әдәпсезлек.

* * *

Мыскыллап көлү — рәнҗетү... Рәнҗеш һәрвакыт әйләнеп кайта.

* * *

Сүз әйтеп көлдерү — тапкырлык,
Ишарә, хәрәкәт белән көлдерү — маймыллык.

* * *

Мыскыллап кешегә ияреп көлү дә гөнаһ.

* * *

Кешедән көлгән — кеше көлкесенә калган.

* * *

Көлке кәефне күтәрә, тамакны туйдырмый...

* * *

Сабый бала елмаюыннан да ихласлылык юк…

## 21

* * *

Елау — табигый халәтнең үзенчәлекле бер билгесе. Тәннең, күңелнең борчылып дулкынлануы, авыртуы, гарьләнүе, кимсенүе, әрнүе, рәнҗүе. Күз яшьләрен күрсәтми калганнар — үз-үзләрен тынычландыра белүчеләр.

* * *

Җан елаганда күз яшьләре күренмәскә дә мөмкин...

* * *

Күз яше йөзне ашый...

* * *

Сәбәпсез елаган баланың өстен алыштырыгыз, туктамаса, дога кылып өшкерегез.

* * *

Елап кызгандыру гадәте дә була... Кызганган саен аларга кызык.

* * *

Елаган баланың авызына мәми каптыралар,
Елаган әзмәвернең артына сугалар...

* * *

Мәет өстенә яшь тамызмыйлар.

* * *

Гөнаһны күз яшьләре белән генә юып булмый.

## 22

* * *

Бәхет һәрдаим янәшәдә: янда, баш өстендә, аяк астында.
Көтмәгәндә килгән куаныч та — бәхет!
Сагаеп көтелгән кайгы килмәсә дә — бәхет!

* * *

Көттереп килгән бәхет бәрәкәтле.

* * *

Бәхет — җан тынычлыгы, тән саулыгы, рухның зурлыгы, югарылыгы!

* * *

Бәхет — яраткан кешең булу, яраткан эшең булу, гаиләңнең яшәешен тәэмин итә алу. Сине ярату-лары, синнән канәгать булулары, сиңа тугры булулары.

* * *

Кемгәдер бердәнбер булу — бәяләнерлек бәхет.

* * *

Бәхетенә шөкер итмәгәннәрдән бәхет качып китәр.

* * *

Барын да белгән, барын да булдырган — бәхетсез түгел.

* * *

Байга бәйләнеп кенә бәхет иңми. Байга бәйләнеп бәхетең кимергә мөмкин.

* * *

Бәхетле булу өчен байлык та бик кирәк. Баеп бәхетсез булганнар ни диярдер?

* * *

Баласыз йорт — бәрәкәтсез, бәхетсез йорт. Баласы башыннан йөргән йорт та бәхетсез йорт.

* * *

Бәхет — байлыкта, мал-мөлкәттә, бер-береңә хөрмәттә.

* * *

Бәдбәхет үзенең бәхетсезлегендә һәрчак кемнедер гаепләр... Үзенең кемнәрне бәхетсез итүен уйлап та бирмәс.

* * *

Туган нигездә тигез гомер кичерү — һәркем теләгән, әмма һәркемгә дә насыйп булмаган бәхет...

* * *

Бәхеттән башлары әйләнмәгәннәргә бәхет гел килеп торыр.

* * *

Мал бүлешү бәхет бүлешү түгел... Бәхетне өлешләп бүлеп булмый. Бәхет уртак куаныч кына була ала.

* * *

Илен җуйган, телен җуйган халык мәңге бәхетсез...

* * *

Ата-ана фатихасы — бәхеткә юл...

* * *

Бәхет ике дөнья өчен дә хас төшенчә... Дөньялыкта бәхет сынавын үтә алган, ахирәттә дә бәхеткә кинәнер, оҗмах түрендә булыр.

## 23

* * *

Сәламләшү — кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең күркәме. Ул бер-береңә исәнлегеңне белдерү һәм тагы да исәнлек теләү...

* * *

Сәламне алмау өчен гадәттән тыш сәбәпләр кирәктер... Бер генә сәбәп тә исәнлек теләүдән өстен була алмый.

* * *

Язып җибәрелгән сәлам — истәлек тә...

* * *

Ата-ананың, балаларның үзара исәнлекләрен белешеп тору гына түгел, ә аларның исәнлеген кайгырту һәр ике якның да бурычы.

* * *

Тәңречелектә кояшны таң белән сәҗдәдә сәламләү йоласы булган... Кешене ул галәм белән бәйләгән, бербөтен иткән... Ходайга якын иткән...

* * *

Иң олы сәламләү — Аллаһыга, намазда, сәҗдәдә. Аллаһы безнең сәламгә мохтаҗ түгел. Без — кешеләр —һәрдаим аның игътибарына, ярдәменә мохтаҗ, саулык-исәнлек өчен иң әүвәл...

* * *

Иң тәэсирле сәламләү — баш иеп, кул бирешеп, күзгә-күз багып һәм ачык йөз белән...

* * *

Сәламләшмәгән туганнардан да түбән затлар юк...

## 24

* * *

Гөлләрнең иң матуры — кышын чәчәк атканы.

* * *

Гөлләр йортка ияләштерелгән терлекләр кебек үк, һәркемгә бик кирәк. Беренчеләре азыклану өчен булса, гөлләр — күңел өчен, рух өчен, күзләр өчен.

* * *

Гөлнең бөтен матурлыгы — чәчкәдә. Чәчкә атмаган гөлләр аерым матур...

* * *

Гөлләрнең кайсысы ерактан матуррак күренә... Һәр матурны тотып карау, татып карауның ихтыяҗы юк.

* * *

Йортында бер генә тере гөл тотмаган, үстермәгән хатын-кызның күңеле җиде йозакта булыр.

* * *

Гөлләр нигездә бер-берсе белән күршелекне яхшы кичерәләр... Димәк, матурлыкта һәркайсы кабатланмас икәннәрен беләләр һәм бер-беренә комачаулык итмиләр. Көнләшмиләр...

* * *

...Матурлыкны тану өчен үзең матур булу кирәк.

**25**

* * *

Киңәшле эш таркалмас, киңәш бирүчеләр күп булса, бөтенләй дә башланмас.

* * *

Патшалар вәзирләре белән бергә юләрләр дә тотканнар. Алардан да киңәш сораганнар. Юләр тагы да «юләргә» сабышып, хакыйкатьне ярып салган... Бүгенге түрәләргә элекке патшалардан үрнәк алу бик тә кирәктер.

* * *

Акыллы киңәшчеләр яки акыллылар киңәшләре өчен хак ала... Бушка киңәш өләшеп йөрүчедән ерак тор...

* * *

Акыл сатучының киңәшен бушка да алучы юк.

* * *

Киңәш бирүченең максатын ачыкларга тырыш: тәкъдимнәре кемнәндер үч алуга, яла ягуга юнәлмәгәнме? Киңәш сорап килүченең дә максатын ачыкла: сереңне урларга килмәгәнме?

* * *

Иң якын киңәшчеләрең — әткәң, әнкәң һәм үзең. Җиде кат үлчә, бер кат кис...

* * *

Сүзләргә колак сал: күзең — ачык, авызың ябык булсын.

**26**

* * *

Булдыксызлык — чикләнгәнлек. Эшлексезлек — гадәт. Булдыксызны эшлексезлектә гаепләүдә һәм эшлексезне фидакарьлеккә өндәүдә мәгънә юк.

* * *

Эшлексез эшләмәскә мең сәбәп эзләр,
Булдыксыз — эш арасында буталып йөрер...
Һәр икесе «хезмәтенә» югары бәя сорар.

* * *

Күмәк хезмәттә кемдер төяр, кемдер иңен сөяр (сөяп торыр)...

* * *

Эшкә ихтыяҗ булганда мохтаҗлык чигенер...

* * *

Эш хакының күпме булуыннан бигрәк, күпмегә җиткерүең әһәмиятлерәк.

* * *

Хакын белмәгән эшкә алынма, килешүсез аны башлама.

* * *

Ялланып эшләүчегә ялланма.

* * *

Арадашчы — төшеп калганны эләктерүче...
Арадашчыга арадашчы булма — буш калырсың.

* * *

Арадашчы — кармаксыз, җимсез балык каптыручы.

## 27

* * *

Ялгызны ял ялкытыр.

* * *

Ялгызыңа бербөтен булудан, — гаиләңдә яртылаш булу хушрак.

* * *

Ялгызның уйлары — чиксез, йокысы — сак, ястыгы — юеш.

* * *

Ялгызның бердәнбер өстенлеге — бар тапканы берүзенә булу.

## 28

* * *

Ямау — һәрчак искелек билгесе.

* * *

Гайбәтченең авызын ямаудан файда юк.

* * *

Ямау — җөйсез булмый.

* * *

Өр-яңа ямаулык та иске бөтеннән матур түгел.

* * *

Өзелгән хисне, тойгыны ялгап та, ямап та булмый.

* * *

Ямаулыны кигән яңаның кадерен белер.

* * *

Ямау өстендәге ямау — сакчыллыктан бигрәк, ярлылык...

## 29

* * *

Җәмәгатьчелек фикерен дә кемдер уйлап чыгара һәм тарата. Ул да халык авыз иҗаты.

* * *

Җәмәгать милке — уртак мал: җаен белеп алсаң — синеке, белмәсәң — җаен белгәннәрнеке...

* * *

Җәмәгатьчелек — дошманыңның авызын яптыру өчен кулланыла торган корал.

* * *

Җәмәгатьчелек — булдыксызлыгыңнан һәм эшсезлектән саклану чарасы...

* * *

Җәмәгатьчелек — күз алдында табынучы, үзе юкта батыручы, бердән алып йөз миллионга кадәр ярым аңгыраларның оешмаган оешмасы...

* * *

Җәмәгать эше — шәхси талантка һәм сәләткә ия булмаганнарның талантларын һәм сәләтләрен ачу өмәсе.

* * *

Җәмәгатьчелек фикере белән артык мавыгу җәмгыятьне болгатуга, буталчык тудыруга китерә. Иң катлаулы хаос — җәмгыятьтә җәмәгатьчелекнең үзара килешмәс төркемнәргә бүленүедер... Күп илләрдә озак вакытларга, хәтта дистә елларга сузылган ватандашлар сугышының башы да җәмәгать фикереннән килеп чыккандыр әле, баксаң...

* * *

Җәмәгатьчелек фикере һичкайчан рәсми кануннардан өстен була алмый...

## 30

* * *

Ишарәне — кул белән дә, күз белән дә, ым белән дә «күрсәтеп» була... Фикер әйтү өчен — сүз, сүз әйтү өчен — тел кирәк!

* * *

...Мәгънәле сүз мәгънәсез гамәлдән чигендерә ала, әмма мәгънәсезлектән котылу өчен сүз генә җитми...

* * *

Сүздән ботка пешереп була, ашап булмый...

* * *

Сүгенүчеләр — шул әгъзалар биеклегендәге бәндәләр.

* * *

Сүгенүнең исе һәм төсе — косыкныкы.

* * *

Телсез ризык тәмен белә, сүз тәмен белми.

* * *

Куркакка һәрчак дәшмәү яки ялвару язган...

* * *

Әйткәнеңнең мәгънәсе — кайтарып әйтелгән сүз дәрәҗәсендә... Дәшмәсәләр — ишетмәгәннәр һәм кабул итмәгәннәр булыр.

* * *

Сүз әйтеп терелтеп була, үтереп була... тудырып булмый.

* * *

Әйтергә онытылган сүз хәтерсезлек кенә түгел, сүзнең зәгыйфьлеге дә.

* * *

Кыек утырып туры сөйләргә маташучыны бөкресе фаш итәр...

* * *

Туры таякка таянып кына тураеп булмый.

**31**

* * *

Сабантуй — сабый хәтеренә сеңеп, гомер буе кабатланып, өстәлеп торган күңел җилкенүе.

* * *

Бәйрәмнәр уртакка әйләнгән саен, ритуалга әверелә — истә бар, күңелдә юк...

* * *

Бәйрәмнәрне дә урлап була икән. Сабантуйдагы иң гадел көч көрәше хәйлә, алдау көрәшенә әйләнер... Сабантуй мәйданын чит халык батыры тотар... Чит телдә сөйләнер, чит көйләр яңгырар... Татар бер почмакта дуңгыз шашлыгы әзерләп йә көнбагыш сатып торса ярый инде... Аллаһым бер, сакла!!!

**32**

* * *

Риясызлар бүләккә һәм рәхмәткә мохтаҗ түгел.

* * *

«Энә дә бүләк, дөя дә бүләк», —  дип, бүләкне алучы түгел, бирүче әйтер...

* * *

Бүләкне бүләккә бирмиләр дисәләр дә, бик кирәктә биреп тору, хәтта бөтенләйгә бирүдә гаеп юк.

* * *

Бүләкнең бәясен белдерүдә гаеп юк.

* * *

Бүләктән баш тартучыга сәбәбен аңлату мәҗбүри түгел...

* * *

Мохтаҗлыгы булмаганнар да бүләккә битараф түгел.

* * *

Бурның бүләге — таланган мал... Гөнаһы онықларыңа төшмәс дисәң — ал.

* * *

Өҗәткә бүләк бирмиләр.

## 33

* * *

Сугыш — уеннан чыккан уймак,
Шул уеннан юк туймак...

* * *

Сугыш — җан биреп дан алу,
Кан биреп казану.

* * *

Сугышка бармый калганнар... тәнгә туенганнар.

* * *

Беркем белми — сугышта:
Кемнәрнең җиңеләсен,
Кемнәрнең җиң эләсен...

* * *

Сугыш фәнен мәктәпләрдә укыту һәм гомуми хәрби бурыч үтәү — чарасызлык, мәҗбүрилек...

## 34

* * *

Җаның бик теләсә дә,
Елан итен ашама...

* * *

Тәкъдиренә буйсынган бәхетенә тигәнне тизрәк таба...

* * *

Чокырдан кемнеңдер иңсәсенә басып чыгуга, аны да тартып чыгарырга онытма...

* * *

Кулыңнан килгәндә алып кал, биреп кал...

* * *

Сорауга караганда бирү һәрчак җиңел.

* * *

Сорап килгәнне тыңла... Бирмәсәң дә куып чыгарма...

* * *

Сүзендә торалмаган белән алыш-биреш итмә... Иң соңыннан ул сиңа күпкә бурычлы булып калачак, әмма түләмәячәк.

* * *

Булганны даими барлап тор...

* * *

Уртак малны әҗәткә бирмиләр...

* * *

Изге ният белән дөресен әйтмәгән — барыбер алдакчы.

* * *

Биреп торганны кире сорауның гаебе юк, бүләк иткәнне кабат дәгъвалау — ямьсез күренеш...

* * *

Бүләкне сорап алу ришвәт алуга тиң...

* * *

Чума чорында да рәхәткә чумучылар була.

* * *

Уртак мал белән яшәсәң дә, уртак яр белән яшәмә...

* * *

Уртак тиз таушала һәм ташлана.

* * *

Бүрегә янмый торган караклар — хакимнәр һәм хөкемдарлар.

* * *

Талымсызның теше тизрәк төшә...

* * *

Хатын-кыз талымсызлыгы һәрчак матур түгел.

* * *

Мунчала: тәннән дә, идәннән дә фәкать кер юу өчен генә...

* * *

Үз-үзеңә көнозын көзгедән карап торганга караганда үз-үзеңне читтән бер карап алу яхшырак...

* * *

Рәсәйдә учлап та, капчыклап та, олаулап та, эшелонлап та урлыйлар... Хөкемгә күбрәк беренчеләре тартыла...

* * *

Байларның бичәсе берәү генә булмый...

* * *

Күз буяу — урта кулны бизәкләп матурларга маташу, булган табигый матурлыкны бозу.

* * *

Күз буяучылар һәр өлкәдә дә буа буарлык, сәясәттә... аларның сазаганнары.

* * *

Буялган = бу + ялган...

* * *

Буялганны бусагаңа бастырма.

* * *

Шымчы һәр кешедә җинаятьчене, җинаятьче һәр кешедә шымчыны күреп шикләнер — алар бер калыптан.

* * *

Шом — шом тудыра, бәвелне кудыра.

* * *

Шәрә тән тиз туза.

* * *

Шом арту шомартудан узган.

* * *

Шым — хаким хәле,
Шом — халык хәле.

* * *

Шиксезнең ишеге биксез.

* * *

Усаллык — тискәре сыйфатларның берсе... Әмма усалларда гаделлек һәм горурлык та бар. Усал — явыздан миһербанлы һәм кешелекле.

* * *

Усал теленә һәм кулына ирек куяр. Усалдан ерак бул, якынайса курыкма, нык тор.

* * *

Усал ике әйтмәс. Үзенә бер дә әйттертмәс.

* * *

Үз балаларына, ата-анасына усаллар — явызлар. Алар белән эшең булмасын.

* * *

Явызның азыгы — ятларның газабы.

* * *

Явызлыгын авызлыклаганнар Аллаһыдан ярлыкаланыр...

## 35

* * *

Ялкауга ятып та җиңел түгел.

* * *

Ялкаудан: «Ни эшлисең?» — дип сорасаң:
— Әле яңа яттым! — дияр.

* * *

Ялкауның төп яшәү урыны — ятак.

* * *

Ялкау — «ял» + «куа», «ял артыннан куып баручы» мәгънәдәге сүзләрдән яралган.

* * *

Ялкауны һәрчак өендә табарсың.

* * *

Ялкау ялкауны яратмас.

* * *

Ялкауның әһәмиятле эшләр башлыйсы көне — һәрчак алдагы дүшәмбедән, аеруча ашыкканда иртәгәдән...

* * *

Ялкауның ятагы һәрчак җәелгән булыр...

* * *

Ялкауның якшәмбе көнге йокысы — егерме дүрт сәгать.

* * *

Ялкаулар белән дөнья тулган. Әмма ялкауларның үз җәмгыятьләре, үз фиркаләре һәм календарьда үз һөнәри көннәре мәңге буласы юк.

* * *

Өендә ялкаулык күрмәсә, бала ялкау булмый...

* * *

Ялкауның ялыкмаган шөгыле — ял һәм йокы.

* * *

Ялкау сүзләргә, вәгазьгә битараф.

## 36

* * *

Адәм балалары иң саксыз караган, пычраткан һәм исраф иткән байлык — Җир һәм Су.

* * *

Җир һәм Су кадерен чүлдә яшәүчеләр ныграк беләләр... Шул ук вакытта аларның чүлдә яшәүгә дучар ителүе дә юкка түгелдер...

* * *

Эчәр суга төкерсәң — телең корыр, печ итсәң — гаурәтең корыр.

* * *

...Җир өстендәге һәрни — аяк астындагы түгел.

* * *

Җир — тере... Ашатмасаң, эчертмәсәң ул да үлә.

* * *

Җир белән Күк арасында бернинди аралык та юк.

* * *

Җиргә ятып елау — вөҗданның уянуы, тәүбәгә килүдәге беренче адым.

* * *

Аллаһы Җирне җитәрлек итеп яраткан — кешеләргә дә, хайваннарга да, бөҗәкләргә дә, үсемлекләргә дә. Әмма аларның берсенә дә җир җитми... Һәркайсы үзенә тиешледән күбрәк җирне даулый, дәгъвалаша, сугыша, яулап ала... югалта. Җиргә туймасларны җир ахырда үзенә йота...

* * *

Җир — тоташтан каберлек.

* * *

Җир — Ана.
Җирсез халык — үги халык.

* * *

Җанга — Күк хуҗа,
Тәнгә — Җир хуҗа.

* * *

Җиргә табыну да, Күккә табыну да гөнаһ түгел.

* * *

Күк — мәңгелек китап. Укыйсың килсә, төнен йоклама.

* * *

Күк күзенә ком керми.

* * *

Күкләрне гизәр өчен Ай булу гына җитми...

* * *

Күккә кеше тәне тансык түгел.

* * *

Күктән кайчан да булса кызыл кар явачак... барыбер.

* * *

Күк чиксез — андагы җанлы һәм җансыз матдәләр дә чиксез.

## 37

* * *

Туганыңа турысын әйтеп тә ярап була.

* * *

Тайгакта таянырың — тик туганың гына.

* * *

Туганыннан тарсынган тәмугка тарыр.

* * *

Туганлык кайгы килгәндә генә түгел, байлык килгәндә дә сынала...

* * *

Туганнан алган бурыч та түләнергә тиеш.

## 38

* * *

Бәләкәй буйлыга бәйләнмә.

* * *

Бәләкәйләр дөньяны болгатып торырга ярата, шулай иткәндә аста калып сытылмау мөмкинлеге арта.

* * *

Бәләкәй баш булудан бәрәкәтләнер.

* * *

Олы бәләкәй белән булашмас,
Бәләкәй олы белән беркайчан да уңышмас.

* * *

Олының вак булуыннан
Бәләкәйнең эрелеге хәерлерәк.

## 39

* * *

Нахак сүз — арттан атылган агулы ук.

* * *

Гайбәт сүзне көнчеләр чыгара. Көндәшенә, дошманына авырлык, кыенлык, борчу салу өчен. Гайбәт сүзнең кемнән чыкканын анык белмәсәң — яңа көндәшең, яңа дошманың килгән дип бел.

* * *

Үзеңне үзең алдауның иң анык үрнәге — күзеңне йомып, мине күрмиләр дип уйлау.

* * *

Саран һәрчак алдакчы...

* * *

Мактанчык һәрчак алдакчы.

* * *

Мактанчыкның авызы гел ачык.

* * *

Мактанчыклар «бир» сүзен яраталар. Ялгыш кына чыккан «мә» сүзеннән дә мактану өчен генә файдаланалар: «Бирдем кирәген», «Күрсәттем күрмәгәнен».

* * *

Мактанчыкларның күп нәрсәсе очсыз, әмма ялтырап торыр...

* * *

Мактанчыкның авызыннан чыккан иң беренче хәреф — «М», иң беренче сүз «МИН» булыр.

## 40

* * *

Дус булмасаң да татулыкны саклау фарыз.

* * *

Дуслык хакына хокук бозу хилафлык һәм хаталык...

* * *

Дусның дусына син дус булмаска да мөмкин.

* * *

Бер дусты һәм бер дошманы булмаганнар да бар...

* * *

Дуслыкны — дошманнар, туганлыкны — дуслар боза...

* * *

Риясыз дуслык та була ала...

* * *

Дуслык — вакытлы күренеш,
Туганлык — гомерлек...

* * *

Дуслыкны, татулыкны ныгыту, ышанычлы итү өчен патшалар кыз биргәннәр, кыз алганнар, туганлашып күпмедер дәрәҗәдә морадларына ирешкәннәр дә.

* * *

Илләр, дәүләтләр башлыкларының дуслыгы — рәсми, церемониаль күренеш яки реклама, абруйлану чарасы — шуннан ары берни түгел.

* * *

Дуслык — кешеләр арасында мөмкин булган мөнәсәбәтләрнең хуплауга, мактауга лаеклысы.

* * *

Ике яки берничә кеше арасындагы дуслык башка һичкемгә комачаулык итәргә тиеш түгел.

## 41

* * *

Рәхәтне бит күрә белү кирәк,
Рәхәткә дә түзә белү кирәк.

* * *

Мескенлек — коллыкка тиң түбәнлек. Мескен кешеләр генә түгел, мескен ыру, мескен халыклар бар.

* * *

Мескеннең тамагы тук, акчасы күп, өсте бөтен, саулыгы да шәп булырга мөмкин. Әмма акылы сай, күңеле тар, рухы зәгыйфь, карашы фәкыйрь, иң мөһиме — иреге булмас...

* * *

Кеше хакына керү барыбер кайчан да булса фаш ителә, һәм хәрам җыйган барыбер казага юлыга, тарый. Шуңа да кеше хакына керүче үзенең килеренә, үзенең һәм гаиләсенең өлешенә алдан әҗәткә керә.

* * *

Әҗәткә керү — үз-үзеңне күпмедер дәрәҗәдә залогка кую ул. Гел әҗәт исәбенә яшәүчеләр бар... Әҗәткә бирү тукталгач, алар хәер сорашырга күчәләр...

* * *

Коръән хәерчелекне инкарь итми. Аларга ярдәм итүне адәмнең (мөселманның) бер фарыз гамәле итеп билгели... «Җан биргәнгә җүн биргән» дигән әйтемнән «Аллаһы үзенең бәндәсен ташламас», дигәнне дә аңлап була.

* * *

Хәер бирү фарызлыгы — бәндәләрне табигый казалардан килгән газаплардан коткару өчен, ярдәм итү йөзеннән килә иң беренче чиратта.

* * *

Риясыз хәер рәхмәтсез калмый. Хәер биргәнгә Раббы үзе бирә...

## 42

* * *

Әрсезлек иң тискәре сыйфатларның берседер.
Әрсезлеккә этәргән — һәрвакытта нәфеседер.

* * *

Әрсез — ялагайның бертуган абыйсы. Яки алар игезәкләр...

* * *

Әрсез — шул ук карак... Әмма ул яшертеп урламый, күзгә карап: «Бу миңа бик кирәк», — дип ала... Яки: «Бу минеке!» — ди.

* * *

Әрсезне әрләп кенә оялтып, тәрбия кылып булмый, әрсез һәр чиратта һәрчак беренчедән соң булыр...

* * *

Әрсездә — ялагайлыктан кала икенче үтмәс чир — көнчелек. Әрсезләр үз дусларыннан, туган-тумачасыннан, хәтта ата-анасыннан да көнләшергә мөмкин.

* * *

Кешедә юк — байда һәм әрсездә булыр.

* * *

Әрсезнең үкенгәнен күрмәссең.

* * *

Әрсез аерым хәлләргә карап бик батыр һәм бик мескен була беләә.

* * *

Әрсезләр мескеннәр, мохтаҗлар өлешенә дә өметләрен сузарлар һәм алырлар.

* * *

Әрсезләр яла-ялган сүзне корбаннарының күзенә туп-туры карап әйтәләр...

* * *

Әрсезләр әр ала-ала үз кирәген ала.

* * *

Әрсезләр гарьләнми.

* * *

Әрсез — чакырылмаган кунак... Һәрчак буш кул белән килер, ни дә булса алып китәр...

* * *

Әрсездән ни булса биреп тә котылып булмый... Ул ялагай, яла ягучы, көнче һәм башка сыйфатларда әле бик күп мәртәбә зыян салачак.

* * *

Бер йорттан куып чыгарылган мәченең икенче бер йортка мәҗбүриләп, әрсезләнеп килеп кергәндәге ямьсезлеге — мин күреп белгән хайваннар арасындагы иң кызганыч күренеш...

* * *

Әрсезлек тәвәккәллек түгел... Әрсез, катгый бер карарга килеп, нидер таләп итәр һәм алыр... Тәвәккәл катгый бер карарга килеп гамәл кылыр һәм теләгенә ирешер...

* * *

Тәвәккәл таш ярганда, әрсез эчендәге төшен алыр...

## 43

* * *

Ут җибәреп суны парга очыралар,
Су җибәреп утны сүндерәләр.

* * *

Ут — иң каты халәт. Үзенә берни сеңдерми.

* * *

Ут курчак түгел — аңа күлмәк кидереп булмый, — уйнамагыз.

* * *

Ут аша узып булмый, узганы — ялкын гына.

* * *

Янмый торган матдә юк.

* * *

Җан тәнне яндырып чыга.

* * *

Имансызлар — тәмуг утыны...

## 44

* * *

Миһербанлык базарда сатылмый...
Әмма аны анда табып була...

* * *

Миһербанлык — кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең иң күркәме. Ата-ананың балаларына булган миһербанлыгы үрнәк булудан туктаса, бу җәмгыять, бу кавем юлын җуйган дигән сүз.

* * *

Миһербансызлыкны пропагандалауда дөнья телевидениесе кадәр «көч куйган» беркем юк...

* * *

Миһербанлыкка беренче адым нәфесне чикли белү, нәфес коткысыннан чигенү...

* * *

Миһербанлык күрсәтми бирелгән хәер-сәдакадан, риясыз ярдәмнән башлана...

* * *

Табигый хәлләргә «миһербансыз» тамгасы тагып без ялгышмыйбызмы?.. Әйтик, «Миһербансыз суык», «Миһербансыз давыл», «Миһербансыз эсселек», хәтта «Миһербансыз үлем» сүзен дә куллануда сак булу кирәктер, алар барысы да Аллаһы ихтыярына бәйле... Алардан үз вакытында сакланырга, Аллаһының саклавын сорарга кирәк...

* * *

Миһербанлык — Җанның Иманга сыенуы...

* * *

Кот качыру уенында бер генә тапкыр катнашып була.

* * *

Кош баласы анасының томшыгыннан азыклана, әмма бу бәхетне тату Күке баласына һәм анасына язмаган...

* * *

«Арбадан арбага күчеп утыруы берни тормый, җырларына кушылуы гына читенрәк», — дип әйтер чарасыздан кемдер...

## 45

* * *

Мәнсезлек — җавапсызлык, вәгъдәсезлек, башбаштаклык, әрсезлек, комсызлык, хиссезлек — бөтенесе бергә... берьюлы.

* * *

Чакырылган җиргә соңармыйча кил... тик беренчеләрдән булып түргә узып утырма...

* * *

Чакырылган кунак һәрчак игътибар үзәгендә булыр... тик тыйнаклыгын гына җуймасын да үз вакытында китә генә белсен...

* * *

Очлы сүз — язма хәлендә дә, телдән әйтелгәндә дә һәрчак үтәсе катламны үтә — үзәгенә җитә...

* * *

Мәйдан үлчәгәндә, үзәк һәрчак уртада...
Авырлык үлчәгәндә, үзәк нәкъ уртада булмаска да мөмкин.

* * *

«Үзәгең үзеңдә булсын!» дигәндә: «Үзеңә төшкән авырлыкны кеше җилкәсенә салма» дигәнне аңлау кирәк.

* * *

Үзәгенә үткәндә үзгәрми калган берни юк...

* * *

Үз вакытын үзе белгән. Димәк, үз кодрәтен үзе белгән, үз-үзен әзерләп җиткергән, өлгергән!

## 46

* * *

Комсызның кулыннан бигрәк карашы куркыныч...

* * *

Комсыз һәрнәрсәдә үзенең өлеше иң зуры дип тәкрарлар...

* * *

Комсызның күзе кысылган булыр...

* * *

Комсызның каберендә комнан ары берни булмас...

* * *

Комсыз — гомерлек хәерсез ( мәңге бер тиен хәер бирмәс)...

* * *

Комсызга каберең якын булмасын, ләхетеңне ачып кәфенеңне тартып алыр...

## 47

* * *

Милли микробларны күрү өчен яныңда һәрчак микроскоп йөртеп булмый...

* * *

Милләтеңә мәхәббәт хисләреннән дә бигрәк аның белән горурлану хисләре өстә тору фарыз...

* * *

Ана телен җуйган — башка күп телләр белүенә карамастан, милләтсез...

* * *

Чит кавемгә, чит милләт кешесенә кияүгә кыз бирү — аларның милләтен үрчетү, көчәйтү, куәтләндерү...

* * *

Үрчү-тудыруның төп чыганагы булган хатын-кыз — милли байлык... Аның физик тазалыгы, әхлагы, җисеме һәм рухи сафлыгы — дәүләт-милләт кайгыртуында, һәркемнең кайгыртуында булырга тиеш... Хатын-кыз азгынлыгына юл куйган дәүләтләр һәм җәмгыятьләр — үзләре утырган ботакка гына түгел, ә агачның тамырына балта чабучылар...

* * *

Милләтнең генофонды — нәсел-нәсәбәсен тәшкил итүче ир-атның җисемен һәм рухи тазалыгын кайгырту — диннәр, дәүләтләрнең олы бурычы...

* * *

Акылсызлыкны һәм бозыклыкны «тауар» хәленә җиткереп», табыш һәм керем исәбенә яшәгән милләтне, халыкны, дәүләтне Аллаһы каргышы барыбер тота...

* * *

«Милләт» ихтыяҗы» дигән пәрдәгә ышыкланып керем артыннан куган, шөһрәт артыннан куган кемсә — милләткә иң күп зыян салучы...

* * *

Милли киемең төссез, сәләмә һәм чабата булса, милли ризыгың дуңгыз ите һәм аракыга калса, һичбер кайчан сине ач-ялангач итмәсләр...

* * *

— Күк капусы ачылса, теләр идең ни теләк?
— Милләткә бер ир кирәк!..

* * *

Милли үзаң — бөтен бер халыкның үз-үзенә читтән карый ала белүе... Киләчәккә бару өчен үз аты, үз арбасы һәм иң мөһиме — үз юлын таба белүе... һәм югалтмавы...

* * *

Дәүләтен җуйган милләтнең үзаңы зәгыйфь, дененнән язган милләтнең үзаңы бөтенләй юк...

* * *

Милләт һәм милләтләрнең атасы юк — баласы гына бар.

* * *

Мәнфәгатьләре милләтенекеннән өстен — милләтпәрвәр булалмый...

* * *

Милләт буларак танылу өчен һәркем үз ана телен камил белергә, гореф-гадәтләрен, йолаларын

үтәргә, үзе туган һәм торган җирдә гөлбакча итеп тормыш корырга тиеш...

* * *

Башка милләтләргә кечерәйтеп һәм җирәнеп караучы милләт — миһербансыз һәм мин-минлекле милләт...

* * *

Милләт яшәсен өчен санын, сынын, ысулын, асылын һәрдаим кайгырту зарур...

* * *

Мәктәпсез милләт — диңгездәге көсмәнсез көймә... Җил кайдан иссә, шунда юнәлә; давыл купса, дулкын белән төпкә китеп югала...

* * *

Милләтеңне яклап бер сүз әйталмасаң әйтмә, әмма аны һичбер хурлама...

* * *

Иң оятсыз ялган — милләтләрнең үз теләге белән бер-беренә кушылуы турында.

* * *

Милли мескенлек — телсез калу. Тел булмагач — ишеткәнне, күргәнне, белгәнне дә әйтеп булмый. Кирәкне сорап, булганны биреп булмый... Телсезлек — бөтенләй бетү билгесе.

## 48

* * *

Иң тынгысыз матдә — кеше.

* * *

Үр — җирдә Адәм баласы корган иң беренче корылма.

* * *

Тешкә теш тигәндә, ут чыкмый,
Ташка таш тигәндә, үт чыга...

* * *

Җирнең җиде катламы, Күкнең җиде түбәсе булган кебек, Кешенең дә җиде бүленеше бар: үкчә-табан; балтыр-тез; бот-бил; арка-күкрәк; куллар-иңсә; муен; баш... Шуларны умыртка тотып тора...

* * *

Кемнең кемлегенә беренче бәя: киеменә-кыяфәтенә карап; аннан акылына-гамәленә карап; ә иң соңгысы каберенә карап бирелә...

* * *

...Җанга тынычлык ике дөньяда да юк...

* * *

...Казан — калалар каласы...

* * *

Бармы җиһанда колның кадерен белгән кемдер?

* * *

Кол азатлык дип хыялланмый, ул үзенә кол булдырырга тели.

* * *

Коллык — кешене түбәнсетү, изүнең иң биек ноктасы. Колбиләүчелек бетү — әле коллык бетү дигән сүз түгел.

* * *

Балта тотып сүтә белгән ир дә булдыксыз түгел...

* * *

Хыянәтне кичерү — үзеңә-үзең хыянәт итү ул.

* * *

Бур мәченең — күзе майлы,
Хыянәтче хатынның күзе юеш булыр.

* * *

Шатлыктан чыккан яшь әче булмый...

* * *

Шар сугу, туп тибү, туп чөю өчен түгелгән акчалар җир йөзендә ачлыкны бетерүгә җитәр иде...

* * *

«Ашаган авыз ояла» дигән сүздә кешене аш белән, акча белән үзеңә авыштырырга, миһербанлы итәргә тырышу бар. «Ашаган табагына төкерде!» — кемнәр турында?



* * *

Саран — биргәндә, комсыз алганда танылыр...

* * *

Саранннан кышын кар алып булмас...
Комсыздан чүлдә бер ком да калмас...

* * *

Саранның сандыгында алтын булыр.
Ятагы һәм якканы салам булыр...

* * *

Саранга кызын биргән —
Җилгә элеп киптергән...

## 50

* * *

Рәхмәтне сорап алмыйлар, әмма әйттереп алалар.

* * *

Күрсәткән хезмәткә рәхмәт әйтү генә җитми. Хезмәт өчен түләү — һәрчак мәҗбүри... Хезмәте өчен тулып баш тартучыга барыбер тиешлесен бирергә кирәк... Алу-алмау аның эше...

* * *

Күрсәтелгән хөрмәткә түләмиләр, рәхмәт әйтеп һәм үзенә дә хөрмәт күрсәтеп җавап бирәләр...

* * *

Сые мулдан булып та хөрмәте булмаса, аның белән йөрешмә...

* * *

Ташу — яр ашый...

* * *

Төшенерсез бик җентекләп карасагыз:
Авызымда җимеш түгел, кара сагыз.

* * *

Көчленеке, имеш, замана,
Йә, кайчан булмаган аныкы?!

* * *

Акыллыдан сүз чыгар тик сайланып,
Җитәр җире ап-ачык абайланып...

* * *

Авызда сүз, ярма түгел киледә,
Ни әйтсә дә, хөкем юк тик тилегә...

## 51

* * *

Бала бәла булудан туктаганчы бәгырьләр теткәләнеп бетәр.

* * *

Ата-анасыннан бертуктаусыз ни дә булса таләп иткән бала-чагадан иман-шәфкать көтеп булмый... Ул барыбер җае чыккан саен: «Сез минем бер генә теләгемне дә үтәмәдегез», — дип тәкрарлап торачак, үзенең ата-анасына шәфкатьсезлеген аклау өчен...

* * *

«Баланың баласы балдан баллырак» диюләрендә хаклык бардыр да... Әмма баланың баласы гына балдан баллырак, баланың баласы булмаганнарга битарафрак буласың.

* * *

Бала — бәгырь ите...
Баласызларның бәгыре китек.

* * *

Бала кайгысыннан айнуы авыр.

* * *

Ата-ананың балалары ирешкән уңышларга куануы табигый... Алар балаларда үз уңышларының дәвамын күрәләр, үзләре ирешкән итеп кабул итәләр...

* * *

Кешеләрдәге кимчелекне сөйләп йөрү, бигрәк тә аларның балаларын аз гына хурлау да үз балларыңа йә аларның балаларына төшә: шул кимчелекләр икеләтә кабатлана...

* * *

Сабый баланың телендә ялган сүз булса да, күзләрендә хаклык булыр...

* * *

Бала берьюлы балдан татлы һәм баланнан ачы гына була ала...

* * *

Ата-анасына орынган баланы
Аллаһы Тәгалә үзе каргый...

* * *

Ерак үткәннәргә хәтердә булса да кайтып була,
Ерак киләчәккә барыр өчен хыял гына җитми...

**ҺӘР ХӘРЕФТӘ — БЕР ФИКЕР**

* * *

Ашаган авыз белән өшегән авыз бер булмас...

* * *

«Буласы …ыннан билгеле», — диләр, әмма булдыклылыкны билгеләүдә бу бердәнбер билге яки алым түгел...

* * *

Ватык арбаны төзәтә алмаган, аны утын итеп тә яга алмас...

* * *

Гаеп, гөнаһ — тәмугка юллама...

* * *

Дан вакыт һәм вөждан сынавына дучар...

* * *

Елмайган авыздан теш күренер, елмайган күздән төс күренер...

* * *

Жанның елан итенә ихтыяҗы юк... «Җаны теләгән — елан ите ашаган», дигәне — шайтанның нәфесне котыртуы гына.

* * *

«Заманына күрә ярый!» дигән җөмләдә кеше — адәм баласы үз булдыксызлыгына аклану эзли...

* * *

Илен изалаган илбашлары — иблис иңдәшләре...

* * *

Коръән — кяферлеккә киртә, тәүбә иттереп, оҗмахка илтә...

* * *

Ләззәтнең иң-иңе — иҗаттан алганы. Нарасыйның тәпи-тәпи атлап киткәне; тәүге кат: «Әттә-әннә!» — дигәне. Алар бар да иҗат нәтиҗәләре бит.

* * *

Моң — Җаннан бүленгән халәт... Моңлы кешеләр, моңлы халык-милләтләр бар... Җаннарын тыңлау кирәк...

* * *

«Ни эшләргә?» — дигән сорау, мәңгелек сорау. Җавабы Коръәндә ап-ачык бирелгән булса да, аны читтән эзли-эзли кеше үзенчә төрледән-төрле гамәлләр кыла... Мәңгелеккә — Аллаһы хозурына барып җиткәнче...

* * *

Отыш уеннарын шайтан уйлап чыгарган. Аларның асылында: күпләрнең өлешен кушып, бирсенә бирү ята. Шайтан кемгә бирәсе килсә, шуңа бирдерә... Ә кешеләр мәңге ялгышып: — Бу бәхет эше, Аллаһы бирде, — диләр. Аллаһы отыш уенын: — Хәрам! — ди юкса...

* * *

Почмаклар ныгытма коруда, ныклык булдыруда бик әһәмиятле... Почмак бер үк вакытта чикләнү билгесе, тамгасы да... Иң ышанычлы ныклык булдырганы — туры почмаклар һәм тигез почмаклар.

* * *

Рух — кешенең җанының, халыкның, кешелекнең халәте... Ул ике дөнья арадашчысы... Рух — үлемсез.

* * *

Савап өчен хәер һәрчак фарыз. Әмма аны — савапны — сатып алып кына булмый...

* * *

Туганлык — дәү бер агачтыр... Кәүсәсе — үзәге, җир астында тамырлардан, җир өстендә ябалдашы — ботак, яфраклардан туенадыр... Бер генә чук-тамыр өзелсә дә үзәгенә зыяндыр.

* * *

Ук — иң куркыныч үтерү коралы, аны һәркем ясый ала...

* * *

Форсат — очраклылык кына түгел. Ул — вакыт һәм киңлек чиксезлегендә кеше акылы белән, күңеле белән сиземли торган табигый бер халәттер...

* * *

Холык — кешеләрнең көчле һәм көчсезлек, барлык һәм юклык шартларында үз-үзләренә һәм үзара булган мөнәсәбәтләрнең чагылышы, халәте...

* * *

Чик — табигый рәвештә дә, канун рәвешендә дә билгеләнгән шарттыр. Чикне бозган — үз-үзенә һәм башкаларга уңайсызлык тудырган дигән сүз... Димәк, ирекнең дә «чиге» бар. Чикне бозган — башкаларның ireген кыскан була... Һәм киресенчә... Һәркем үз чиген белергә, файдаланырга, сакларга тиеш...

* * *

Шатлык — борчылудан арыну. Көтеп алган шатлык — үзеңнең гамәлең, холкың, теләгең кабул булу чагылышы. Көтелмәгән шатлык — сиңа кемнеңдер һәм язмышыңның бүләге. Шәрә шатлык булмый...

* * *

Ыргак — кеше уйлап тапкан иң беренче җайланма кебек. Чынлыкта исә Аллаһы аны кешенең үзе тәнендә үк күрсәтеп биргән: бармакларыңны бөк тә — ыргак яса... терсәгеңне бөгеп тә, билеңне бөгеп тә ясап була ыргакны... Әмма гомер буе ыргак булып яшәргә генә язмасын... Шуңар — ясалган ыргакларны куллану фарыз...

* * *

«Эчемдәге — тышымда» дигәннән ерак тор: исенә һәм төсенә буялырсың...

* * *

«Ә» — сорау, соклану, гаҗәпләнү, гайрәт чигү — чиркану авазы. Ул бик күп сүзләрне алыштыра ала.

* * *

«Йә» — өндәү һәм сорау билгесен берьюлы куйганда яңгыраган аваз. Ягъни мәсәлән, «Шуннан ни?! Шуннан шул: утырган да шуган. Йә — шуннан ни?..»

* * *

Өмет — кешенең ни-нәрсәгә дә булса гадәттәгедән артыграк түземлек белән дәгъва кылуы... морадына ирешүдәге дәвамлы теләге...

* * *

Һөнәр — акыл, сәләт һәм гамәл берлеге, камиллекнең чагылышы... Үзен һәм гаиләсен иң кирәкләр белән тәэмин иткән һәм үрнәк күрсәтә алган — һәрчак һөнәрле...

* * *

Ъ — калынлык билгесе — бәләкәй гәүдәле һәм кайтыш сәләткә ия кешенең үзеннән дәүрәк һәм өстеннәр белән идарә итәргә билгеләнгәч күзәтелгән кыланышлары җыелмасы...

* * *

Ь — нечкәлек билгесе... Әлифбасы — алфавиты камил булмаган телләрдә тупас авазларны йомшак-ыспай итеп күрсәтү өчен бизәнү чарасы...

* * *

Үлем — Җанның Хак Хода хозурына күтәрелүдәге адымы. Үтерү — тыелган үлем уены, йоласы... Уеннан уймак чыгару.

* * *

Юл сабу — алдагы буласы хәлләрне кисәтеп, дөрес юнәлеш биреп бару: Коръәннең төп асылы — шулдыр!..

* * *

Яшәү — Хак Хода ихтыяры белән Җанның дөньялыкка килеп-китү вакыты, урыны һәм башка җаннарга шул ук йоланы үтәүдә булышлык күрсәтүе... Яшәү — дөньялыкта гомер итү йоласы...

## ЭЧТӘЛЕК


Күзләр төсе. *Р.Зәйдулла* _________________

**Газәлләр**
«Фатихасыз бер көнем дә торалмам...» _____
«Коръән — бел, хаклык үрнәге бердәнбер...»
«Җир — тоташ бер сәхнә, тора әйләнеп...» __
«Күкләр хәбәр итә шул көн хакында...» ____
«Актарасың: һәр битеннән батыр чыга...» ___
«Үтеп бара заман, тузган чал чәче...» ______
«Ничек, дисәң, шулай мөмкин атарга...» ____
«Кемлегенә карап, сыең куясың...» ________
«Газәл — гүзәллек бакчасы...» .___________
«Холыксызлар кемнедер гел битәрләр...» ___
«Килгәнсең дә төпләнгәнсең бу якта...» _____
«Чигенде кыш — чигенгән гаскәр кебек...»
«Күкләр битараф түгел һәр тарафка...» _____
«Тантана итсә дә һаман төннең туе...» ______
«Ни тәңгәллек — бердәй тамыр тибеше...» ___
«Кышның китәсе килмиме һич кенә...» _____
«Уйчан йөзем борчулы күренмәсен...» ______
«Һәр ташуда ун адым чигенде яр...» _______
«Тулган айда күрдем йөзең төсләрен...» ____
«Дөнья гел алыш-бирештә, аңла син...» ____
«Кызлы йортның капкасында ат торыр...» __
«Күзгә-күз багып бирәмсең сәламең...» _____
«Көн уртасы, туктап калды сәгатем...» ______
«Әйтче, кардәш, һаман түзеп торыйкмы...» __
«Тыңла, ничек сыктый көз кышны тоеп...» _
«Бәләкәй булсаң бул...» __________________
«Карыйм да бу дөньяның дүрт ягына...» ____

**Робагыйлар**

**Кош теле** *(Кыска шигырьләр)*
Икеюллыклар __________________________
Өчьюллыклар __________________________
Дүртьюллыклар ________________________
Бишьюллыклар ________________________
Адәм баласына _________________________
Алтыюллыклар _________________________
Җидеюллыклар ________________________
Сигезьюллыклар _______________________

**Тулган айга карап**
Аккош күлендә _________________________
Кемнең дә булса барыбер ________________

«Кояш — бер генә...» ____________________
Бабаң монологы _________________________
«Өреп кабасын оныткан...» _______________
«Карында яткан бер үк яралгы...» _________
Мәсәл ___________________________________
XXI гасыр ______________________________
Чоры башка, жыр бүтән... _______________
«Хак тарихны Бер Хак белә...» ___________
«Йә, ничекләр түзде икән...» _____________
Юмарт патша көтеп ятып... ______________
Больницада ишеткәннәр, яки замана такмаклары __________________________________
Каен кайгы китерәме? ____________________
Инкарь итеп кара шуны __________________
Сабыйлык хатирәсе ______________________
Иблис ___________________________________
Булганы, булмаганы _____________________
«Скифлар — ерак бабайлар...» ____________
Җилнең эзләгәне ________________________
Гомер иткән һәр көн — бәхет! _______ ______
Юатып ни әйтә алам? _____________________
Бер хәбәрсез югалганнар... _______________
Кавемем — зур оям _______________________
Сүтеп ятам хәтер чорнаганны _____________
«Тамыры тирән...» _______________________
Тере су _______________________________
Җил хәбәрен әйтеп... _____________________
Яңа гасыр дигәне дә _____________________
Яз мизгелләре ___________________________
Җилдән туган, дип әйтүләре ______________
Ышансаң-ышанмасаң да... ________________
«Үткәннәре белән яши һәркем...»__________
Карлы яңгыр ____________________________
Тик син генә ____________________________
Иртә язда _______________________________
Тәрәзәмдә Тулганай ______________________
Күзләргә кердисәм _______________________
Илһамият, рәхмәт сиңа! __________________
Сагыш __________________________________
Бу — яшәү көедер _______________________
Каурый болытта тибрәлә бер төймә ________
Изге сукмак _____________________________
Яшәр өчен ______________________________
Булды, булды... __________________________
Чорында бердәнбер була... ________________
Ялган сүз _______________________________
Егылдык та тордык... ____________________
Күздә бер мәл ___________________________
Язның тәүге көннәре _____________________
Яздан җәйгә күчкәндә ____________________
Күз — күтеп алганым _____________________
Сиңа кайтыр юлым _______________________

**Гыйбарәләр**
«Бер йотым су» __________________________
Һәр хәрефтә — бер фикер ________________

Литературно-художественное издание

**Мухаммед Мирза**

(**Ибрагимов** Ильфак Мирзаевич)

ЖИВАЯ ВОДА

Казань. Татарское книжное издательство

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Мөхәммәт Мирза**

(**Ибраһимов** Илфак Мирза улы)

ТЕРЕ СУ

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.П.Клипова*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 6.03.2007. Форматы 70г108 1/32.
Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 15,4. Шартлы буяу-оттиск 15,75.
Нәшер-хисап табагы 7,36. Тиражы 3000 д. Заказ С–270.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.